ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# 1990 – 2014 елларда Татарстан Республикасының закон чыгару эшчәнлеге торышы турында доклад

Казан
2015

*Төзүче авторлар:*

***Ю.З. Камалтынов, Яһудин (ю.ф.к.), А.А. Ощепков, Ф.Р. Волкова, М.Б. Сөнгатуллин, Э.М. Мостафина, И.И. Фәттахов, Д.И. Мәхмутов, Л.И. Ибраһимова (ю.ф.к.), Л.Г. Казакова, А.Ә. Шакирова, Э.Р. Ишмаева, Л.В. Архипова, В.В. Борисова, Э.А. Даутова, В.М. Захаров, А.Ә. Кәримова, А.Р. Насыйриева, Э.Т. Шакирова, Ф.В. Зарипов (ю.ф.к.)***

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынов редакциясендә.

**Татарстан Республикасының закон чыгару эшчәнлеге торышы турында доклад**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы басмасы, 2015 ел

ны бәйрәм көненнән соң килгән эш көненә күчерүне бетерүне тәкъдим итә.

Әлеге мәсьәләнең әһәмиятлелеге төрле факторлар йогынтысында, шул исәптән хезмәт җитештерүчәнлеге дәрәҗәсенең кимүе аркасында икътисад үсеше темпларының акрынаюы белән аңлатыла, чөнки дәвамлы бәйрәмнәр предприятиеләр эшчәнлегенең тотрыксызлыгына, җитештерү дәрәҗәсенең кимүенә, хезмәт хакына чыгымнарның артуына китерә.

Ил законнарына ял көне һәм эш көне булмаган бәйрәм көне туры килгән очракта ял көнен бәйрәм көненнән соң килгән эш көненә күчерү турындагы норма Хезмәт законнары турында кодекс белән билгеләнгән бәйрәм көннәренең саны 9 көн булган чорда «Хезмәт законнары турында РСФСР кодексына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 1992 елның 25 сентябрендәге 3543-1 номерлы Россия Федерациясе Законы белән кертелгән иде. Бүгенге көндә Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә эш көне булмаган бәйрәм көннәренең саны 14 көнне тәшкил итә. Күчерүләрне исәпкә алып ял итү көннәренең саны 3 – 4 көнгә арта.

Дәвамлы бәйрәмнәр сәнәгать производствосына сизелерлек дәрәҗәдә тәэсир ясый, ул ел саен гыйнвар аенда гына да якынча 10 процент керемен югалта. Закон кабул итү белән ял итү көннәренең саны кимиячәк, ә бу исә эш вакыты фондының кыскару проблемасын өлешчә хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы инициативасы белән кертелгән федераль закон проектларыннан 31 федераль закон проекты кире кагылды, 18 федераль закон проекты Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чакыртып алуга бәйле Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы каравыннан төшереп калдырылды, 13 федераль закон проекты кире кайтарылды.



**Эчтәлек**

«1990 – 2014 елларда Татарстан Республикасы законнары торышы турында доклад хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Карары ........ 5

Кереш сүз ........ 6

I БҮЛЕК. **1990 ЕЛДАН 2014 ЕЛГА КАДӘР ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ ЗАКОН ЧЫГАРУ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ АНАЛИЗ** ........ 8

II БҮЛЕК. **ДӘҮЛӘТ КОРЫЛЫШЫ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЗАКОННАР** ........ 22

Татарстан Республикасының дәүләт төзелеше турындагы законнар ........ 22

Дәүләт идарәсе турындагы законнар ........ 56

Суд системасы, иминлек һәм җәмәгатьчелек ........ 66

тәртибен саклау турындагы законнар ........ 66

Коррупциягә каршы көрәш турындагы законнар ........ 78

Җирле үзидарә турындагы законнар ........ 79

III БҮЛЕК. **ИКЪТИСАДЫЙ ҮСЕШ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЗАКОННАР** ........ 106

Икътисад тармагында дәүләт идарәсенең гомуми мәсьәләләре ........ 106

Салымнар һәм җыемнар өлкәсендәге законнар ........ 125

Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы өлкәсендәге законнар ........ 133

Энергетика өлкәсендәге законнар ........ 140

Торак законнары ........ 141

Җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге законнар ........ 148

Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар ........ 152

IV БҮЛЕК. **СОЦИАЛЬ ҮСЕШ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЗАКОННАР** ........ 169

Гражданнарның сәламәтлеген саклау, физик культура һәм спорт турындагы законнар ........ 169

Хезмәт һәм социаль яклау турындагы законнар ........ 173

Гаилә һәм яшьләр сәясәте турындагы законнар ........ 185

Мәдәният, фән һәм мәгариф турындагы законнар ........ 192

V БҮЛЕК. **РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ФЕДЕРАЛЬ СОБРАНИЕСЕ ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ ЗАКОН ЧЫГАРУ ИНИЦИАТИВАЛАРЫ** ........ 204





Аны куллану шулай ук җитди авыруларга китерә. Медицина нәтиҗәләренең иң билгелеләренә түбәндәгеләр керә: тешләр бетүе, кариес, казналар атрофиясе, лайлалы тышчаның дистрофик үзгәрүе. Моннан тыш, тартмый торган төтенсез тәмәкене озак вакыт дәвамында куллану казналар, авыз куышлыгы, йоткылык, бугаз һәм үңәч рак авыруын китереп чыгара. Тартмый торган тәмәке шулай ук кан басымының артуына, кан тамырларының тараюына һәм йөрәк ритмының бозылуына бәйле рәвештә йөрәк-кан тамырлары авыруларының һәм инсультларның үсүендә роль уйнарга мөмкин.

Гражданнар сәламәтлеген саклауны тәэмин итү, тәмәке тартуны һәм тартмый торган тәмәке әйберләренең аерым төрләрен таратуны чикләү, шулай ук Россия Федерациясенең аерым субъектлары территорияләрендә әлеге өлкәдәге проблемаларны вакытында хәл итү максатларында закон проекты белән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тартмый торган тәмәке әйберләрен сатуга өстәмә чикләүләр, шул исәптән тартмый торган тәмәке әйберләрен ваклап сатуны тулысынча тыюны (алкоголь продукциясен ваклап сату кебек – чикләүләр «Этил спиртын, алкоголь һәм спиртлы продукцияне җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 5 өлеше белән билгеләнде) билгеләү хокукын бирү тәкъдим ителә.

Закон проекты шулай ук Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына суыра торган тәмәкене (снюсны) күпләп яисә ваклап саткан өчен җаваплылык билгеләү өлешендә үзгәреш кертә.

Тартмый торган тәмәке әйберләрен, шул исәптән суыра торган тәмәкене (снюсны), куллану процессына балигъ булмаганнарның җәлеп ителүен исәпкә алып, шулай ук тартмый торган тәмәке әйберләренең яңа төрләрен таратуны булдырмау максатларында закон проекты белән тәкъдим ителгән сатуны чикләү, шулай ук тәмәке әйберләрен сату кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылык билгеләү чаралары безнең ил гражданнары арасында тәмәке тартуны сизелерлек киметәчәк.

6. «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 112 статьясының үз көчен югалтуын тану турында» 665384-6 номерлы проект (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның 26 ноябрендәге 194-V ДС номерлы карары).

Федераль закон проекты ял итү көннәренең санын билгеләүнең рациональ алымын тәэмин итүгә юнәлдерелгән һәм ял көннәре һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәре туры килгән очракта алар-

эшен кузгатуны кире кагу турында законсыз һәм нигезләнмәгән карарлар чыгарылган очракта, шулай ук законнарның үтәлешен тикшерү нәтиҗәсендә җинаятькә туры килгән билгеләре булган хокук бозулар ачыкланган очракларда тиешле йогынты ясауга билгеле бер гарантия бирәчәк.

Шулай ук затны сак астына законлы ябу турында карар кабул иткәндә прокурорның күзәтү вәкаләтләрен киңәйтүне; сорау алу органнарыннан һәм тикшерү органнарыннан җинаятькә кагылышлы суд эшен судка кадәр башкарганда җибәрелгән федераль законнарны бозуларны бетерүләрен таләп итү хокукын бирүне күз алдында тоткан үзгәрешләр, җинаятькә кагылышлы суд эшен башкарганда, гражданнар хокукларын саклау гарантияләрен көчәйтүгә юнәлдерелгән.

Закон проектында шулай ук Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына административ тоткарлау кебек җәза чарасы кулланылган гражданнарның конституциячел хокукларын саклау буенча прокурор йогынтысы чараларын вакытында куллануга юнәлдерелгән үзгәреш кертү каралган.

4. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.43 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 223299-6 номерлы проект (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2013 елның 31 гыйнварындагы 2667-IV ДС номерлы карары). Закон проекты белән мотор ягулыгының сыйфатсыз продукциясен саткан өчен җаваплылыкны көчәйтү турында тәкъдим кертелә.

5. «Әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тарту зыяннарыннан гражданнар сәламәтлеген саклау турында» Федераль законның 19 статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.53 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 665383-6 номерлы проект (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2014 елның 26 ноябрендәге 195-V ДС номерлы карары).

Федераль закон проекты Россия Федерациясе территориясендә тартмый торган тәмәке әйбере снюсны күпләп һәм ваклап сатуны тыюны күздә тота.

Суыра торган тәмәке (снюс) – тартмый торган төтенсез тәмәкенең бер төре, аның төп компоненты никотин, ул снюсның бер порциясендә бер сигаретта караганда 5 мәртәбә күбрәк. Әлеге тәмәке әйберен 30 минут «чәйнәү» организмга өч сигаретта булган никотинга тигез никотин күләмен җиткерә, ә атнага ике кап снюс куллануның нәтиҗәсе көненә 1,5 кап сигарет тартканнан булган нәтиҗәгә тиң диярлек.

Никотин көчле ияләнүне китереп чыгарганга күрә, снюс кулланучылар тиз арада аннан физик һәм психик бәйлелеккә эләгә.



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 1990 – 2014 елларда Татарстан Республикасы законнары торышы турында доклад хакында

1990 – 2014 елларда Татарстан Республикасы законнары торышы турында доклад хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынов чыгышын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларының тәкъдимнәрен гомумиләштереп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. 1990 – 2014 елларда Татарстан Республикасы законнары торышы турында докладны (алга таба – Доклад) хупларга.

2. Докладны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы Рәисенә, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисенә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенә, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы әгъзалары – Татарстан Республикасыннан вәкилләргә, Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына, Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Аппаратының Хокук идарәсенә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектларга җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына, 2016 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проектлары белән эшләүнең якынча планын төзегәндә, Докладтагы тәкъдимнәрне исәпкә алуны тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре Л.Н. Мавринага Докладны татар һәм рус телләрендә брошюра рәвешендә бастырып чыгаруны һәм аларның электрон күчермәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтына урнаштыруны оештырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2015 елның 16 апреле
№ 552-V ДС

## Кереш сүз

2014 елның сентябренә Татарстан Республикасының закон чыгару эшчәнлеге торышы турында доклад 2012 ел Докладының актуальләштерелгән редакциясеннән гыйбарәт, ул узган чорга республика закон чыгару эшчәнлегендәге үзгәрешләрне исәпкә ала, шулай ук шушы елларда кабул ителгән Татарстан Республикасының яңа законнары хакындагы мәгълүматтан тора. I бүлектә 1990 елдан алып 2014 елның сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару эшчәнлегенә анализ бирелде.

Татарстан Республикасының закон чыгару эшчәнлеге торышы турындагы докладка түбәндәгеләр керә:

«Татарстан Республикасының дәүләт төзелеше турындагы законнар», «Дәүләт идарәсе турындагы законнар», «Суд системасы, иминлек һәм җәмәгатьчелек тәртибен саклау турындагы законнар», «Коррупциягә каршы көрәш турындагы законнар», «Җирле үзидарә турындагы законнар» бүлекчәләреннән торган «Дәүләт корылышы өлкәсендәге законнар» бүлеге;

«Икътисад тармагында дәүләт идарәсенең гомуми мәсьәләләре», «Салымнар һәм җыемнар өлкәсендәге законнар», «Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы өлкәсендәге законнар», «Энергетика өлкәсендәге законнар», «Торак законнары», «Җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге законнар», «Әйләнә-тирә мохитне саклау турындагы законнар» бүлекчәләреннән торган «Икътисадый үсеш өлкәсендәге законнар» бүлеге;

«Гражданнарның сәламәтлеген саклау, физик культура һәм спорт өлкәсендәге законнар», «Хезмәт һәм социаль яклау турындагы законнар», «Гаилә һәм яшьләр сәясәте турындагы законнар», «Мәдәният, фән һәм мәгариф турындагы законнар» бүлекчәләреннән торган «Социаль үсеш өлкәсендәге законнар» бүлеге;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертелгән, федераль законнар сыйфатында кабул ителгән, шулай ук Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында карауда булган Дәүләт Советының закон чыгару инициативалары турындагы мәгълүмат бирелгән закон чыгару инициативалары хакындагы бүлек.

Парламент эшенең өстенлекле юнәлеше булып республика закон чыгару эшчәнлегенең сыйфатын арттыру тора. Шуңа бәйле рәвештә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, законлылык һәм хокук тәртибе режимын ныгыту, Татарстан Республикасы законнарының гамәли көче нәтиҗәлелеген билгеләү





кертүне, шулай ук күрсәтелгән категориядәге гражданнарга социаль ярдәм итү чаралары исемлеген билгели.

2. «Гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 481349-5 номерлы проект (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2010 елның 23 декабрендәге 1438-IV ДС номерлы карары). Федераль закон проекты күрсәтелгән Федераль законның аерым нигезләмәләрен актуальләштерү, шулай ук гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләренә ярдәмне көчәйтү максатларында әзерләнде. Проект белән, хокукый җайга салудагы бушлыкны бетерү максатларында, гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләренең гомуми файдаланудагы мөлкәтенә караган җир кишәрлекләренең әйләнешенә кагылышлы яңа нигезләмәләр кертелә. Гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир кишәрлекләре коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәсе әгъзаларының гомуми җыены карары нигезендә коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәсе әгъзалары арасында бары тик берләшмә территориясенең генераль планына яисә төзүне оештыру проектына билгеләнгән тәртиптә төзәтмәләр кертеп кенә бүленә алуын билгеләргә тәкъдим ителә. Проектта шулай ук гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәсе идарәсенең компетенциясен тәгаенләүгә һәм идарә рәисенең мондый берләшмә әгъзалары алдындагы җаваплылыгын арттыруга юнәлдерелгән нигезләмәләр урын алган.

3. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 84590-6 номерлы проект (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2012 елның 28 маендагы 2198-IV ДС номерлы карары). Федераль закон проекты кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен нәтиҗәле яклауны арттыру максатларында законнарны камилләштерүгә юнәлдерелгән һәм җинаятьчелеккә каршы көрәшне көчәйтү, прокуратураның хокук яклау функцияләрен ныгыту максатларында җинаятькә кагылышлы суд эшен башкарганда хокук институтларының һәм прокурор күзәтчелеге механизмнарының нәтиҗәлелеген арттыру өчен Россия Федерациясенең Җинаять-процессуаль кодексына, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына һәм «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертә.

Закон проекты прокурорның җинаять эшен кузгату буенча элек булган вәкаләтен кире кайтаруны күздә тота, бу исә җинаять

6. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 251 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 16 ноябрендәге 320-ФЗ номерлы Федераль закон торак фондын саклап калуны һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруны тәэмин итү максатларында, күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренең күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү өчен идарә итүче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак һәм бүтән махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына җибәрелә торган акчалары салым салу базасыннан төшереп калдырды, шуның белән бергә аларны күрсәтелгән өлештә оешмаларның табышына салымнан азат итте (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2009 елның 24 сентябрендәге 400-IV ДС һәм 2010 елның 8 июлендәге 1069-IV ДС номерлы карарлары).

7. «Россия Федерациясе субъектларында җәмәгать судьяларының гомуми саны һәм суд участокларының исәбе турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2010 елның 12 ноябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон (Татарстан Республикасында җәмәгать судьяларының санын арттыру турында) (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2011 елның 25 ноябрендәге 1932-IV ДС номерлы карары).

8. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.19 һәм 9.11 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 25 ноябрендәге 316-ФЗ номерлы Федераль закон гражданнарның, юридик затларның һәм вазыйфаи затларның ресурслар тотуны исәпләү приборларының күрсәткечләрен бозып күрсәтү фактлары буенча административ җаваплылыкны көчәйтүне күздә тота (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2012 елның 24 декабрендәге 2619-IV ДС номерлы карары).

6 федераль закон проекты Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында төрле дәрәҗәдә карау стадиясендә:

1. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 493433-4 номерлы проект (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2007 елның 5 июлендәге 3022-III ДС номерлы карары). Әлеге федераль закон проекты СССРның вакытлыча басып алынган территорияләрендә эшләү чорыннан тыш, 1941 елның 22 июненнән алып 1945 елның 9 маена кадәр кимендә алты ай тылда эшләгән гражданнарга, шулай ук Бөек Ватан сугышы вакытында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнгән гражданнарга социаль ярдәм итү чараларын Россия Федерациясенең чыгым йөкләмәләренә



максатларында Татарстан Республикасы законнарына мониторинг уздыруны күздә тота торган «Татарстан Республикасы законнары мониторингы турында» 2010 елның 3 июлендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде.

Доклад асылда Татарстан Республикасы законнарына мониторингтан һәм 1990 елдан алып 2014 елның сентябренә кадәр республика закон чыгару эшчәнлегенә анализдан гыйбарәт.

**Ф.Х. Мөхәммәтшин,**
**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**

## I БҮЛЕК

## 1990 ЕЛДАН 2014 ЕЛГА КАДӘР ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ ЗАКОН ЧЫГАРУ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ АНАЛИЗ

1990 елдан алып Татарстан Республикасы Югары Советы һәм беренче – дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы (алга таба – Дәүләт Советы) тарафыннан 1584 закон кабул ителде. Аларның 714 төп, 870 – үзгәрешләр кертү турындагы законнар. Барлык законнардан 546 закон гамәлдә булу чоры тәмамлануга йә законның үз көчен югалтуын тану хакында махсус закон чыгару нормаларын кабул итүгә бәйле үз көчләрен югалткан дип танылды. Түбәндәге җиде кодекс кабул ителде һәм гамәлдә: Татарстан Республикасы Җир кодексы (1998 ел), Татарстан Республикасы Бюджет кодексы (2004 ел), Татарстан Республикасы Гаилә кодексы (2009 ел), Татарстан Республикасы Сайлау кодексы (2007 ел), Татарстан Республикасы Экология кодексы (2009 ел), Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы (2006 ел), Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы (2013 ел). Элек Татарстан Республикасы Урман кодексы (1994 ел), Татарстан Республикасы Су кодексы (1999 ел), Татарстан Республикасы Шәһәр төзү кодексы (2001 ел) кабул ителгән иде, соңрак алар үз көчләрен югалтты.

Татарстан Республикасы законнарының сан ягыннан бүленеше диаграммада һәм таблицада күрсәтелгән.








лар исемнәре, кеше исемнәре, фамилияләр һ.б.), эшчәнлегенең характеры (предметы, максаты) бертөрле булган (бу очракта иминият эшчәнлеге) юридик затлар мохитендә шушы оешманы индивидуальләштерүгә юнәлдерелгән юридик затның үз атамасы (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2005 елның 29 апрелендәге 1203-III ДС номерлы карары).

3. «Җинаять җәзаларын иректән мәхрүм итү рәвешендә үтәүче учреждениеләр һәм органнар турында» Россия Федерациясе Законының 38 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2007 елның 19 июнендәге 104-ФЗ номерлы Федераль закон Россия Федерациясе субъектларында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләргә контрольне гамәлгә ашыру өчен махсус рөхсәтсез җәзаларны үтәүче учреждениеләрдә һәм тикшерү изоляторларында булу хокукын бирде (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2007 елның 31 гыйнварындагы 2696-III ДС номерлы карары).

4. «Россия Федерациясе субъектларында җәмәгать судьяларының гомуми саны һәм суд участокларының исәбе турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2007 елның 21 июнендәге 111-ФЗ номерлы Федераль закон. Республика территориясендә өстәмә 31 суд участогы төзелде. Нәтиҗәдә җәмәгать судьяларының саны 199 җиткерелде, бер суд участогында халыкның уртача саны республикада 18,9 мең кешегә кимеде (15 меңнән алып 23 меңгә кадәр диапазон өчен бер суд участогына уртача күрсәткеч 19 меңгә тигез). Нәкъ менә бер суд участогы хезмәтләр күрсәткән гражданнарның исәп санын, димәк, җәмәгать судьяларына хезмәт йөкләнешен дә кимetү максатларында югарыда күрсәтелгән Федераль законга үзгәрешләр кертелде (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2006 елның 25 маендагы 2227-III ДС номерлы карары).

5. «Россия Федерациясендә җәмәгать судьялары турында» Федераль законның 1 һәм 5 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 8 декабрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль законда җәмәгать судьяларына карата һәм җәмәгать судьялары вазыйфаларына кандидатларга карата «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә судьяларга һәм судьялар вазыйфаларына кандидатларга карата куела торган шундый ук таләпләрнең әлеге Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып куелуы күздә тотыла (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2010 елның 22 апрелендәге 898-IV ДС номерлы карары).

## V БҮЛЕК

# РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ФЕДЕРАЛЬ СОБРАНИЕСЕ ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ ЗАКОН ЧЫГАРУ ИНИЦИАТИВАЛАРЫ

Россия Федерациясе субъектлары Россия Федерациясе Конституциясендә беркетелгән Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында закон чыгару инициативасы хокукын актив гамәлгә ашыра. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында закон чыгару инициативасы хокукының Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан тормышка ашырылуы субъектларның төбәк дәрәҗәсендә хәл итәргә хокукый мөмкинлекләре булмаган мәсьәләләрне хәл итү зарурлыгының тормыш өчен әһәмиятле булуы белән аңлатыла.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә 76 федераль закон проекты кертте, шуларның 8 федераль закон булды:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 85 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 18 апрелендәге 34-ФЗ номерлы Федераль законда, әгәр Федераль законда билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнары структурасы турындагы мәсьәлә буенча референдум (гражданнар җыены) уздыру хакында карар кабул ителмәгән булса, 2005 елның 31 мартына кадәр «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда каралган күчмә чорда Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына яңа төзелгән муниципаль берәмлекләр башлыкларын сайлап кую тәртибен билгеләү хокукын бирү күздә тотыла (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2005 елның 26 гыйнварындагы 925-III ДС номерлы карары).

2. «Россия Федерациясендә иминият эшен оештыру турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 21 июлендәге 104-ФЗ номерлы Федераль закон. Әлеге Федераль закон Россия Федерациясе Законының гамәлдәге законнарның нормаларына каршы килүен бетерүгә һәм Россия Федерациясендә иминият базарын үстерүгә юнәлдерелгән. Ул вакытта гамәлдә булган Россия Федерациясе Законы редакциясендә түбәндәгеләрнең кайсысын фирма атамасына өлешчә туры килә дип санарга дигән күрсәтмәләр юк иде: иҗек, сүз йә сүз һәм (яисә) сан белән билгеләнгән (предмет-





### 1990 елдан 2014 елга кадәр Татарстан Республикасы парламенты кабул иткән законнар саны

1 таблица

| | ТР Югары Советы (1990 августы – 1995 марты | ТР ДС I чакырылыш (1995 марты – 1999 декабре) | ТР ДС II чакырылыш (1999 декабре – 2004 марты) | ТР ДС III чакырылыш (2004 марты – 2009 марты) | ТР ДС IV чакырылыш (2009 марты – 2014 сентябре) | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Кабул ителгән Татарстан Республикасы законнары саны | 115 (шуларның 83 төп) | 141 (шуларның 85 төп) | 223 (шуларның 102 төп) | 514 (шуларның 260 төп) | 591 (шуларның 184 төп) | 1584 (шуларның 714 төп) |

1990 елдан (август) 2014 елга (сентябрь) кадәр закон чыгару эшчәнлеген анализлап, парламент тарафыннан кабул ителә торган законнар санының чакырылыштан чакырылышка артуын билгеләп үтәргә була. Ел саен кабул ителә торган законнар саны уртача түбәндәгечә: беренче чакырылышта (1995 – 1999) 25, икенче чакырылышта (1999 – 2004) 55, өченче чакырылышта (2004 – 2009) 75 һәм дүртенче чакырылышта (2009 – 2014) 100.

1990 елдан алып 1999 елга кадәрге чор – Татарстан Республикасы законнарының үсү чоры. Бу дәвердә Татарстан Республикасының яңа дәүләт-хокукый статусын ныгыта торган законнар, бу беренче чиратта 1992 елда кабул ителгән Татарстан Республикасы Конституциясе, кабул ителде.

Бу чор күбесенчә төп законнар кабул итү белән аерылып тора, алар кабул ителгән законнарның 72% тәшкил итә.

Бу чор закон чыгару эшчәнлегенең тагын бер үзенчәлеге булып федераль законнар белән чагыштырганда алда барып хокукый җайга салу актларын кабул итү тора. Мондыйларга Татарстан Республикасы Җир кодексы (1998 ел), «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законы (1998 ел), «Тузган торакны бетерү өчен максатчан салым турында» Татарстан Республикасы Законы (1996 ел), «Дәүләт хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законы (1994 ел) һәм Татарстан Республикасы карамагындагы мәсьәләләр, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы карамагындагы уртак мәсьәләләр буенча башка законнар (дәүләт корылышы, икътисад, мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау, экология һәм табигатьтән файдалану өлкәләрендә).

Татарстан Республикасында II чакырылыш Дәүләт Советының закон чыгару эшчәнлеге 1999 елдан (март аеннан) алып региональ законнарны федераль законнарга тәңгәлләштерүнең гомумроссия процессы тәэсирендә гамәлгә ашырылды.

Күрсәтелгән хәлләр элек кабул ителгән законнарга үзгәрешләр кертү буенча республика дәрәҗәсендәге күпсанлы актлар кабул итүне йә аларны үз көчләрен югалткан дип тануны таләп итте: кабул ителгән законнар күләменең яртысын (52%) Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү турында законнар тәшкил итте, 1990 елдан кабул ителгән 583 законның 132се (25%) законның үз көчен югалтуын тану хакында махсус закон чыгару нормаларын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтты.

2004 – 2014 елларда Татарстан Республикасы законнары үсешенә федераль әһәмияте дә булган берничә фактор тәэсир ясады.

1999 ел ахырыннан федераль закон чыгаручы кысалы законнар кабул итүдән акрынлап, еш кына Россия Федерациясе субъектларының вәкаләтләрен алып, турыдан-туры гамәлдә булган федераль законнар кабул итүгә күчә.

2000 елларның беренче яртысында тулы масштаблы административ һәм муниципаль реформалар үткәрелә. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында» (1999), «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» (2003), «Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларының «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» федераль законнар кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуын тану турында» («Ташламаларны акчалата бирү турында» Законы) (2004) кабул ителде, алар республиканың күпсанлы закон актларын кабул итүне таләп итте. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законны үстерү йөзеннән генә дә Татарстан Республикасы парламенты тарафыннан 108 закон кабул ителде.

Тулаем алганда хәзерге этапта кабул ителә торган законнарны анализлаганда мөстәкыйль хокукый җайга салу предметына ия булган законнар санының кимү тенденциясе күзәтелә, бу,





касында муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативлары да раслана.

Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 21 октябрендәге 1172 номерлы Указы белән федераль университетларга дәүләт ярдәмен күрсәтү, аларны үстерүнең хупланган программаларын исәпкә алып, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары белән берлектә Россия Федерациясе Хөкүмәтенә йөкләнелә. «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары һөнәри белем мәгариф учреждениесендә белем бирүне үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2014 елның 9 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 48-ТРЗ номерлы Закон) федераль университетның социаль һәм икътисадый мәсьәләләрне хәл итүдә нәтиҗәле катнашуы өчен Татарстан Республикасында оештыру һәм норматив хокукый шартлар тудыруга юнәлдерелде.

48-ТРЗ номерлы Закон белән «Казан (Идел буе) федераль университеты» (алга таба – Университет) федераль дәүләт автоном югары һөнәри белем мәгариф учреждениесенә дәүләт ярдәмен күрсәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре, Университетка дәүләт ярдәменең төп юнәлешләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Университетның үзара эшләвенең төп юнәлешләре билгеләнде.

Университетта белем бирүне үстерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары күләме Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

киеменә карата таләпләр билгеләнү. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың белем алучыларның киеменә карата таләпләрне билгели торган локаль норматив акты белем алучылар советы, ата-аналар советы, шулай ук бу оешма хезмәткәрләренең һәм (яисә) анда белем алучыларның вәкиллекле органы (булганда) фикерләрен исәпкә алып кабул ителә.

68-ТРЗ номерлы Закон белән шулай ук инновация эшчәнлеге, мәгариф өлкәсендә дәүләт-хосусый партнерлык, сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларның белем алуын оештыру, максатчан кабул итү (максатчан укыту) үзенчәлекләре, педагогик хезмәткәрләргә социаль ярдәм күрсәтү чаралары һәм мәгариф өлкәсендәге башка мәсьәләләр җайга салына.

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасының яңа төп Законын гамәлгә ашыру кысаларында, Татарстан Республикасы закон актларын мәгариф өлкәсендәге яңа законнарга тәңгәлләштерү максатларында «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде, аның белән 35 Татарстан Республикасы законына, шул исәптән «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында», «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында», «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында», «Китапханәләр һәм китапханә эше турында», «Һөнәр берлекләре турында», «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы законнарына, башка Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына, Татарстан Республикасы Экология һәм Җир кодексларына үзгәрешләр кертелде. Күрсәтелгән закон актларына кертелгән үзгәрешләрнең күбесе аларның терминологиясен «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законда һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законында кулланыла торган төшенчәләргә һәм терминнарга тәңгәлләштерүне тәэмин итә.

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасының яңа төп Законы нигезләмәләрен үтәү йөзеннән 2013 елның сентябреннән алып ел саен Татарстан Республикасы законнары белән Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативлары гына түгел, Татарстан Республи-





шул исәптән, Россия Федерациясе тарафыннан регионнарның закон чыгару вәкаләтләре чикләнүе шартларында республикада иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең законнар дәрәҗәсендә югары дәрәҗәдә җайга салынганлыгы турында сөйли.

Закон чыгару эшчәнлегендә беренче планга хокукый җайга салуның тулылыгы, норматив хокукый актның актуаль хәле, аның сыйфаты (каршылыксызлык, хокукый нормаларның ачык һәм төгәл булуы, коррупциоген факторлар булмавы) чыга.

Татарстан Республикасында хәзерге этапта тулы һәм заманча закон чыгару системасы бар, моны ышанып әйтергә була. Татарстан Республикасы законнары белән Татарстан Республикасы карамагындагы мәсьәләләр, уртак карамактагы эшләр буенча Татарстан Республикасы вәкаләтләрендәге мәсьәләләр буенча эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә иҗтимагый мөнәсәбәтләр җайга салына.

Татарстан Республикасы законнарының тематик блоклар буенча бүленеше диаграммада һәм таблицада күрсәтелгән.




**Кабул ителгән законнарның тематик блоклар буенча бүленеше**

2 таблица

| № | Хокукый җайга салу өлкәләре | ТР Югары Советы | ТР ДС I чакырылыш | ТР ДС II чакырылыш | ТР ДС III чакырылыш | ТР ДС IV чакырылыш | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Дәүләт корылышы һәм гражданнарның конституциячел хокуклары | 42 (36,5%) | 27 (19,2%) | 52 (23,3%) | 168 (32,7%) | 140 (23,7%) | 429 (27,1%) |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Финанс һәм бюджет сәясәте | 29 (25,2%) | 41 (29%) | 57 (25,5%) | 150 (29,2%) | 107 (18,1%) | 384 (24,2%) |
| 4 | Иминлек, хокук тәртибен саклау, суд эшчәнлеге һәм административ җаваплылык | 13 (11,3%) | 20 (14 %) | 28 (12,6%) | 37 (7,2%) | 122 (20,6%) | 220 (13,8%) |
| 3 | Икътисадый эшчәнлек | 7 (6%) | 18 (12,8%) | 30 (13,5%) | 52 (10,1%) | 71 (12%) | 178 (11,2%) |
| 6 | Социаль сәясәт | 16 (14%) | 10 (7%) | 25 (11,2%) | 44 (8,5%) | 62 (10,5%) | 157 (10%) |
| 5 | Экология һәм табигатьтән файдалану | 6 (5,2%) | 14 (10%) | 23 (10,3%) | 39 (7,6%) | 44 (7,4%) | 126 (8%) |
| 7 | Мәдәният, фән, мәгариф | 2 (1,7%) | 11 (8%) | 8 (3,5%) | 24 (4,7%) | 45 (7,6%) | 90 (5,7%) |
| 8 | Хокукый җайга салу өлкәләре буенча барлыгы | 115 | 115 | 223 | 514 | 591 | 1584 |

1990 елда ТАССР Конституциясе нигезендә (1989 елның 4 ноябрендәге Закон белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) закон чыгару инициативасы хокукына Татарстан АССР халык депутатлары, Татарстан АССР Югары Советы Президиумы, Татарстан АССР Югары Советы Рәисе, Татарстан АССР Конституциячел күзәтчелек комитеты, Татарстан АССР Министрлар Советы, Татарстан АССР Югары Советының даими комиссияләре, Татарстан АССР Халык контроле комитеты, Татарстан АССР Югары Суды, Татарстан АССР Прокуроры, Татарстан АССР Баш дәүләт арбитры (1992 елдан Татарстан Республикасы Югары Арбитраж суды), шулай ук аларның республика органнары йөзендә иҗтимагый оешмалар ия булды.

1992 елгы Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә закон чыгару инициативасы хокукы Татарстан Республикасы халык депутатларына, Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Югары Советының Президиумына, даими комиссияләренә һәм Парламент күзәтчелеге комитетына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасының Конституция судына, Югары судына һәм Югары Арбитраж судына, Татарстан Республикасы Прокурорына, шулай ук һөнәри берлекләрнең республика советына бирелде. Алга таба бу хокук Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә (1999 ел) һәм Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә (2000 ел) бирелде.

Татарстан Республикасы Конституциясенең яңа редакциясендә (2002 ел) закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектлар





«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 68-ТРЗ номерлы Закон) «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен үстерү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасында мәгариф өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне федераль законнар белән Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләренә кертелгән вәкаләтләр чикләрендә Татарстан Республикасы үзенчәлекләренә яраклаштырып җайга сала.

68-ТРЗ номерлы Закон белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы) арасында бүленде. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары мәгариф өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне Федераль закон нигезендә гамәлгә ашыра.

68-ТРЗ номерлы Закон нигезендә гражданнар федераль законнар белән гарантияләнгән мәктәпкәчә, башлангыч гомуми һәм төп гомуми белем бирү дәрәҗәсендә генә түгел, ә урта гомуми белем бирү дәрәҗәсендә дә туган телдә белем алырга хокуклы. Шулай ук законда Татарстан Республикасы урта һөнәри һәм югары белем мәгариф оешмаларында һөнәри белем бирү программаларының татар телендә гамәлгә ашырыла алуы каралды.

68-ТРЗ номерлы Закон белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан, социаль-икътисадый, экологик, демографик, этномәдәни һәм башка үзенчәлекләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасында мәгарифне үстерүнең максатчан программалары эшләнүе һәм раслануы каралды. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ел саен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында доклад тапшыра.

68-ТРЗ номерлы Закон нигезендә белем бирү эшчәнлеген башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү уку-укыту программалары буенча гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары һәм Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең муниципаль мәгариф оешмалары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган төп таләпләр нигезендә белем алучыларның

кабул ителде, ул кешенең һәм гражданның теләсә кайсы динне тотуында иреклe булу яисә бер дингә дә ышанмау, дини эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукын тәэмин итү һәм тормышка ашыру гарантияләрен билгели.

2279 номерлы Закон дини оешмалар эшчәнлегенең хокукый нигезләрен ныгыта, Татарстан Республикасында дини белем бирү тәртибен регламентлаштыра, дини эшләр буенча Татарстан Республикасы мәгълүмат, консультация, оештыру һәм эксперт дәүләт органын төзүне күздә тота.

2012 елның 4 августындагы 64-ТРЗ номерлы һәм 2013 елның 17 июлендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары белән дини экстремистлыкны кисәтү, конфессия эчендәге һәм конфессияара татулыкны ныгытуга ярдәм итү максатларында дини оешмаларның үз эчке билгеләүләре нигезендә руханиларның һәм дини персоналның эшчәнлекләре шартларын, шулай ук аларга карата таләпләр, шул исәптән дини белем бирү өлешендә, билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертелде.

«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» 1998 елның 18 июнендәге 1661 номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 1661 номерлы Закон) «Фән һәм фәнни-техник дәүләт сәясәте турында» 1996 елның 23 августындагы 127-ФЗ номерлы Федераль законның Татарстан Республикасы территориясендә фәннитехник дәүләт сәясәтенә караган өлешенең тормышка ашырылуын тәэмин итә.

1661 номерлы Закон фән һәм фәнни эшчәнлек өлкәсендә икътисадый, социаль һәм башка мөнәсәбәтләрне җайга сала, фәнни һәм техник иҗат ирегенә гарантияләр, фәнни хезмәткәрләрнең хокукларын һәм бурычларын, Татарстан Республикасының дәүләт фәнни оешмаларын төзү һәм аларның эшчәнлегенә идарә итү тәртибен билгели, фундаменталь фәнни тикшеренүләрне өстенлекле финанслауны күздә тота.

1661 номерлы Закон федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм үзенең уставы нигезендә гамәлгә куелган, үз эшләренә үзе идарә итүче оешма булган Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең статусын билгели. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе табигый, техник, иҗтимагый-гуманитар фәннәрнең мөһим проблемалары буенча фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләр үткәрә һәм Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән финанслана торган, фәнни оешмалар, югары һәм һөнәри белем бирү мәгариф оешмалары тарафыннан башкарыла торган фәнни тикшеренүләрне координацияләүдә катнаша, Россия Федерациясе академик оешмалары белән координацияләүне башкара.





даирәсе үзгәртелде. Закон чыгару инициативасы хокукын Татарстан Республикасы Президенты, Дәүләт Советы депутатлары, Дәүләт Советы Президиумы һәм комитетлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты саклап калды. Татарстан Республикасы Конституция суды, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үз карамакларындагы мәсьәләләр буенча закон чыгару инициативасы хокукын саклап калды. Татарстан Республикасы Югары суды, Татарстан Республикасы Югары Арбитраж суды, Татарстан Республикасы Прокуроры һәм һөнәри берлекләрнең республика советы әлеге хокукны югалтты. Җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары закон чыгару инициативасы хокукына ия яңа субъект булды. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе вазыйфасы булдырылгач, аңа шулай ук закон чыгару инициативасы хокукы бирелде. Соңрак 2010 елда закон чыгару инициативасы хокукы Татарстан Республикасы Прокурорына кире кайтарылды.

Закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектларның иң активы булып гадәттәгечә Татарстан Республикасы Хөкүмәте кала, аның инициативасы белән законнарның яртысы – 51% кабул ителде. Законнарның өчтән бер өлешеннән артыгын – 36%ын депутат (Дәүләт Советы депутатлары, Дәүләт Советы Президиумы һәм Дәүләт Советы комитетлары) инициативалары белән кабул ителгәннәре тәшкил итә.

Татарстан Республикасы законнарының закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектлар буенча бүленеше диаграммада һәм таблицада күрсәтелгән.



## 1990 – 2014 елларда кабул ителгән Татарстан Республикасы законнарының закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектлар буенча бүленеше

4 таблица

| № | Закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектлар | ТР Югары Советы | ТР ДС I чакырылыш | ТР ДС II чакырылыш | ТР ДС III чакырылыш | ТР ДС IV чакырылыш | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Президенты | 12 (10,4%) | 12 (8,5%) | 23 (10,3%) | 29 (5,6%) | 47* (8%) (1 – ТР ДС депутатлары белән берлектә) | 123 (7,8%)* |
| 2 | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы | 30 (26,1%) | 5 (3,5%) | – | – | 1 (0,1%) | 36 (2,3%) |
| 4 | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары | 5 (4,3%) | 26 (18,4%) | 36 (16,1%) | 56 (11%) | 136* (23%) (1 – ТР Президенты белән берлектә, 1 – ТР МК белән берлектә, 1 – ТР Үзәк сайлау комиссиясе белән берлектә) | 259* (16,3%) |
| 3 | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары | 4 (3,5%) | 17 (12%) | 87 (39%) | 93 (18,1%) | 77 (13%) | 278 (17,5%) |
| 6 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | 60 (52,2%) | 78 (55,3%) | 58 (26%) | 323 (62,8%) | 294* (49,7%) (1 – ТР ДС депутатлары белән берлектә) | 813* (51,3%) |
| 5 | Җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары | – | – | – | 11 (2%) | 25 (4,2%) | 36 (2,3%) |
| 7 | Татарстан Республикасы Прокуроры | 1 (0,8%) | 1 (0,7%) | 8 (3,6%) | – | 9 (1,5%) | 19 (1,2%) |
| 8 | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил | – | – | 6 (2,7%) | 2 (0,3%) | 1 (0,1%) | 9 (0,5%) |
| 9 | Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе | – | – | 1 (0,4%) | – | 4* (0,6%) (1 – ТР ДС депутатлары белән берлектә) | 5* (0,3%) |





телдә бирелә. Җавапны мөрәҗәгать итү телендә бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла. Моңа бәйле рәвештә, 1-ТРЗ номерлы Закон Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына гражданнардан, оешмалардан татар телендә латин яисә гарәп графикасында язылган мөрәҗәгатьләр кергән очракта, җавапларның татар телен кириллица графикасы нигезендә бирелү очрагын карый. Рәсми җавапка татар телендә латин яисә гарәп графикасы билгеләрен кулланып язылган җавап кушылып бирелергә мөмкин.

1-ТРЗ номерлы Закон белән татар алфавитын төрки һәм Көнбатыш Европа телләре белән унификацияләү, татар язуының тарихи традицияләрен өйрәнү өчен фәнни нигезләнгән иң уңай транскрипция кертелә. Көнчыгыш һәм татар лексемаларын, исемнәрен һәм атамаларын дөрес итеп транслитерацион бирүне тәэмин итү проблемасы төрки-татар мирасына кагылышлы фәнни хезмәтләрне бастырып чыгарганда, илдәге кайбер халыкларның латин графикасында, гарәп графикасында язылган язма һәм кульъязма мирасларын яңадан бастырып чыгаруга әзерләгәндә; иске татар язуындагы басмаларның электрон каталогларын төзегәндә һәм латин, гарәп графикасындагы басмаларны катологлаштырганда барлыкка килә. Татар алфавитының латин һәм гарәп графикаларына нигезләнгән транскрипция билгеләре татар һәм шәрык телләрендәге иске татар язулы һәм кульъязма чыганаклар белән эшләүче белгечләрнең киң даирәсенә, шулай ук китапханә, архив, музей белгечләренә кирәк.

«Татар алфавитын тәртипкә китерү турында» 1997 елның 20 гыйнварындагы 997 номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 997 номерлы Закон) татар алфавитын камилләштерү һәм аны төзү нигезләрен тәртипкә китерү максатларында кабул ителде һәм татар алфавитындагы хәрефләрнең санын һәм билгеләнешен раслады. 997 номерлы Закон «Татар язуын латинлаштырылган алфавиттан рус графикасы нигезендәге алфавитка күчерү турында» 1939 елның 5 маендагы Татарстан АССР Югары Советы Президиумы Указын үз көчен югалткан дип таныды һәм татар алфавитындагы аерым хәрефләрнең Указдагыдан үзгә урнашуын билгеләде.

«Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 2279 номерлы Закон) «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон кысаларында

финанслау тәртибен билгели торган нигезләмәләр, музейларга ярдәм күрсәтү төрләре күрсәтелгән.

69-ТРЗ номерлы Законның бер бүлеге музей-тыюлык дигән үзенчәлекле статуска ия музейлар категориясенә багышланган.

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 1560-XII номерлы Закон) «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Россия Федерациясе Законының тиешле нигезләмәләренә таяна.

Татарстан Республикасында дәүләт телләре итеп тигез хокуклы татар һәм рус телләре игълан ителә. 1560-XII номерлы Закон Татарстан Республикасында телләрнең сакланып калуы һәм, гадәтләрне саклап, тигез хокуклы булып үсүе, икетеллелек һәм күптеллелек үсү өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән.

1560-XII номерлы Закон дәүләт телләрен һәм башка телләрне Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм бүтән оешмалар эшчәнлегендә куллануны регламентлаштыра, тел өлкәсендә Татарстан Республикасы компетенциясен билгели, Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын кабул итү өчен хокукый нигезне раслый.

«Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба – 1-ТРЗ номерлы Закон) кабул итү Татарстан Республикасының бөтен территориясендә дәүләт теле буларак татар теленең кулланылышын тәэмин итү, дәүләт теле буларак татар телен куллануга гражданнарның хокукын тәэмин итү, татар тел культурасын яклау һәм үстерү, татар халкы язуының тарихи традицияләрен дәвам иттерүне саклап калу өчен кирәк булды. 1-ТРЗ номерлы Закон белән дәүләт теле буларак татар теле алфавитының кириллица графикасы нигезендә төзелүе билгеләнде.

Гражданнар, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләренә ярашлы рәвештә, тәкъдимнәрен, гаризаларын, шикаятьләрен Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, туган телдә яисә Россия Федерациясе халыкларының үзләре белгән теләсә кайсы телендә җиткерергә хокуклы. Тәкъдимнәргә, гаризаларга, шикаятьләргә җаваплар гражданнар мөрәҗәгать иткән





| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10 | Татарстан Республикасы Конституция суды | – | – | 3 (1,3%) | – | – | 3 (0,2%) |
| 11 | Һөнәри берлекләрнең республика советы | 2 (1,7%) | 1 (0,7%) | – | – | – | 3 (0,2%) |
| 12 | Татарстан Республикасы Югары Арбитраж суды | 1 (0,8%) | 1 (0,7%) | – | – | – | 2 (0,1%) |
| 13 | Татарстан Республикасы Югары Суды | – | – | 1 (0,4%) | – | – | 1 (0,06%) |

1990 елда Югары Совет тарафыннан 12 даими комиссия төзелде. 1995 елда I чакырылыш Дәүләт Советы тарафыннан даими комиссияләр карамагындагы мәсьәләләр берләштерелде һәм мондый 7 комиссия төзелде. 2002 елда Татарстан Республикасы Конституциясенә кертелгән үзгәрешләр белән даими комиссияләр Дәүләт Советы комитетларына үзгәртеп төзелде.

Хәзерге вакыттагы вәкаләтләрне бүлешүдән чыгып Татарстан Республикасы законнарының комитетлар карамагындагы өлкәләр буенча бүленеше диаграммада һәм таблицада күрсәтелгән.



### 1990 – 2014 елларда кабул ителгән Татарстан Республикасы законнарының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары карамагындагы өлкәләр буенча бүленеше

3 таблица

| № | Хокукый җайга салу өлкәләре | ТР Югары Советы | ТР ДС I чакырылыш | ТР ДС II чакырылыш | ТР ДС III чакырылыш | ТР ДС IV чакырылыш | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә | 36 (31,3%) | 22 (15,6%) | 39 (17,5%) | 154 (30%) | 116 (19,6%) | 367 (23,2%) |
| 2 | Законлылык һәм хокук тәртибе | 19 (16,5%) | 25 (17,7%) | 42 (18,8%) | 52 (10,1%) | 146 (24,7%) | 284 (18%) |
| 3 | Бюджет, салымнар һәм финанслар | 29 (25,2%) | 41 (29%) | 56 (25,1%) | 149 (29%) | 107 (18,1%) | 382 (24%) |
| 4 | Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык | 7 (6%) | 18 (12,7%) | 30 (13,5%) | 52 (10,1%) | 71 (12%) | 178 (11,2%) |
| 5 | Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр | 6 (5,2%) | 14 (10%) | 23 (10,3%) | 39 (7,5%) | 44 (7,4%) | 126 (8%) |
| 6 | Социаль сәясәт | 16 (14%) | 10 (7%) | 25 (11,2%) | 44 (8,5%) | 62 (10,5%) | 157 (10%) |
| 7 | Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр | 2 (1,7%) | 11 (7,8%) | 8 (3,5%) | 24 (4,6%) | 45 (7,6%) | 90 (5,6%) |
| 8 | Хокукый җайга салу өлкәләре буенча барлыгы | 115 | 141 | 223 | 514 | 591 | 1584 |

Федераль законнарның да, Россия Федерациясе субъектлары законнарының да тотрыксызлыгын хокук кулланудагы шактый зур кыенлыклар тудыра. Федераль законнарны кабул иткәндә ашыгычлык, тирән анализ булмау, законнар чыгару эшчәнлеген акламаслык дәрәҗәдә тизләтү закон чыгару эшендә үзара килешүнең булмавына, кабул ителә торган законнарның гамәлдәге законнар системасына туры килмәвенә сәбәп була. Федераль закон чыгаручы тарафыннан, гомуми принципларны җайга салган булып, Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләрне детальләп җайга салу закон чыгару өлкәсендә җитди проблема булып тора.

Хакимиятнең барлык дәрәҗәләре арасында вәкаләтләрне чикләү – Россия Федерациясе дәүләт сәясәтендәге актуаль мәсьәләләрнең берсе. Россия Федерациясе Конституциясендә са-





мәдәни автономияләрнең эшчәнлек төрләренә Россия милләте бердәмлеген ныгыту, этникара мөнәсәбәтләрне камилләштерү, диннәр арасындагы диалогка ярдәм итү, шулай ук мигрантларны социаль һәм мәдәни җайлаштыруга һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән эшчәнлек кертелде.

«Татарстан Республикасы Архив фонды һәм архивлар турында» 1996 елның 13 июнендәге 644 номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 644 номерлы Закон) «Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен республика территориясендә гамәлгә ашыруны тәэмин итә.

644 номерлы Закон белән, Татарстан Республикасында архивларны һәм архив фондларын туплау, саклау, исәпкә алу, куллануны һәм алар белән архив документларының сакланышын һәм гражданнар, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә аларның һәртөрле файдаланышын тәэмин итү максатларында, алар белән идарә итү җайга салына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, шулай ук җирле үзидарә органнарының архив эше өлкәсендәге компетенциясе раслана.

Музей эше өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» 2010 елның 14 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 69-ТРЗ номерлы Закон) кабул ителде.

69-ТРЗ номерлы Закон белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының музей эше өлкәсендәге вәкаләтләре билгеләнгән, Россия Федерациясенең Музей фондына кертелгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә булган музей әйберләре һәм музей коллекцияләренең хокукый режимы, Татарстан Республикасы территориясендәге музей әйберләре һәм музей коллекцияләренең торышын дәүләт тарафыннан тикшереп тору тәртибе билгеләнгән. Законда Татарстан Республикасында музей әйберләре һәм музей коллекцияләренең дәүләт каталогын, шулай ук дәүләт, муниципаль һәм дәүләткә карамаган музейлар турында белешмәләр бирүче Татарстан Республикасы музейлары реестрын булдыру һәм алып бару каралган.

69-ТРЗ номерлы Законда, Татарстан Республикасында эшли торган музейларның күптөрлелеген һәм күпсанлы булуын исәпкә алып, музейларның төрләре, аларны төзү, урнаштыру шартлары билгеләнгән, Татарстан Республикасы музейлары эшчәнлеген

еллар эшләгән өчен өстәмә түләү, белгечлек буенча эш стажына карап, вазыйфа окладыннан түбәндәге күләмнәрдә каралган: 5 елдан алып 10 елга кадәр эш стажы булганда – 20 процент, 10 елдан алып 15 елга кадәр – 25 процент, 15 елдан алып 20 елга кадәр – 30 процент, 20 елдан алып 25 елга кадәр – 35 процент, 25 ел һәм аннан күбрәк булганда – 40 процент.

«Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсе турында» 2005 елның 18 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 5-ТРЗ номерлы Закон), Татарстан Республикасы документларының тулы милли китапханә-мәгълүмат фондын туплау, Татарстан Республикасы документлары мәҗбүри нөсхәләренең дәүләт библиография исәбен алып бару һәм даими саклауны оештыру максатларында, «Документларның мәҗбүри нөсхәсе турында» 1994 елның 29 декабрендәге 77-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кабул ителгән.

5-ТРЗ номерлы Закон белән мәҗбүри нөсхәгә кергән документларның исемлеге ачыла, документлар җитештерүчеләрнең хокуклары һәм бурычлары, документларның мәҗбүри нөсхәсен илтеп җиткерүне тикшереп торуны башкару тәртибе билгеләнә.

Татарстан Республикасы документларының мәҗбүри нөсхәсен Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, Татарстан Республикасы Дәүләт матбугат архивы һәм Татарстан Республикасының аудиовизуаль документлары үзәк дәүләт архивы ала.

Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләренең 21 статьясында үз милли-дәүләт берәмлекләреннән читтә тыгыз яшәүче яки үз дәүләтчелеге булмаган барлык этник җәмгыятьләрнең мәдәни-милли автономиягә хокуклары каралган.

«Татарстан Республикасында милли-мәдәни автономияләр турында» 2003 елның 12 маендагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасында милли-мәдәни автономияләр системасын, милли-мәдәни автономиянең хокукларын билгели, гражданнарның милли (туган) телне һәм милли мәдәниятне саклап калу, үстерү һәм куллануга хокукларын тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан башкарыла торган чараларны карый, милли-мәдәни автономияләрнең финанс-икътисадый нигезен билгели.

«Татарстан Республикасында милли-мәдәни автономияләр турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән милли-





лынган Федерация һәм аның субъектлары арасында эшләр алып баруны бүлү принцибын һич тә уңышлы дип атап булмый.

Россия Федерациясенең үз карамагындагы эшләрдән һәм уртак карамактагы эшләр буенча Россия Федерациясе вәкаләтләреннән тыш субъектларның дәүләт хакимиятенең бөтен тулылыгына ия булуы турында Россия Федерациясе Конституциясенең 73 статьясында беркетелгән нигезләмә Федерациянең үз карамагында гына булган һәм уртак карамактагы мәсьәләләрнең шулкадәр детальләштерелгән булуын исәпкә алмый, нәтиҗәдә Россия Федерациясе Конституциясенең 71 һәм 72 статьяларына кагылмый торган эшчәнлек өлкәләрен ачыклау кыенлаша.

Алай гына да түгел, федераль закон чыгаручы алга таба тармак актларын кабул итү юлы белән уртак карамактагы мәсьәләләрне асылда бары тик Федерация карамагындагы эшләргә генә үзгәртте. Россия Федерациясе субъектларына регионның социаль-икътисадый үсешенә йогынты ясый алырлык мәсьәләләрне законнар белән җайга салу буенча минималь хокуклар бирелде.

Мондый ситуация, кызганычка каршы, субъектлар законнарының федераль законнарны «куып тоту» белән шөгыльләнүенә китерә. Федераль дәрәҗәдәге кечкенә генә үзгәрешләр дә региональ закон актларына тиешле үзгәрешләр кертү зарурлыгын китереп чыгара. Даими рәвештә үзгәрешләр кертеп тору эше региональ законнарның тотрыксызлыгы, регионнарның дәүләт хакимияте органнарының закон чыгару процессын тиешле дәрәҗәдә оештыра алмавы иллюзиясен тудыра.

Субъектларның һәм тулаем Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсешен тоткарлаучы факторларның берсе булган вәкаләтләрне бүлешү өлкәсендә баланслылык булмавының проблемага әверелүен федераль дәрәҗәдә аңлый башладылар. Шуның белән бергә әлеге проблеманы хәл итү буенча күрелгән чаралар җитәрлек түгел. Вәкаләтләрне бүлешүнең мөһим мәсьәләсе керем чыганаклары һәм чыгым йөкләмәләренең оптималь нисбәтеннән гыйбарәт, шуңа күрә әлеге мәсьәләдә салым керемнәрен Россия Федерациясе бюджет системасы дәрәҗәләре арасында яңадан бүлүдән башка алга бару бик кыен.

Әмма республика закон чыгару эшчәнлегендәге җитешсезлекләр федераль закон чыгару эшчәнлегендәге проблемалар белән генә бәйләнмәгән, алар үз проблемаларыннан да килеп чыга.

Норматив хокукый актның сыйфатын тәэмин итү ысулы булып аны гамәлгә ашыруны, хокукый җайга салуның планлаштырылган нәтиҗәсенә туры килүен тикшерү тора. Нәкъ менә шушы максатларда «Татарстан Республикасы законнары мониторингы турында» 2010 елның 3 июлендәге 49-ТРЗ номерлы һәм «Татар-

стан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары кабул ителде.

Мониторинг асылда закон чыгару эшчәнлеге сыйфатын тәэмин итүнең универсаль чарасы булса, норматив хокукый акт проектының җайга салу йогынтысын бәяләү хокукый җайга салу механизмнарын яхшырту мөмкинлеген бирә. Соңгысы бүгенге көн шартларында бигрәк тә әһәмиятле, чөнки эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге үсешенә дә, тулаем алганда, республика икътисады үсешенә дә уңай тәэсир итә. Дәүләт һәм муниципаль идарәнең сыйфатына да тиешле йогынты ясала. Моңа норматив хокукый актларның икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларының дөрес җыелмасы һәм социаль нәтиҗәләрне алдан күрү, шулай ук бәяләүдә катнашучыларның профессионализмы ярдәм итәргә тиеш.

Гамәлдә булган норматив хокукый актның сыйфатын тәэмин итүнең өстәмә чарасы булып аңа экспертиза ясау тора. Ул вәкаләтле орган тарафыннан үткәрелә, аның ролен башкарма хакимият органы башкара.

Норматив хокукый акт проектының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан элек кабул ителгән актларга экспертиза ясау законнардагы җитешсезлекләрне бетерүгә тәэсир итә алырлык ысуллар булып тора. Безнең фикеребезчә, бу эшчәнлекнең нәтиҗәләрен инде өйрәнергә һәм гомумиләштерергә кирәк. Бер яктан, мондый анализ әлеге законны гамәлгә ашыруны тикшерү ысулы булып торачак, икенче яктан аңа таянып, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген регламентлый торган закон актларының сыйфаты турында хөкем итәргә мөмкин булачак.

«Татарстан Республикасы законнары мониторингы турында» 2010 елның 3 июлендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә республика законнары исәпкә алып барылырга тиеш. Һәр закон буенча мәгълүмат системалаштырыла һәм Татарстан Республикасы законы паспорты рәвешендә рәсмиләштерелә, анда законның белешмә рәвешендәге күрсәткечләре һәм аңа кертелгән үзгәрешләр турында белешмәләр, законга карата суд карарлары, прокурор һәм юстиция органнары актлары исемлеге, шулай ук аларны карау нәтиҗәләре буенча Дәүләт Советы карарлары күрсәтелә. Бу Татарстан Республикасы законнарына нәтиҗәле мониторинг үткәрергә мөмкинлек бирә. Татарстан Республикасы законнарының паспортлары Дәүләт Советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми





Мәдәният өлкәсендә мөһим дәүләт бурычларының берсе — халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләрен саклап калу, яңарту һәм үстерү Татарстан Республикасында «Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» 2005 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп хәл ителә.

Күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законы «Халык сәнгать һөнәрләре турында» 1999 елның 6 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру кысаларында кабул ителде һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләренә ярдәм итү максатларында алар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган вәкаләтләрен билгели. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасының Халык сәнгать һөнәрләре сәнгать-эксперт советын төзү каралган, аның карарлары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә эшләнә торган әйберләр халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре эшләнмәләренә кертелә, Татарстан Республикасында халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләренең традицион көнкүреш урыннары билгеләнә.

«Китапханә эше турында» 1994 елның 29 декабрендәге 78-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кабул ителгән «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 1998 елның 21 октябрендәге 1818 номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба — 1818 номерлы Закон) китапханә эшен оештыруның гомуми мәсьәләләрен, дәүләт, гражданнар, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар арасында Татарстан Республикасында китапханә эше өлкәсенә караган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

1818 номерлы Законда Татарстан Республикасының китапханә эше өлкәсендәге дәүләт сәясәте нигезләре, дәүләтнең китапханә эшен үстерүдәге йөкләмәләре, Татарстан Республикасында китапханә эшчәнлеген башкару нигезләре, китапханәләрнең һәм алардан файдаланучыларның хокуклары һәм бурычлары билгеләнгән.

1818 номерлы Закон нигезләмәләрендә Татарстан Республикасы Милли китапханәсенә милли һәм республика, Россия һәм чит ил матбугатының баш дәүләт китап саклагычы, китапханә-мәгълүмат һәм фәнни-тикшеренү учреждениесе, мәдәни, библиографик, методик үзәк статусы беркетелгән. Татарстан Республикасы Милли китапханәсе фонды мемориаль әһәмияткә ия, республиканың мәдәни һәм фәнни байлыгы документларының киләчәк буыннар өчен сакланып калуын тәэмин итә.

1818 номерлы Законда китапханә өлкәсе хезмәткәрләренә социаль ярдәм чарасы буларак китапханә хезмәткәрләренә тиешле

ну һәм популярлаштыру өлкәсендәге вәкаләтләре билгеләнгән, Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау гамәлләре санап кителгән, республика әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларын яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын бердәм мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) реестрына кертү тәртибе, төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларында һәм җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларында мәгълүмат бирүче язулар һәм билгеләр урнаштыру тәртибе, мәдәни мирас объектларының торышына дәүләт контролен гамәлгә ашыру, юк ителгән мәдәни мирас объектларын торгызу тәртибе билгеләнгән.

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 30 һәм 38 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында мәдәни мирас объектын саклап калу буенча эшләр башкаруга рөхсәт һәм йөкләмә алу өчен кирәкле документлар кабул итүне һәм мәдәни мирас объектын саклап калу буенча эшләр башкаруга рөхсәт һәм йөкләмә бирүне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша гамәлгә ашыру мөмкинлеге каралган.

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән тарихи җирлек чикләрендәге эшчәнлекне җайга сала торган нигезләмәләр үзгәртелде, аерым алганда, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының мәдәни мирас объектларын саклап калу, файдалану һәм популярлаштыру өлкәсендәге вәкаләтләренә Татарстан Республикасы тарихы һәм мәдәнияте өчен аерым әһәмияткә ия тарихи җирлекләр исемлеген, төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлекне саклау предметын, төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрен раслау, төбәк (республика) әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата әзерләнгән генераль планнар проектларын, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектларын килештерү кертеп каралды.

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 13 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән археологик мирас объектларын, археологик предметларны табуга һәм саклап калуга кагылышлы мәсьәләләр өстәмә рәвештә җайга салынды.





сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

Дәүләт Советында федераль законнарның үзгәрешләрен мониторинглау да алып барыла. Татарстан Республикасы законнарына Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга тәңгәлләштерүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертүне таләп итә торган үзгәрешләр федераль законнарга кертелгән очракта Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе бәяләмә әзерли, аны тиешле федераль закон үз көченә кергән көненнән 14 көннән дә соңга калмыйча тапшыру Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 85 статьясында махсус каралган. Шуңа бәйле рәвештә Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсе белгечләре басылып чыккан федераль законнарга анализ ясый һәм тиз арада республика законнарын үзгәртү кирәклеге турында Дәүләт Советы җитәкчелегенә хәбәр итә.

Республика закон актларын үз вакытында федераль нормаларга тәңгәлләштерү зарурлыгы әһәмиятле булып кала. Яңа гына кабул ителгән федераль законнарга гына түгел, элек кабул ителгән актларга да анализ ясалырга тиеш.

Татарстан Республикасы законнарын коррупция барлыкка килү мөмкинлегенә мониторинглау да мөһим өлеш булып тора. Хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру Татарстан Республикасында 2004 елдан бирле башкарыла. 2004 елның октябрендә Дәүләт Советы һәм «Россия Федерациясе Хисап палатасының Системалы анализлауның дәүләт фәнни-тикшеренү институты» дәүләт фәнни учреждениесе Дәүләт хакимияте органнарында һәм җирле үзидарә органнарында коррупция барлыкка китерерлек һәм таратырлык хокукый шартларны кисәтү һәм бетерү өлкәсендәге хезмәттәшлек турында килешүгә имза салдылар. Шушы максатларда Дәүләт Советы Президиумы «Татарстан Республикасы законнары проектларына экспертиза ясау турында» 2004 елның 18 ноябрендәге 589-III ДС номерлы карарын кабул итте, анда закон проекты эше вакытында закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектларга Дәүләт Советына кертелә торган Татарстан Республикасы законнары проектларының аерым статьяларындагы һәм нигезләмәләрендәге коррупция барлыкка килү мөмкинлегенә аеруча игътибар бирү тәкъдим ителә.

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон белән органнар, оешмалар, вазыйфаи затлар тарафыннан үзләре кабул иткән норматив хокукый актларга (норматив хокукый актлар проектларына) хокукый экспертиза уздырганда һәм аларны кул-

лануны мониторинглауда аларга коррупциягә каршы экспертиза уздыру каралды. Шуңа бәйле рәвештә коррупциоген факторларны бетерү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы нигезендә Татарстан Республикасының һәр закон проектына Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсендә коррупциягә каршы экспертиза уздырыла.

Дәүләт Советы каравында булган Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы прокуратурасына җибәрү тәҗрибәсе үзенең нәтиҗәлелеген раслады. Прокуратура искәрмәләре законнар проектларын кабул итүгә әзерләү стадиясендә исәпкә алына.

Федераль законнар проектлары белән эшләүгә аерым игътибар бирергә кирәк. Еш кына республика законнарына үзгәрешләр әзерләү эшен алдан, Россия Федерациясе Президенты тарафыннан тиешле закон актына имза салынганчы ук башларга да мөмкин. Мәсәлән, Россия Федерациясе Президенты һәм Хөкүмәте тарафыннан кертелгән закон чыгару инициативалары, кагыйдә буларак, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе тарафыннан, проектта тәкъдим ителә торган концепциягә зур үзгәрешләр кертмичә генә, кыска вакытларда карала һәм кабул ителә. Мондый законнар проектларын мониторинглау һәм мониторинг нәтиҗәләре белән киң даирәнең (беренче чиратта башкарма хакимиятнең тармак органнарының, җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый институтларның) танышу мөмкинлеге булуы тиешле закон актларын тиз арада әзерләү өчен шартлар тудырачак дип уйлыйбыз.

Федераль законнарга йогынты ясау алымнарының берсе – «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 26.4 статьясы нигезендә бәяләмәләр әзерләү. Федераль закон таләпләре нигезендә закон проекты буенча субъектның закон чыгару һәм башкарма хакимияте органнары үз бәяләмәләрен тапшырган очракта Россия Федерациясе субъекты шушы закон проекты буенча фикерен белдергән дип санала.

Бу юнәлештәге эш активлаштырылырга тиеш дип уйлыйбыз. Закон проектлары буенча бәяләмәләрне тапшыру сроклары закон проектларын парламент утырышына чыгарырга мөмкинлек биргән очракта, алар барысы да каралырга тиеш. Бу Татарстан Республикасына федераль закон проекты буенча үз фикерен





руны тәэмин итә һәм аннан соңгы законнар өчен нигез булып тора.

1705 номерлы Закон гражданнарның мәдәни эшчәнлеккә һәм мәдәни ядкарьләрдән иркеле файдалана алуга конституциячел хокукларын тәэмин итүгә һәм яклауга, татар милли мәдәниятен, Татарстан Республикасының күпмилләтле халкы мәдәниятен үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелә һәм Татарстан Республикасы территориясендә мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмалары һәм учреждениеләре эшчәнлегенең хокукый нигезен тәшкил итә.

1705 номерлы Законда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының мәдәният өлкәсендәге компетенциясе, шулай ук күрсәтелгән өлкәдә икътисадый җайга салу механизмы, иҗади хезмәткәрләрнең һәм мәдәният хезмәткәрләренең статусы, аларга социаль ярдәм күрсәтү чаралары билгеләнә, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендәге эшчәнлекне грантлар исәбеннән гамәлгә ашыру мөмкинлеге карала.

Мәдәният хезмәткәрләренә социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлтелгән нигезләмәләрдән Татарстан Республикасы карамагында булган мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмалары (учреждениеләре) җитәкчеләренә һәм белгечләренә тиешле еллар эшләгән өчен өстәмә түләүне белгечлек буенча эш стажына карап билгеләүне ассызыкларга мөмкин. Вазыйфа окладыннан аларның күләме түбәндәгечә була: 5 елдан алып 10 елга кадәр эш стажы булганда – 20 процент, 10 елдан алып 15 елга кадәр – 25 процент, 15 елдан алып 20 елга кадәр – 30 процент, 20 елдан алып 25 елга кадәр – 35 процент, 25 ел һәм аннан күбрәк булганда – 40 процент.

Татарстан Республикасында «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 60-ТРЗ номерлы Закон) гамәлдә булуы тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне саклауны тәэмин итү максатларын күздә тота.

60-ТРЗ номерлы Законда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, шул исәптән Татарстан Республикасы ядкарьләрен саклау буенча дәүләт органының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының мәдәни мирас объектларын дәүләт тарафыннан саклау, саклап калу, файдала-

Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнарының төп бурычлары түбәндәгеләр:

ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, социаль яклауга мохтаҗ балигъ булмаганнарга уңай тормыш һәм тәрбия шартлары тәэмин итү, аларны карауны, тәрбияләүне һәм укытуны тикшереп тору;

суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган затларга һәм сәламәтлеге аркасында опекага, попечительлеккә һәм кайгыртуга мохтаҗ хокукка сәләтле балигъ булган за-тларга уңай тормыш шартлары тәэмин итү;

балигъ булмаганнарның, шулай ук суд тарафыннан хокукка сәләтсез дип яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган затларның һәм сәламәтлеге аркасында үз хокукларын мөстәкыйль гамәлгә ашыра алмый һәм яклый алмый, бурычларын үти алмый торган хокукка сәләтле балигъ булган затларның мөлкәти һәм мөлкәти булмаган шәхси хокукларын, закон белән саклануы мәнфәгатьләрен яклау;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән опека һәм попечительлек органнарына йөкләнгән башка бурычлар.

8-ТРЗ номерлы Закон нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең түбәндәге органнары Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары булалар:

мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы органнар — балигъ булмаган затларга карата;

сәламәтлек саклауга идарә итүне гамәлгә ашыручы органнар — суд тарафыннан хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикле дип танылган затларга карата;

социаль яклау органнары — сәламәтлеге аркасында кайгыртуга мохтаҗ хокукка сәләтле затларга карата.

Җирле үзидарә органнары федераль законнар нигезендә опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруда катнашу хокукына ия.

### Мәдәният, фән һәм мәгариф турындагы законнар

Татарстан Республикасында мәдәният өлкәсендәге эшчәнлекне хокукый җайга сала торган нигез акт — 1992 елның 9 октябрендәге 3612-1 номерлы Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә таянып кабул ителгән «Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба — 1705 номерлы Закон) Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт мәдәният сәясәтен тормышка ашы-





белдерергә ярдәм итәчәк, ахыр чиктә, бу республиканың үз законнары торышында да чагылачак.

Татарстан Республикасы законнарына турыдан-туры кагыла торган тагын бер мәсьәлә — җирле үзидарә органнарының закон чыгару процессында катнашуы. Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясы нигезендә җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукы бирелгән, кызганычка каршы, алар аннан җитәрлек дәрәҗәдә актив файдаланмый.

Шул ук вакытта бер үк дәрәҗәдә дәүләт һәм муниципаль мәнфәгатьләрне исәпкә ала торган балансны законнар булдыру җирле үзидарә органнарының закон чыгару хокукы инициативасын гамәлгә ашыруда актив катнашуыннан башка мөмкин түгел. Җирле үзидарә органнары белән конструктив диалог алып барырга, закон актлары проектларын әзерләгәндә аларга консультатив һәм методик ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә кирәк.

II БҮЛЕК

## ДӘҮЛӘТ КОРЫЛЫШЫ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЗАКОННАР

### Татарстан Республикасының дәүләт төзелеше турындагы законнар

1990 елның 30 августында Татарстан АССР Югары Советы, автономияле республика статусының аның күпмилләтле халкының киләчәктә сәяси, икътисадый, социаль һәм рухи үсеше мәнфәгатьләренә туры килмәвен билгеләп, демократик хокукый дәүләт төзергә омтылып, «Татарстан Совет Социалистик Республикасы дәүләт суверенлыгы турында» 1990 елның 30 августындагы 334-XII номерлы Татарстан ССР Декларациясе (алга таба — Дәүләт суверенитеты турындагы декларация) кабул итте, анда республиканың дәүләт суверенитетын игълан итте һәм республиканы Татарстан Совет Социалистик Республикасы — Татарстан Республикасы дип үзгәртте.

1990 елгы Дәүләт суверенитеты турындагы декларация нигезендә 1978 елгы Татарстан АССР Конституциясенә үзгәрешләр кертелде, бу үзгәрешләр Татарстан ССР — республиканың күпмилләтле барлык халкы ихтыярын һәм мәнфәгатьләрен чагылдыручы суверен демократик дәүләт, дәүләт суверенитеты — Татарстан ССРның аерылгысыз хасияте дигән нигезләмәне беркетте.

Дәүләт суверенитеты турындагы декларация 1992 елгы Татарстан Республикасы Конституциясен эшләү, республика законнарын үстерү, «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» 1994 елның 15 февралендәге Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы Шартнамәсен (алга таба — Эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында шартнамә) төзү өчен нигез булды.

Алда атап үтелгән Татарстан Республикасы юридик документлары нигезендә Татарстан Республикасы Эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында шартнамә нигезендә Россия Федерациясе белән ассоциацияләшкән суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты буларак билгеләнде. Татарстан Республикасы Конституциясенең 59 статьясында Татарстан Республикасы үз дәүләти-хокукый статусын мөстәкыйль билгели, сәяси, икътисадый, социаль-мәдәни корылыш мәсьәләләрен мөстәкыйль хәл итә дигән норма беркетелде.





күрсәтүгә бәйле барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала һәм Татарстан республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының торакка конституциячел хокукын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән.

2443 номерлы Закон билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләргә торак урынын сатып алу өчен кире кайтару, ташламалы һәм вакытлы нигезләрдә финанс чаралары бирү йә төзелешне төгәлләү һәм (яисә) яшь гаиләнең торак урынын реконструкцияләү өчен финанс чаралары бирү юлы белән дәүләт ярдәмен күрсәтүне күздә тота.

Яшь гаиләгә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен бүлеп бирелә торган финанс чараларының күләме 400 мең сумнан артык була алмый.

«Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 6 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме чараларын башкаручы буларак вәкаләтле оешма эшчәнлегенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртибе нигезләнә торган норма төшереп калдырылды.

Күрсәтелгән чараларны башкаручы вәкаләтле оешма эшчәнлеге өчьяклы шартнамәләргә таянып башкарыла, алар республика башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы һәм җирле үзидарә органнары белән төзелә. Күрсәтелгән шартнамәдә торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме чараларын башкару буенча якларның хокуклары һәм бурычлары күрсәтелә.

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба — 8-ТРЗ номерлы Закон) гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау максатларында Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрен җайга сала.

Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнарының хокукый нигезен Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Гаилә кодексы, 8-ТРЗ номерлы Закон, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының опека, попечительлек һәм патронаж мәсьәләләрен җайга салучы башка норматив хокукый актлары тәшкил итә.

ләр кертү хакында» 2013 елның 11 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, шулай ук иҗтимагый мөнәсәбәтләрне гамәлгә ашыруда яшь гражданнарны катнаштыру максатларында яшь гражданнарның иң түбән яше итеп 14 яшь билгеләнде. Шул рәвешле, 1983-XII номерлы Законга «балалар иҗтимагый берләшмәләре» дигән термин кертелде.

«Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 20 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында дәүләт ярдәме күрсәтелә ала торган яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре исемлеге бирелде. Анда мәнфәгатьләр уртаклыгы нигезендә берләшкән 30 яшькә кадәрге гражданнарның, шулай ук уртак эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен берләшкән 18 яшькә кадәрге һәм балигъ булган гражданнарның төбәкара, республика һәм җирле яшьләр иҗтимагый берләшмәләре бар.

Дәүләт ярдәмен алу өчен ике шартны үтәргә кирәк. Берләшмә юридик зат буларак оешкан һәм дәүләт теркәве үткән вакыттан кимендә бер ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә эшләгән булырга тиеш. Берләшмәдә кимендә 50 әгъза исәптә торырга тиеш. Дәүләт ярдәме сорап мөрәҗәгать иткән берләшмәнең билгеләнгән таләпләргә туры килүе Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең яшьләр эшләре буенча вәкаләтле органы тарафыннан ачыклана.

Вәкаләтле орган шулай ук Дәүләт ярдәменнән файдалана торган яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең республика реестрын булдыра һәм алып бара. Күрсәтелгән берләшмәләрне реестрга кертү алар тарафыннан язмача гариза һәм берләшмәнең расланган таләпләргә туры килүен раслый торган документлар тапшырылганнан соң 30 көн эчендә түләүсез гамәлгә ашырыла.

Реестрга кертелгән яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре ике елга бер тапкыр вәкаләтле органга үзләренең билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документлар тапшыра.

Республика реестрына яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсе турында кертелә торган белешмәләр исемлеге бәян ителде. Вәкаләтле орган әлеге белешмәләрне квартал саен дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру буенча федераль башкарма хакимият органына тапшыра.

«Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 2443 номерлы Закон) яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәмен





«Татарстан Совет Социалистик Республикасы исемен үзгәртү һәм Татарстан ССР Конституциясенә (Төп Законына) тиешле үзгәрешләр кертү турында» 1992 елның 7 февралендәге 1413-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Совет Социалистик Республикасы Татарстан Республикасы (Татарстан) дип үзгәртелде.

Татарстан Республикасы Югары Советы тарафыннан 1992 елның 6 ноябрендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Конституциясендә беренче мәртәбә Татарстан Республикасының демократик хокукый дәүләт буларак принциплары формалаштырылды, бу принциплар нигезендә дәүләт органнары эшчәнлеге башкарыла, аерым алганда, законнарның өстенлеге, аларның һичшиксез үтәлүе, закон чыгару, башкарма һәм суд хакимиятләренең бүленгән булуы принциплары гамәлгә ашырыла.

1992 елгы Татарстан Республикасы Конституциясе, иң югары социаль кыйммәт буларак, кеше хокукларының өстенлеге принцибын, үз мөнәсәбәтләрендә граждан белән дәүләтнең үзара җаваплылыгын, гомумтанылган принципларның һәм халыкара хокук нормаларының республика законнарыннан өстенлеген игълан итте.

Беренче мәртәбә Конституция Кеше хокукларының гомуми декларациясендә белдерелгән кешенең һәм гражданның төп хокукларын һәм ирекләрен беркетте.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы статусын Россия Федерациясе составындагы дәүләт буларак билгеләүче Татарстан Республикасының төп һәм мөһим хокукый акты булып элеккечә үк 1992 елгы Татарстан Республикасы Конституциясе кала, ул 2002 елның 19 апрелендәге Татарстан Республикасы Законында яңа редакциядә бәян ителде, аңа Татарстан Республикасының 2005 елның 14 мартындагы 55-ТРЗ номерлы, 2010 елның 30 мартындагы 10-ТРЗ номерлы, 2010 елның 22 ноябрендәге 79-ТРЗ номерлы һәм 2012 елның 22 июнендәге 40-ТРЗ номерлы законнары белән үзгәрешләр кертелде. Яңа редакциядәге Конституциядә Татарстан дәүләтчелеге турындагы төп нигезләмәләр сакланып калды.

Россия Федерациясе Конституциясенең 5, 66 һәм 73 статьяларының нигезләмәләре буенча республика дәүләт булып тора, аның статусы Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе белән билгеләнә, ә Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының эшләр бүлешү буенча Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләрдән һәм Россия Федерациясе вәкаләтләреннән тыш республика Россия Федерациясе субъекты буларак дәүләт хакимиятенең бөтен

тулылыгына ия. Шуның нигезендә Татарстан Республикасы Конституциясендә, элекке редакциясеннән аермалы буларак, суверенитет билгеләмәсенең яңа рәвеше бирелде: Татарстан Республикасы суверенитеты Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының эшләр бүлешү буенча Россия Федерациясе карамагындагы мәсьәләләрдән һәм Россия Федерациясе вәкаләтләреннән тыш дәүләт хакимиятенең (закон чыгару, башкарма һәм суд) бөтен тулылыгына ия булуда чагыла һәм Татарстан Республикасының аерылгысыз хасияте була.

Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасында дәүләт телләре дип тигез хокуклы татар һәм рус телләрен атады, алар Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, дәүләт учреждениеләрендә бертигез нигезләрдә кулланыла.

Татарстан Республикасы Конституциясендә Татарстан Республикасы гражданлыгы турындагы нормалар да бар. Татарстан Республикасы гражданлыгы институты «Россия Федерациясе гражданлыгы турында» 2002 елның 31 маендагы 62-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән шундый ук хокукларның һәм бурычларның өстәмә күләмен билгеләүне күз алдында тотмый, ә кеше белән Татарстан Республикасы арасындагы хокукый бәйләнешне билгеләү өчен хезмәт итә һәм республикадагы хокук һәм хакимият чыганагына күрсәтүче атрибут буларак кирәк.

Татарстан Республикасы Конституция судының республика гражданлыгы институты буенча 2003 елның 30 маендагы 9-П номерлы карарында белдерелгән хокукый позициясе Татарстан Республикасы гражданлыгы турындагы нигезләмәнең Россия Федерациясе гражданлыгының беренчеллеген һәм төп характерын танудан, Россия Федерациясе гражданлыгы белән Татарстан Республикасы гражданлыгының өзелмәс хокукый үзара бәйлелегеннән килеп чыгуын белдерә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасы гражданлыгын алу өчен Россия Федерациясе гражданының Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәве шарт булуны билгели. Татарстан Республикасы гражданлыгы, Россия Федерациясе гражданлыгыннан килеп чыкканга күрә, бер үк вакытта Россия Федерациясе гражданнары булган Татарстан Республикасы гражданнарының бердәм һәм тигез конституциячел хокукый статусын тануны белдерә, аның нигезендә Татарстан Республикасында гомумтанылган принципларга һәм халыкара хокук нормаларына, Россия Федерациясе Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә нигезләнеп, кешенең һәм гражданның хокуклары һәм ирекләре танылa һәм гарантияләнә.





«Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 1983-XII номерлы Закон) Россия Федерациясендә дәүләт яшьләр сәясәтенең максатларыннан, принципларыннан һәм төп юнәлешләреннән чыгып Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп бурычларын, принципларын, төп юнәлешләрен һәм рәвешләрен билгели.

Дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның хокукый, социаль һәм оештыру шартлары һәм аларны гамәлгә ашыру гарантияләре билгеләнә. Халыкның башка иҗтимагый һәм социаль төркемнәре белән бергә балаларның һәм яшьләрнең социаль мөмкинлекләрен тигезләү чараларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән оештыру-хокукый чаралары системасы күрсәтелде.

1983-XII номерлы Законның бурычлары буларак шәхеснең ирекле үсүе өчен реаль шартлар һәм стимуллар тудыруны, яшь гражданнарның тормыш максатларын гамәлгә ашыруны, аларны актив социаль-икътисадый һәм сәяси эшчәнлеккә тартуны тәэмин итү билгеләнде. 1983-XII номерлы Закон республиканың дәүләт органнары, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре һәм яшь гражданнары арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга сала. 1983-XII номерлы Закон нигезләмәләре республика территориясендә яшәүче 14 яшьтән алып 30 яшькә кадәрге яшь гражданнарга (яшьләргә), шулай ук ата-аналарга һәм балаларны, яшьләрне тәрбияләүче затларга кагыла.

Әлеге Закон белән яшь гражданнарны хокукый һәм социаль яклау, аларның җаваплылыгы мәсьәләләре җайга салына. Яшь гражданнарның икътисадый мөстәкыйльлеген тәэмин итү һәм аларга ярдәм күрсәтү, яшьләр предприятиеләренә һәм яшьләр оешмалары эшчәнлегенә дәүләт ярдәме тәртибе билгеләнә.

1983-XII номерлы Законда республикада ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлеген булдыру һәм үстерү максатларында әлеге өлкәдә яшьләрнең башлангычына дәүләт ярдәме күрсәтү, шулай ук волонтер белгечләрне үз вакытында сыйфатлы итеп әзерләү каралган. Әлеге нигезләмәләр ихтыярый инициативаларның формаларын һәм берләшмәләрнең статусын күтәрә һәм ихтыярый эшчәнлекнең оештырылу рәвешләрен камилләштерәләр.

Ихтыярый эшчәнлек яшьләрнең үй-фикерләүләренә һәм социаль иҗатына киң мөмкинлекләр бирә торган өлкә булып тора, ул дәүләтнең социаль сәясәт максатларына ирешүгә һәм гражданнарның яшәү сыйфатын яхшыртуга яшьләрнең зур өлеш кертүләрен тәэмин итә.

«Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш-

Медицина таныклавы гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы кысаларында үткәрелү турындагы нигезләмә билгеләнде.

Балаларның опекуннары (попечительләре) булып торучы яисә булган һәм үзләренә йөкләнгән вазыйфаларын үтәүдән читләштерелмәгән затлар, баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алу өчен тиешле әзерлек узмаган очракта да, уллыкка алучылар булырга мөмкин.

Даими рәвештә читтә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына яисә чит ил гражданнарына уллыкка балалар бирү срогы ике тапкырга арттырылды (6 айдан 12 айга кадәр). Бу срок ятимнәр турында федераль белешмәләр банкына мондый балалар турында мәгълүмат кергән көннән исәпләнә.

Ата-ана хокукларын гамәлгә ашырганда, ата-аналарның (аларны алмаштыручы затларның) гаиләгә медицина, психологик, педагогик, юридик, социаль ярдәм күрсәтелүдә ярдәм алырга хокуклары бар. Әлеге ярдәмне күрсәткәндә булышлык итү шартлары һәм тәртибе социаль хезмәт күрсәтү турындагы законнар белән билгеләнә.

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы Россиянең башка регионына тапшыру турында нигезләмә билгеләнде. Татарстанда ятим баланы аны карап тору, тәрбияләү һәм укыту өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында баланың ихтыяҗларыннан чыгып урнаштырырлык ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешма булмаганда, бала башка регионның опека һәм попечительлек органнарына тапшырыла.

Кодекста кулланыла торган терминология Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында һәм мәгариф турында федераль законнарга туры китерелде.

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 110 һәм 114 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 30 июнендә 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны ачыклау һәм исәпкә алу механизмын камилләштерүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелде.

Ятимнәр турында актуальләштерелгән республика белешмәләр банкын булдыру карала. Опека һәм попечительлек органнары ятимнәрне ачыклаган очракта республика белешмәләр банкында беренчел исәпкә алу өчен мәгълүматны республика башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органына җибәрә. Бер үк вакытта федераль белешмәләр банкында исәпкә алу өчен мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган федераль башкарма хакимият органына җибәрелә.





Татарстан Республикасында дәүләт хакимиятен Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы судлары башкара. Татарстан Республикасында җирле үзидарә танылa һәм гарантияләнә, 2005 – 2006 елларда аңа оештыру һәм территориаль яктан реформа ясалды.

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы территориясенә республиканың административ-территориаль берәмлекләре буларак районнар һәм республика әһәмиятендәге шәһәрләр керә. Республика әһәмиятендәге шәһәр территориясе районнардан торырга мөмкин.

Татарстан Республикасы түбәндәге административ-территориаль берәмлекләрдән тора:

43 районнан – Әгерҗе, Азнакай, Аксубай, Актаныш, Алексеевск, Әлки, Әлмәт, Апас, Арча, Әтнә, Баулы, Балтач, Бөгелмә, Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Алабуга, Зәй, Зеленодольск, Кайбыч, Кама Тамагы, Кукмара, Лаеш, Лениногорск, Мамадыш, Менделеевск, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Нурлат, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Сарман, Спас, Тәтеш, Тукай, Теләче, Чирмешән, Чистай, Ютазы;

республика әһәмиятендәге 14 шәһәрдән – Азнакай, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Буа, Алабуга, Зәй, Зеленодольск, Казан, Лениногорск, Чаллы, Түбән Кама, Нурлат, Чистай.

Татарстан Республикасының башкаласы – Казан шәһәре.

Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше һәм аны үзгәртү тәртибе Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

Татарстан Республикасы Конституциясенең мөстәкыйль бүлекләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы турындагы (Дәүләт Советы биш елга сайлана һәм аңа Дәүләт Советы Рәисе җитәкчелек итә) нигезләмәләргә; Татарстан Республикасы Президенты турындагы (ул – дәүләт башлыгы, Татарстан Республикасының гомуми тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән гражданнар тарафыннан сайлана торган иң югары вазыйфаи заты була) нигезләмәләргә; Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма һәм боеру органы булып торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте хакындагы нигезләмәләргә; шулай ук суд хакимияте һәм прокуратура, җирле үзидарә, дәүләт символлары һәм Татарстан Республикасы башкаласы турындагы нигезләмәләргә багышлана.

Татарстан Республикасы Конституциясе «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы Шартнамәсен (алга таба – Шартнамә) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хокукый системасының состав өлеше дип таный.

«Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турындагы Шартнамәне раслау хакында» 2007 елның 24 июлендәге 199-ФЗ номерлы Федераль закон белән яңа Шартнамә расланды, ул элегрәк, 2007 елның 26 июнендә Мәскәү шәһәрендә Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин һәм Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиев тарафыннан имзаланды.

Шартнамә нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасының икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләренә бәйле мәсьәләләрне уртак хәл итүне күз алдында тота торган килешүләр төзиләр һәм әлеге проблемалар буенча Дәүләт Думасына тиешле закон проектларын кертәләр. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Россия Федерациясе Хөкүмәте белән килешү буенча ватандашларга дәүләт ярдәме күрсәтү һәм гомумән ярдәм итү хокукы, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына Россия Федерациясе гражданының гомумграждан паспортына Татарстан Республикасы дәүләт телендәге (татар телендәге) һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гербы төшерелгән өземтәсен бирү хокукы билгеләнде. Моннан тыш, Шартнамәдә Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты вазыйфасын биләүгә чыгарыла торган кандидатуралар өчен «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә өстәмә таләп – Татарстан Республикасы дәүләт телләренең икесен дә белү беркетелә, ул игълан итү тәртибендә билгеләнә. Шартнамәнең гамәлдә булу срогы – 10 ел. Шартнамә нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Шартнамәне гамәлгә ашыру чаралары планы расланды, анда Шартнамә нигезләмәләрен башкару өчен кирәкле федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары проектларын, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабине-





мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру рәвешләрен һәм тәртибен билгели.

Кодекс рәсми никах яше, өйләнешүгә каршы сәбәпләр, өйләнешүче затларга медицина тикшерүе, граждан хәле актларын теркәү органнарында һәм суд тәртибендә никахны өзү, граждан хәле актларын теркәү органнарында аерылышканда ир белән хатын арасында барлыкка килгән бәхәсләрне карау, ир белән хатынның хокуклары һәм бурычлары, ир белән хатын мөлкәтенең законлы һәм шартнамәчел режимы, йөкләмәләр буенча ир белән хатынның җаваплылыгы, ата-ананың һәм балаларның хокуклары һәм бурычлары, гаилә әгъзаларының алимент йөкләмәләре турындагы мәсьәләләрне җайга сала.

Кодекска аны федераль законнарга туры китерүгә бәйле үзгәрешләр кертелде (2013 елның 18 маендагы 34-ТРЗ, 2013 елның 13 июлендәге 60-ТРЗ, 2014 елның 11 апрелендәге 24-ТРЗ, 2014 елның 30 июнендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары).

Мәсәлән, «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 19 статьясына үзгәреш кертү турында» 2013 елның 18 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Кодекс аерылышу турында таныклык алырга мөмкин булган урыннарны өстәү өлешендә федераль законнарга туры китерелде. Хәзер ир белән хатын аерылышу турындагы таныклыкны үзләренең яшәү урыннары буенча да, өйләнешүне дәүләт теркәвенә алган урын буенча да алырга мөмкин.

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 141[1] статьясына үзгәреш кертү турында» 2013 елның 13 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән Татарстан Республикасында үз бурычларын түләүле нигездә үтәүче опекуннарга яисә попечительләргә тиешле түләү һәр опекага алынган бала өчен 2500 сумнан 3000 сумга кадәр арттырылды.

«Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 11 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасында балаларны уллыкка (кызлыкка) алу мәсьәләләре төгәлләштерелде.

Уллыкка алучылар, опекуннар (попечительләр) була алмый торган затларның өстәмә категорияләре билгеләнде. Болар: бер үк җенестәге затлар арасында төзелгән, мондый өйләнешү рөхсәт ителгән дәүләт законнары нигезендә өйләнешү дип танылган һәм теркәлгән берлектә торучы затлар, шулай ук күрсәтелгән дәүләт гражданнары булып торучы теләсә кайсы башка затлар.

да ата-аналарга (аларны алмаштыручы затларга) яисә балалар катнашында чаралар уздыручы затларга һәм (яисә) эчке эшләр органнарына хәбәр итү тәртибен, шулай ук мондый баланы аның ата-аналарына (аларны алмаштыручы затларга) яисә балалар катнашында чаралар уздыручы затларга йә, күрсәтелгән затлар булмаганда, аларның тору урынын ачыклау мөмкинлеге булмаганда яисә баланы кичекмәстән шушы затларга тапшыру өчен тоткарлык ясый торган башка шартлар булганда, баланы ул табылган урындагы социаль реабилитацияләүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләргә илтеп тапшыру тәртибен билгеләү.

Шулай ук 71-ТРЗ номерлы Закон белән балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерә торган урыннары һәм төнлә өлкәннәрдән башка балаларның булуы рөхсәт ителми торган җәмәгать урыннары билгеләнде.

71-ТРЗ номерлы Законда балигъ булмаганнарга булу тыела яисә чикләнә торган башка урыннар, мәдәни һәм бүтән җирле гореф-гадәтләрне исәпкә алып, шул исәптән балигъ булмаганнарның күзәтүчесез калуларын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый оешмалар, гражданнар тәкъдимнәре нигезендә, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының вәкиллекле органнары тарафыннан билгеләнергә мөмкин. Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрендә балигъ булмаганнарга булу тыела яисә чикләнә торган урыннар тиешле җирлекнең вәкиллекле органы тәкъдиме яисә ризалыгы белән билгеләнә.

Балигъ булмаганнарның булуы тыела яисә чикләнә торган башка урыннарны билгеләү турындагы тәкъдимнәрне бәяләү эксперт комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла, аның функцияләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре буенча республика комиссиясе башкара.

Татарстан Республикасы Гаилә кодексы (алга таба — Кодекс) никахлашуның, аны туктатуның һәм дөрес түгел дип тануның шартларын һәм тәртибен билгели, гаилә әгъзалары: ир белән хатын, ата-ана һәм балалар (уллыкка алучылар һәм уллыкка алынучылар) арасында, ә гаилә законнарында каралган очракларда һәм чикләрдә башка туганнар һәм бүтән затлар арасында мөлкәти булмаган һәм мөлкәти булган шәхси мөнәсәбәтләрне җайга сала, шулай ук ата-ана кайгыртуыннан





ты арасында Татарстан Республикасының икътисадый, экологик (углеводородларны чыгаруның геологик шартларын исәпкә алып нефть ятмаларыннан озак файдалану нәтиҗәсендә), мәдәни һәм башка үзенчәлекләренә бәйле мәсьәләләрне уртак хәл итүне күз алдында тота торган килешүләр проектларын әзерләү карала.

«Татарстан Республикасы Конституциясен гамәлгә кертү тәртибе турында» 1992 елның 30 ноябрендәге 1665-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы 1992 елның 6 ноябрендәге Татарстан Республикасы Конституциясен басылып чыккан көненнән гамәлгә кертү тәртибен билгеләде, моңа кайбер нигезләмәләр керми, алар өчен үз көчләренә керүнең махсус тәртибе каралды. Конституциянең кайбер нормалары, аерым алганда, Татарстан Республикасы Югары Советының Закон чыгару Собраниесе һәм Татарстан Республикасының Тикшерү комитеты турындагы Конституция статьяларының нигезләмәләре үз көчләренә керми калды. Аларны гамәлгә кертү махсус законнар кабул итүне таләп итә иде.

Әлеге Законның 11 статьясында шулай дип билгеләнде: кабул ителгән яңа Татарстан Республикасы Конституциясен исәпкә алып, Россия Федерациясе — Россия Югары Советына Россия Федерациясенең Төп Законында Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясе — Россия арасында шартнамәчел-конституциячел мөнәсәбәтләр турындагы нигезләмәләрне конституцияләштерү хакындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә.

Дәүләт хакимиятенең вәкиллекле һәм башкарма органнары системасын камилләштерүнең конституциячел нигезләре салынган һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органнарына һәм җирле үзидарә органнарына сайлаулар билгеләү һәм уздыру өчен төп закон булган «Татарстан Республикасы Конституциясенә дәүләт хакимиятенең вәкиллекле һәм башкарма органнарын реформалаштыруга бәйле рәвештә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 1994 елның 30 ноябрендәге 2243-XII номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, «Татарстан Республикасы законнарында парламент исемен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү турында» 1995 елның 30 мартындагы 18 номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде. Әлеге Закон белән дәүләт хакимиятенең иң югары вәкиллекле, закон чыгару һәм тикшереп тору органы исемен Татарстан Республикасы законнарында Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең иң югары вәкиллекле, закон чыгару һәм тикшереп тору органы исеме була-

рак «Татарстан Республикасы Югары Советы» сүзләре «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы» сүзләренә алмаштырылды.

«Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» 1999 елның 14 июлендәге 2284 номерлы Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасының суверенитетын, Татарстан халкының үзенчәлеген һәм традицияләрен белдерә торган Татарстан Республикасы дәүләт символлары тасвирламасын, шулай ук аларны рәсми куллану очракларын һәм тәртибен билгеләде. Татарстан Республикасы дәүләт символлары – Татарстан Республикасы Дәүләт гербы, Татарстан Республикасы Дәүләт флагы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гимны.

Татарстан Республикасының Дәүләт гербы кояш җирлегендә алгы уң аягын бераз күтәргән, янтавында түгәрәк калканы булган канатлы барс сурәтеннән гыйбарәт. Кояш түгәрәге татар милли бизәге төшерелгән, аскы өлешенә «Татарстан» дип язылган кайма белән уратып алынган, барс канатларында җидешәр каурый, калкандагы розеткада сигез аерча бар.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербының төсле сурәтендә кояш – кызыл (кадмий ачык кызыл), барс, аның канатлары һәм калкандагы розетка – ак, кайма – яшел (кобальт ачык яшел), калкан, каймадагы бизәк һәм «Татарстан» язмасы – алтын төсләрдә.

Татарстан Республикасының Дәүләт флагы яшел, ак һәм кызыл төстәге аркылы буйлардан торган турыпочмаклы тукымадан гыйбарәт. Ак буй флаг киңлегенең 1/15 өлешен тәшкил итә һәм бертигез киңлектәге яшел (кобальт ачык яшел) һәм кызыл (кадмий ачык кызыл) төсләрдәге буйлар арасында урнашкан. Яшел буй – өстә. Флагның киңлеге озынлыгына карата 1:2 нисбәтендә.

Татарстан Республикасы Дәүләт гимны – композитор Рөстәм Яхинның музыкаль әсәре.

2011 елның 15 декабрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы 2012 елда Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына иҗади конкурс уздыру турында карар кабул итте. Әлеге карар белән конкурс уздыруны оештыру максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстының иң яхшы проектына конкурс уздыру комиссиясе төзелде.

2012 елда уздырылган конкурста җиңүче – шагыйрь Рамазан Байтимеровның татар телендәге шигыре, рус теленә – Филипп Пираев тәрҗемәсе.

2013 елның 18 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән «Татарстан Республикасы дәүләт сим-





Шуңа бәйле рәвештә гражданнарның керемнәрен арттыру максатларында, 31-ТРЗ номерлы Законда яшәү минимумын исәпкә алып билгеләнгән социаль ярдәм чараларына өстәп, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Татарстан Республикасында, минималь куллану бюджетыннан чыгып, социаль ярдәм чараларын билгеләү мөмкинлеге күздә тотыла.

31-ТРЗ номерлы Законда шулай ук республикада минималь хезмәт хакы күләме минималь куллану бюджеты күләме хакыннан кимрәк була алмый дип билгеләнә. Ләкин хезмәт законнары нигезендә Россия Федерациясе субъектында минималь хезмәт хакы күләме Россия Федерациясе субъекты законы белән түгел, ә региональ килешү белән билгеләнә, 31-ТРЗ номерлы Законда минималь хезмәт хакы күләмен этаплап арттыру тәртибе һәм сроклары ел саен Татарстан Республикасында минималь хезмәт хакы турында республика килешүе белән билгеләнәчәк.

**Гаилә һәм яшьләр сәясәте турындагы законнар**

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 71-ТРЗ номерлы Закон) «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 14[1] статьясы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чараларын билгеләде. Аерым алганда, түбәндәге чаралар күздә тотылган:

сексуаль характердагы товарлар реализацияләү өчен генә билгеләнгән объектларда (территорияләрдә, биналарда), сыра ресторларында, шәраб барларында, сыра барларында, чәркәханәләрдә, бары тик алкоголь продукциясен, сыра һәм аның нигезендә әзерләнә торган эчемлекләрне реализацияләү өчен генә билгеләнгән урыннарда, балаларның физик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерерлек башка урыннарда балаларның (18 яшькә кадәрге затларның) булуына юл куймау чаралары;

төнлә өлкәннәрдән башка кайбер җәмәгать урыннарында балаларның (18 яшькә кадәрге затларның) булуына юл куймау чаралары;

югарыда күрсәтелгән урыннарда, билгеләнгән таләпләрне бозып, бала күренгән очракта, баланың шунда күренүе турын-

һәм икмәк продуктлары, бәрәңге, үсемлек мае, маргарин һәм башка майлар буенча куллану нормасы киметелде. Җиләк-җимешләрне куллану нормасы ике тапкырдан да күбрәккә арттырылды.

Азык-төлек булмаган товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр бәясенең куллану кәрзиненә керә торган азык-төлек продуктларына карата бәясе 45 процент һәм 55 процент чагыштырмасында билгеләнде.

Бу Закон социаль әһәмияткә ия һәм кешенең сәламәтлеген саклау һәм яшәешен тәэмин итү өчен кирәкле азык-төлек продуктларының минималь җыелмасын, шулай ук бәясе азык-төлек продуктларының минималь җыелмасы бәясенә карата билгеләнә торган башка товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең минималь җыелмасын билгели.

Моннан тыш, Татарстан Республикасында хокукый нигезе «Татарстан Республикасында минималь куллану бюджеты турында» 2008 елның 23 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 31-ТРЗ номерлы Закон) белән билгеләнгән минималь куллану бюджеты кебек категория дә кулланыла. 31-ТРЗ номерлы Закон белән Татарстан Республикасында минималь куллану бюджеты нигезендә халыкның тормыш сыйфатын һәм керемнәрен арттыруга юнәлдерелгән, халыкның тормыш дәрәҗәсен бәяләүнең яшәү минимумыннан югарырак булган социаль стандарт билгеләнә. Минималь куллану бюджеты системасы халык арасында ярлыларны гына түгел, аз тәэмин ителгәннәрне, чагыштырмача тәэмин ителгәннәрне һәм агымдагы куллану дәрәҗәсе буенча аерылып тора торган бай катламны ачыкларга мөмкинлек бирә.

Минималь куллану бюджеты кешенең актив физик халәтен саклап калу һәм эшләвен тәэмин итү өчен кирәкле азык-төлек продуктларының, башка товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең балансланган җыелмасының, шулай ук мәҗбүри түләүләрнең һәм җыемнарның бәяләрдә күрсәтелгән зурлыгыннан гыйбарәт. 31-ТРЗ номерлы Законда шундый гарантия билгеләнә: минималь куллану бюджеты яшәү минимумыннан түбәнрәк була алмый.

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 13 июлендәге 61-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән яшәү минимумына яңа билгеләмә бирә. Бу – куллану кәрзиненең бәя хакы, шулай ук мәҗбүри түләүләр һәм җыемнар.

31-ТРЗ номерлы Законда минималь куллану бюджеты составын билгеләү принциплары һәм тәртибе билгеләнә, ул яшәү минимумы составыннан һәм, димәк, Татарстан Республикасында куллану кәрзине составыннан зуррак, чөнки хезмәткә сәләтле хезмәткәрнең Россия Федерациясендә хезмәт өчен түләүнең минималь күләмен билгеләү нигезенә салынган яшәү минимумы эшче көчне торгызу өчен кирәкле яшәү чаралары хакын тулысынча тәэмин итә алмый.





воллары турында» Татарстан Республикасы Законына Татарстан Республикасы Дәүләт гимны текстын раслау өлешендә тиешле үзгәрешләр кертелде.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербы эталоны һәм Татарстан Республикасы Дәүләт флагы эталоны Дәүләт Советында саклана.

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше мәсьәләләрен һәм аны үзгәртү тәртибен җайга сала.

«Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 17 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Законның 32 статьясыннан 25 яңа редакциядә бәян ителде.

Закон новеллалары нигезендә Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше дигәндә Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләренең (алга таба – административ-территориаль берәмлекләр) дә, торак пунктларның да системасыннан гыйбарәт булган Татарстан Республикасының территориаль оештырылуы аңлашыла.

Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләренә бары тик Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон нигезендә билгеләнгән хокукый статусы булган, дәүләт идарәсе функцияләрен гамәлгә ашыру өчен территориаль аерымланган территориаль берәмлекләр – районнар, республика әһәмиятендәге шәһәрләр һәм республика әһәмиятендәге шәһәрләрдәге районнар кертелә башлады.

Билгеләп үтелгәнчә, Татарстан Республикасы районнардан һәм республика әһәмиятендәге шәһәрләрдән тора, аларның исемлеге Татарстан Республикасы Конституциясе белән билгеләнә.

Район дигәндә Татарстан Республикасы Конституциясендә билгеләнгән, үз чикләрендә үзара территориаль һәм административ яктан бәйле торак пунктларны берләштерүче административ-территориаль берәмлек аңлашыла, моңа республика әһәмиятендәге шәһәрләр керми.

Республика әһәмиятендәге шәһәрләр территориаль яктан шәһәрдәге районнарга бүленергә мөмкин. Административ-территориаль яктан шәһәрдәге районнарга бүленүче республика әһәмиятендәге шәһәрләр һәм аларның составына керүче районнар исемлеге «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» Татарстан Республикасы Зако-

ны белән билгеләнә. Әлеге Законның 7 статьясындагы 4 өлеше нигезендә районнарга бүленүче республика әһәмиятендәге шәһәр булып бердәнбер шәһәр, Татарстан Республикасы башкаласы — Казан шәһәре тора. Казан шәһәре составына Авиатөзелеш, Вахитов, Киров, Мәскәү, Яңа Савин, Идел буе һәм Совет районнары керә.

Административ-территориаль төзелешне үзгәртүнең Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, муниципаль районнарның, шәһәр округларының вәкиллекле органнары инициативасы буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан башкарылуы «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә. Мондый үзгәреш Татарстан Республикасы законы белән, ә күрсәтелгән Законда каралган очракларда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары рәвешендә рәсмиләштерелә.

Административ-территориаль берәмлекләр һәм Татарстан Республикасының торак пунктлары Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләре һәм торак пунктлары реестрында исәпкә алынырга һәм теркәлергә тиеш. Күрсәтелгән Реестрның эчтәлеге һәм аны алып бару тәртибе, шулай ук әлеге Реестрны алып баручы орган Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә. «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2008 елның 12 маендагы 205-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләре һәм торак пунктлары реестрын алып баручы вәкаләтле орган буларак билгеләнде. Реестрның эчтәлеге һәм аны алып бару тәртибе турындагы нигезләмә Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 29 сентябрендәге 460-ПУ номерлы Указы белән расланды. 2014 елның 4 февраленә Татарстан Республикасының административ-территориаль берәмлекләре һәм торак пунктлары реестрына 3117 торак пункт кертелде, шулардан 40ы — шәһәр торак пунктлары, 3077се — авыл торак пунктлары.

Әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр «Татарстан АССРның административ-территориаль төзелеше мәсьәләләрен хәл итү тәртибе турында» 1983 елның 10 ноябрендәге 2647-X номерлы Татарстан АССР Югары Советы Президиумы Указы гамәлдә булды, аның нигезләмәләре актуаль булмаганга күрә алар үз көчләрен югалткан дип танылды.





92-ТРЗ номерлы Закон нигезендә Татарстан Республикасында бер кешегә исәпләнгән һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләме квартал саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана. Татарстан Республикасында бер кешегә исәпләнгән һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы турындагы белешмәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының рәсми басмаларында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.

Татарстан Республикасында бер кешегә исәпләнгән һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләме квартал саен куллану кәрзине нигезендә билгеләнә.

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 13 июлендәге 61-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында куллану кәрзине төшенчәсе төгәлләштерелә, аның буенча куллану кәрзине дигәндә кеше сәламәтлеген саклау һәм аның яшәешен тәэмин итү өчен кирәкле азык-төлек продуктларының, шулай ук азык-төлек булмаган товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең минималь җыелмасы аңлашыла, аларның хакы азык-төлек продуктларының минималь җыелмасы хакына нисбәттә билгеләнә. Ул азык-төлек продуктларын натураль күләмнәрдә нормалар буенча, башка товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне азык-төлек продуктлары бәясеннән чыгып билгеләү мөмкинлеген бирә.

Россия Федерациясе буенча тулаем һәм Россия Федерациясе субъектларында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча куллану кәрзине «Россия Федерациясендә куллану кәрзине турында» Федераль закон нигезендә кимендә биш елга бер тапкыр билгеләнә. Әлеге норманы гамәлгә ашыру максатларында «Татарстан Республикасында куллану кәрзине турында» 2013 елның 13 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде, аның белән Татарстан Республикасында куллану кәрзине составы һәм күләмнәре (натуралата күрсәткечләрдә) билгеләнде. «Татарстан Республикасында куллану кәрзине турында» 2008 елның 7 августындагы 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы үз көчен югалткан дип танылды.

Азык-төлек продуктларының минималь җыелмасы нормалары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 28 гыйнварындагы 54 номерлы карары белән расланган Методик рекомендацияләрнең VIII зонасына туры китерелде. Туклану сыйфатын яхшырту максатында елга бер кешегә уртача ит, балык, сөт продуктларына, йомыркага, яшелчәләргә, җиләк-җимешләргә һәм яңа җитештерелгән яисә җыеп алынган продуктларга карата куллану нормасы арттырылды

Өйгә барып социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә, хезмәт күрсәтүнең ярымстационар һәм стационар рәвешләрендә социаль хезмәт күрсәтүләр 442-ФЗ номерлы Федераль законда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнарга түләүсез гамәлгә ашырыла. Әгәр мөрәҗәгать итү датасына социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның бер кешегә уртача исәпләнгән кереме социаль хезмәт күрсәтүләрне түләүсез гамәлгә ашырган өчен бер кешегә уртача исәпләнгән керемнең чик күләменнән аз яисә чик күләменә тигез булса, өйгә барып социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә, инвалидларны реабилитацияләү үзәкләрендә һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль-реабилитация бүлекләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүләр түләүсез гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән социаль хезмәт күрсәтүләрне түләүсез гамәлгә ашыру башка категориядәге гражданнарга каралырга мөмкин.

126-ФЗ номерлы Законда социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашырган өчен айлык түләү күләме социаль хезмәт күрсәтүләргә тарифлар нигезендә исәпләнә, әмма ул файдаланучының бер кешегә исәпләнгән уртача кеременең 75 процентыннан арта алмый дип каралган.

126-ФЗ номерлы Законда Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүне финанс ягыннан тәэмин итү чыганаклары итеп Татарстан Республикасы бюджеты акчалары; хәйрия кертемнәре һәм иганәләр; социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның социаль хезмәт күрсәтүләр өчен түли торган яисә өлешчә түли торган акчалары; Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының керем китерә торган эшчәнлегеннән керемнәре, шулай ук законнар белән тыелмаган башка чыганаклар билгеләнгән.

«Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе субъектларында халыкның төп социаль демографик төркемнәре буенча бер кешегә исәпләнгән яшәү минимумы күләме Россия Федерациясе субъектлары законнарында күрсәтелгән тәртиптә билгеләнә. Яшәү минимумын билгеләү һәм Татарстан Республикасында тормыш дәрәҗәсен яхшырту чараларын гамәлгә ашырганда аннан файдалану өчен хокукый нигез «Татарстан Республикасында бер кешегә исәпләнгән һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү тәртибе турында» 2005 елның 20 июлендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 92-ТРЗ номерлы Закон) белән билгеләнә.





Россия Федерациясе субъектларының административ-территориаль төзелеше һәм аны үзгәртү тәртибе субъект законы белән билгеләнә. Шуңа карамастан, «Географик объектларның атамалары турында» 1997 елның 18 декабрендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе субъектлары башкалаларына һәм административ үзәкләренә исемнәр бирү һәм Россия Федерациясе субъектлары башкалаларының һәм административ үзәкләренең исемнәрен үзгәртү Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тәкъдимнәре буенча федераль законнар белән гамәлгә ашырыла, Россия Федерациясе шәһәрләренең исемнәрен үзгәртү Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тәкъдимнәре буенча федераль законнар белән башкарыла, ә башка торак пунктларга (мәсәлән, поселокларга һәм авылларга) исемнәр бирү Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тәкъдимнәре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләнде. Әмма әлеге мәсьәләләрне, соңыннан бу хакта дәүләт хакимиятенең тиешле федераль органына һичшиксез хәбәр итү шарты белән, Федерация субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан хәл итү максатка ярашлы булыр иде, әмма федераль закон чыгаручы Россия Федерациясе субъектлары, аерым алганда, Татарстан Республикасы фикере белән килешмәде, Татарстан Республикасы бу тәкъдимне берничә тапкыр кабатлады. Әлеге Федераль законның республикаларга, крайларга, өлкәләргә, федераль әһәмияттәге шәһәрләргә, автономияле өлкәгә, автономияле округларга исемнәр бирү һәм аларның исемнәрен үзгәртү турындагы нигезләмәләре Россия Федерациясе Конституциясенә тәңгәлләштерелде. «Географик объектларның атамалары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 27 октябрендәге 191-ФЗ номерлы Федераль закон белән әлеге мәсьәләләр Россия Федерациясе законнары нигезендә хәл ителә дип билгеләнде, ягъни республиканың, крайның, өлкәнең, федераль әһәмияттәге шәһәрнең, автономияле өлкәнең, автономияле округның исемен үзгәртүләр Россия Федерациясе Конституциясенең 137 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъектының билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән карарына таянып, Россия Федерациясе Президенты указы белән Россия Федерациясе Конституциясенең 65 статьясы текстына кертелде.

«Географик объектларның атамалары турында» Федераль законның Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары тарафыннан географик атамаларга исемнәр бирү яисә географик объектның исе-

мен үзгәртү, мондый органнар тарафыннан кирәкле чыгымнар турында тиешле территорияләр халкына мәгълүмат бирү һәм күрсәтелгән тәкъдимнәр хакында халык фикерен ачыклау турындагы тәкъдимнәрне карау хакындагы нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатларында «Татарстан Республикасында географик объектлар исемнәре өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 23 июлендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде.

Әлеге Закон нигезендә географик объектка исем бирү турында яисә географик объектның исемен үзгәртү хакында кергән тәкъдим турында тиешле территорияләрдәге халыкның фикерен ачыклау гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Гавами тыңлаулар үткәрү хакында карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җаваплы комитеты тарафыннан кабул ителә. Гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Дәүләт Советының җаваплы комитеты төзи торган эшче төркем тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү өчен кирәкле чыгымнар турында тиешле территорияләр халкына хәбәр итү Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында тиешле мәгълүмат урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне әлеге Закон нигезендә ачыкланган халык фикерен исәпкә алып карый.

Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү хакындагы тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы күрсәтелгән тәкъдимне хуплау яисә аны кире кагу турында карар кабул итә. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының әлеге карары Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

Географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан хупланган тәкъдим, күрсәтелгән тәкъдимне нигезли торган документлар һәм кирәкле чыгымнарның исәп-хисабы географик объектка исем бирү яисә географик объектның исемен үзгәртү турындагы мәсьәләне карау өчен федераль законнар нигезендә федераль дәүләт хакимияте органына җибәрелә.

2011 елда «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләренә таянып Дәүләт Советы Татарстан Республика-





елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә кергән Татарстан Республикасы Законында (алга таба — 126-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге мәсьәләләрне закон чыгарып җайга салу билгеләнә, алар «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба — 442-ФЗ номерлы Федераль закон) Россия Федерациясе субъектлары компетенциясенә кертелә, шул исәптән:

— Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының түбәндәге яңа функцияләрне үтәве: социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә республика дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру; гражданны социаль хезмәт күрсәтелүгә мохтаҗ дип тану; социаль хезмәт күрсәтүләрнең индивидуаль программасын төзү; социаль хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә мәгълүмат системаларын (социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүчеләрнең реестрын һәм социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның регистрын) булдыруны һәм алып баруны;

— социаль хезмәт күрсәтүләрнең яңа төрен кертү: ашыгыч социаль хезмәт күрсәтүләр, инвалид балаларга һәм алар тәрбияләнә торган гаиләләргә өйдә социаль хезмәт күрсәтүләр;

— Татарстан Республикасы карамагындагы социаль хезмәт күрсәтү оешмалары номенклатурасын раслау;

— Татарстан Республикасында күрсәтелә торган социаль хезмәтләр исемлеген раслау;

— социаль хезмәт күрсәтү рәвешләре буенча социаль хезмәт күрсәтүләр түләүсез гамәлгә ашырыла торган гражданнар категорияләрен билгеләү;

— Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүләрне түләүсез гамәлгә ашыру өчен бер кешегә уртача исәпләнгән керемнең иң чик күләмен билгеләү;

— социаль хезмәт күрсәтүләр гамәлгә ашырылганда һәм социаль хезмәт күрсәтүләргә карамый торган ярдәмне алганда булышлык күрсәткәндә ведомстволар арасында үзара эшчәнлекне оештыру;

— Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә социаль ярдәм һәм кызыксындыру чараларын билгеләү;

— социаль хезмәт күрсәтүне финанслау мәсьәләләрен җайга салу.

Социаль хезмәт күрсәтүне финанс ягыннан тәэмин итү чыганакларына республика бюджеты акчалары, хәйрия кертемнәре һәм иганәләр, социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның социаль хезмәт күрсәтүләр өчен түли торган яисә өлешчә түли торган акчалары, шулай ук социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының керем китерә торган эшчәнлегеннән керемнәре керә.

июлендәге 76-ТРЗ, 2014 елның 24 июлендәге 125-ТРЗ, 2014 елның 18 декабрендәге 125 номерлы Татарстан Республикасы законнары).

Мәсәлән, «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга махсуслаштырылган торак фондыннан махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәләре буенча Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә торак урыннары белән тәэмин ителү хокукы билгеләнә.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $8^{1}$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 20 маендагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында адреслы социаль ярдәм чаралары күрсәтелә торган гражданнар категориясе арттырылды. Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлегеннән, онкология авыруларыннан интегүче, бер кешегә исәпләнгән уртача керемe Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының икеләтә күләменнән кимрәк булган затларга дәвалану урынына бару һәм яшәү урынына кире кайту буенча транспорт чыгымнары компенсацияләнә.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июлендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларга һәм шундый инвалид балалары булган гаиләләргә Татарстан Республикасында торак хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелде. авырулар исемлеге Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнде.

Торак урыннарга мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан затларга торак урын сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирелә.

Инвалидларның һәм инвалид балаларның федераль законда каралган өстәмә торак мәйданына хокукы булганда, торак субсидиясе мондый хокукны исәпкә алып бирелә. Торак субсидиясен исәпләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014





сы административ-территориаль берәмлекләренә исем бирү һәм аларның исемнәрен үзгәртү хакындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карау турында нигезләмә кабул итте. Әлеге нигезләмә белән Татарстан Республикасы административ-территориаль берәмлекләренә исем бирү һәм аларның исемнәрен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне Дәүләт Советы тарафыннан карау тәртибе билгеләнде. Нигезләмәдә шулай ук административ-территориаль берәмлекнең исемен сайлау һәм Дәүләт Советы карарының тиешле проектын әзерләү буенча тәкъдим ителә торган кагыйдәләр бар.

Татарстанда халык хакимиятен гамәлгә ашыруның кирәкле элементлары сайлаулардан һәм референдумнан гыйбарәт, республикада сайлау процессын һәм референдум оештыру өчен үз закон чыгару базасы бар.

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы референдумын билгеләү һәм уздыру тәртибен билгели.

Татарстан Республикасы референдумы ирекле сайлаулар белән беррәттән халык хакимиятен иң югары турыдан-туры белдерү булып тора. Референдум —карарлар кабул итү максатларында дәүләт әһәмиятендәге иң мөһим мәсьәләләр буенча Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу хокукына ия булган гражданнар тарафыннан тавыш бирү юлы белән гамәлгә ашырыла торган ихтыярын турыдан-туры белдерү. Татарстан Республикасы референдумы Татарстан Республикасының бөтен территориясендә уздырыла.

Татарстан Республикасы референдумында катнашу хокукына 18 яшькә җиткән, яшәү урыны Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе гражданы ия була.

Татарстан Республикасы референдумына Татарстан Республикасы карамагындагы мәсьәләләр генә, шулай ук Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр, әгәр алар Россия Федерациясе Конституциясе, Федераль закон белән җайга салынмаган булса, чыгарылырга мөмкин. Референдум уздыру инициативасына референдумда катнашу хокукына ия булган гражданнар һәм сайлау берләшмәсе, уставында сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда катнашу

каралган һәм Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә референдум уздыру буенча инициатив төркем барлыкка килгәнче бер елдан да соңга калмыйча республика яисә федераль дәрәҗәдә теркәлгән бүтән иҗтимагый берләшмә ия була. Референдум уздыру инициативасы белән чыгу һәм аны гамәлгә ашыру тәртибе һәм сроклары үтәлгән булса, референдум билгеләү һәм уздыру мәҗбүри. Татарстан Республикасы референдумы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы референдумы, әгәр анда Татарстан Республикасы территориясендә референдумда катнашучылар исемлекләренә кертелгән референдумда катнашучыларның яртысыннан артыграгы катнашса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан узган дип, ә карар, әгәр бу карар өчен тавыш бирүдә катнашучы референдумда катнашучыларның яртысыннан артыграгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип таныла. Татарстан Республикасы референдумында кабул ителгән карар мәҗбүри була һәм өстәмә раслауны таләп итми, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә гамәлдә була.

2013 һәм 2014 елларда «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законына кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы референдумы турында» Татарстан Республикасы Законына референдум комиссияләрен төзү тәртибе һәм аларның вәкаләтләре, вакытыннан алда тавыш бирү институтын гамәлгә кертү һәм бүтән сайлау участогында тавыш бирү таныклыклары буенча референдумда тавыш бирү мөмкинлеген бетерү, тавыш бирү өчен стационар һәм күчерелмә әрҗәләрнең рәвеше турындагы нигезләмәләр өлешендә һәм башкалар өлешендә үзгәрешләр кертелде.

Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә 100 депутат сайлана. Дәүләт Советы депутатларын сайлауны билгеләү, уздыру һәм сайлау кампаниясе нәтиҗәләрен чыгару тәртибе 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексы белән җайга салына.

Республикада 2000 еллар уртасында беренче мәртәбә Татарстандагы сайлау процессын сайлауларның дәрәҗәсенә карап җайга салучы барлык республика законнарын кодлаштыру эше башкарылды, аның нәтиҗәсе 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексын кабул итү булды.

Татарстан Республикасы Сайлау кодексы Татарстан Республикасы Президентын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын, җирле үзидарә органының вәкиллекле органы де-





60-ТРЗ номерлы Законга инвалидларны эшкә кабул итеп алу өчен квота йөз кешедән арткан хезмәткәрләре булган эш бирүче өчен генә түгел, хезмәткәрләре 35тән дә ким булган һәм 100дән дә артык булмаган эш бирүчеләр өчен дә каралу турында үзгәрешләр кертелде. Квота күләме бу очракта уртача исемлектәге хезмәткәрләр санының 3 процентын тәшкил итә.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль хезмәт күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 63-ТРЗ номерлы Закон) белән дәүләт тарафыннан адреслы социаль ярдәм чаралары билгеләнде.

Закон Татарстан Республикасында гражданнарның түбәндәге категорияләренә күрсәтелгән чараларны билгели:

1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәр чорда, СССРның вакытлыча басып алынган территорияләрендә эшләгән чорны кертмичә, тылда кимендә алты ай эшләгән затларга; Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яисә медальләре белән бүләкләнгән затларга;

хезмәт ветераннарына;

реабилитацияләнгән гражданнарга;

сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган гражданнарга;

ятим балаларга;

ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга;

ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар исәбеннән булган затларга;

18 яшькә кадәрге балалары булган гражданнарга;

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга;

хроник бөер җитешсезлегеннән, онкологик авырулардан интегүче затларга;

хроник авыруларның авыр төрләреннән интегүчеләргә;

хроник авыруларның авыр төрләреннән интегүче балалары булган гаиләләргә.

Халыкны социаль яклау чараларын гамәлгә ашыруга 63-ТРЗ номерлы Законда билгеләнгән чыгымнар тапшырылган финанс чаралары күләмнәрендә Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән башкарыла.

Әлеге 63-ТРЗ номерлы Законга кайбер нигезләмәләрне төгәлләштерүгә бәйле үзгәрешләр кертелде (2012 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ, 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ, 2013 елның 20 маендагы 37-ТРЗ, 2014 елның 23 июлендәге 69-ТРЗ, 2014 елның 24

урта һөнәри белемгә ия булган, беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге гражданнар;

вәкаләтле орган бәяләмәсе буенча даими карауга, ярдәмгә яисә күзәтүгә мохтаҗ затларны үзләре каравында тотучы гражданнар;

предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр ябылу йә физик затларның индивидуаль эшкуарлар буларак эшчәнлеге туктатылу аркасында эшләреннән азат ителгән, бала туугa һәм аны карауга бәйле рәвештә эшендә өзеклек барлыкка килгән хатын-кызлар;

иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтү учреждениеләреннән азат ителеп кайткан затлар.

Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары булдыру максатларында 60-ТРЗ номерлы Закон тиешле кызыксындыру чаралары билгели. Аерым алганда, билгеләнгән квоталар һәм резервлана торган эш урыннары саны нигезендә эш урыннары бүлеп бирүче яисә булдыручы һәм шул эш урыннарына инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыручы эш бирүчеләрне кызыксындыру чарасы буларак, 60-ТРЗ номерлы Законда әлеге эш бирүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан инвестицияләр алу өчен өстенлекле хокук бирү карала.

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 10 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән 60-ТРЗ номерлы Закон федераль законнарга туры китерелде.

Эш бирүчегә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яисә бүлеп бирелгән эш урыннары турында белешмәләр булган локаль норматив актлар кабул итү, шулай ук мондый эш урыннары һәм актлар турында эш белән тәэмин итү хезмәтенә мәгълүмат бирү тиешлеге билгеләнде. Мәгълүмат бирү сроклары ачыкланды.

Мондый эш урыннары турында белешмәләр булган актлар турында һәм вакантлы эш урыннары булу турындагы мәгълүмат ай саен эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына тапшырылырга тиеш.

Социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар һәм инвалидларны эшкә урнаштыру өчен резервланган эш урыннары санын билгеләү турындагы карарлар кысаларында бүлеп бирелгән яисә булдырылган ирекле эш урыннары турында мәгълүмат эшләүче азат ителгән көннән алып 10 көн эчендә тапшырыла.

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 9 июнендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән





путатларын, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзаларын, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын сайлауларны уздыру тәртибен, шулай ук федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Президентын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар һәм муниципаль сайлаулар уздырганда Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары гарантияләрен билгели. Әлеге Кодекс муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын, муниципаль берәмлек башлыгын һәм җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларын сайлаулар тәртибен, әгәр күрсәтелгән вәкиллекле орган, җирле үзидарәнең вазыйфаи заты закон, муниципаль берәмлек уставы нигезендә муниципаль сайлауларда турыдантуры халык тарафыннан сайланса, җайга сала. Муниципаль берәмлекләр башлыкларын сайлаулар һәм җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларын сайлаулар, әгәр күрсәтелгән Кодекста муниципаль берәмлекләр башлыкларын сайлауларны җайга салу үзенчәлекләре аерым каралмаган булса, бердәм кагыйдәләр буенча уздырыла. Кодекс референдумда катнашу хокукын гамәлгә ашырганда, депутатларны һәм сайланулы вазыйфаи затларны чакыртып алганда барлыкка килә торган, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасының бүтән законнары белән җайга салына торган иҗтимагый мөнәсәбәтләргә кагылмый.

Татарстан Республикасында пропорциональ-мажоритар сайлау системасы билгеләнде. Дәүләт Советының 50 депутаты бермандатлы сайлау округлары буенча (бер округ — бер депутат) сайлана, бу округлар бермандатлы сайлау округына сайлаучылар вәкиллегенең уртача нормасы нигезендә төзелә. Сайлаучылар вәкиллегенең уртача нормасы Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәм Татарстан Республикасында теркәлгән сайлаучыларның гомуми санын 50 бермандатлы сайлау округына бүлү юлы белән Федераль закон нигезендә билгеләнә. Дәүләт Советының 50 депутаты бердәм республика сайлау округы буенча сәяси партияләр тарафыннан күрсәтелгән депутатлыкка кандидатларның республика исемлекләре буенча сайлана.

Дәүләт Советы депутатларын республика сайлау округы буенча сайлауда актив сайлау хокукына 18 яшькә җиткән, яшәү урыны Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе гражданы (алга таба — граждан) ия була, бермандатлы сайлау округы буенча — 18 яшькә җиткән, яшәү урыны тиешле бермандатлы сайлау округы территориясендә урнашкан граждан ия була. Тавыш бирү көненә 18 яшькә җиткән граждан

закон белән каралган һәм законлы алымнар белән уздырыла торган башка сайлау гамәлләрендә дә катнашырга хокуклы.

Дәүләт Советы депутаты итеп тавыш бирү көненә 21 яшькә җиткән граждан сайлана ала.

Татарстан Республикасында Дәүләт Советы депутатларын сайлауны әзерләү һәм уздыру түбәндәге сайлау комиссияләре тарафыннан гамәлгә ашырыла: Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, округ, территориаль һәм участок сайлау комиссияләре.

Кандидатларны күрсәтү хокукына турыдан-туры кандидат, бу хокук үз-үзеңне күрсәтү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин, һәм сәяси партия (сайлау берләшмәсе) ия була. Кандидатларның республика исемлеге составында кандидатларны күрсәтү сайлау берләшмәсе тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Бермандатлы сайлау округы буенча сайлау нәтиҗәләрен округ комиссиясе, ә республика сайлау округы буенча – Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе билгели.

Бермандатлы сайлау округы буенча тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның иң күп тавышын җыйган теркәлгән кандидат сайланган дип таныла.

Республика сайлау округы буенча депутат мандатларын бүлешүгә кандидатларның кимендә ике республика исемлеге кертелергә тиеш. Татарстан Республикасы Сайлау кодексында Татарстан Республикасы закон чыгару органында депутат мандатларын бүлешүгә партия исемлегенең узу барьеры 5 процент итеп билгеләнә.

Өченче чакырылыш Дәүләт Советы депутатларын сайлау 2004 елда «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны Россия Федерациясе Президентын сайлаулар белән бергә алып бару турында» 2003 елның 22 сентябрендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә уздырылды. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 82 статьясы нигезендә Дәүләт Советына сайлауда тавыш бирү көнен Россия Федерациясе Президентын сайлауда тавыш бирү көне белән берләштерү максатларында икенче чакырылыш Дәүләт Советы вәкаләтләре срогы 2004 елның 14 мартына кадәр кыскартылды.

2004 елның 14 мартында Татарстанда парламент сайлавы беренче мәртәбә катнаш (пропорциональ-мажоритар) система буенча уздырылды. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауның гомуми нәтиҗәләрен билгеләү турында» 2004 елның 17 мартындагы 98/458 номерлы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары нигезендә сайлау узды-





легенең сайланулы хезмәткәрләре өчен эштән азат ителгәндә гарантияләрне төгәлләштерә торган үзгәрешләр кертелде.

«Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында» 2004 елның 26 июлендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 42-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнарының социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм шуларга бәйле башка турыдантуры мөнәсәбәтләрне күп баскычлы шартнамәчел җайга салу һәм иҗтимагый татулыкка ирешүгә ярдәм итү максатларында социаль партнерлык органнарын төзү һәм аларның эшчәнлек механизмын билгели.

42-ТРЗ номерлы Законда республика, тармак һәм территориаль дәрәҗәләрдә социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу комиссияләрен төзү күздә тотыла, аларның эшчәнлек максатлары, бурычлары, принциплары һәм төзү тәртибе билгеләнә.

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 60-ТРЗ номерлы Закон) белән инвалидлар өчен эш урыннары квоталау һәм махсус эш урыннарының минималь күләмен билгеләү, инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын резервлау тәртибен билгели, эш бирүчеләрнең хокуклары һәм бурычлары, инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау чараларын финанслау чыганакларын билгели.

60-ТРЗ номерлы Закон нигезендә социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарга – хезмәт базарында тигез шартларда конкуренциягә сәләтле булмаган һәм шуңа бәйле рәвештә эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнарга түбәндәгеләр керә:

14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнар;

ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар;

пенсия алды яшендәге затлар (картлык буенча хезмәт пенсиясенә чыгу, шул исәптән картлык буенча вакытыннан алда хезмәт пенсиясе билгеләнү хокукын бирә торган яшькә җиткәнче ике ел кала);

качаклар һәм мәҗбүри күченеп килүчеләр;

хәрби хезмәттән кайткан гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары;

балигъ булмаган балаларын яисә инвалид балаларын тәрбияләүче ялгыз һәм күпбалалы ата-аналар;

Чернобыль һәм башка радиация һәлакәтләре һәм афәтләре аркасында радиациягә дучар булган гражданнар;

дерациясе Законы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә гамәлгә ашыру өчен тапшырылган вәкаләтләрен бүлү чараларын төгәлләштерүне күздә тота.

Россия Федерациясе субъектлары хәзер бары тик эшсезләргә генә социаль түләүләрне федераль бюджеттан бирелгән субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашыралар. Мондый түләүләрнең төрләре күрсәтелде. Болар: эшсезлек буенча пособиеләр; халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү чорында стипендияләр; эшсезлек буенча пособие түләүнең билгеләнгән чоры тәмамлануга бәйле матди ярдәм; халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификация күтәрү чорында матди ярдәм; картлык буенча хезмәт пенсиясе, шул исәптән картлык буенча вакытыннан алда билгеләнә торган хезмәт пенсиясе билгеләнүгә хокук бирә торган яшькә җиткәнчегә кадәрге чорга халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тәкъдиме белән билгеләнгән пенсия.

Татарстан Республикасы вәкаләтләре кысаларында эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру чараларын финанслау республика бюджеты акчалары, бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән башкарыла.

Гражданнарның үз һөнәри, хезмәт һәм социаль-икътисадый хокукларын һәм халыкара хокукның гомумтанылган нормаларына, Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм федераль законнарга бәйле мәнфәгатьләрен яклау өчен һөнәр берлекләренә иректе берләшү гарантияләре «Һөнәр берлекләре турында» 1995 елның 18 гыйнварындагы 2303-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба — 2303-XII номерлы Закон) белән билгеләнә. 2303-XII номерлы Закон социаль базар хуҗалыгын үстерүдә, гражданлык татулыгын тәэмин итүдә һөнәр берлекләренең конструктив ролен таный, һөнәр берлекләре эшчәнлегенә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2303-XII номерлы Закон һөнәр берлекләренең төп хокукларын, шул исәптән хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен чагылдыруга, күмәк сөйләшүләр алып баруга, күмәк шартнамәләр һәм килешүләр төзүгә, дәүләт һәм иҗтимагый эшләр белән идарә итүдә катнашуга, хезмәт, һөнәр берлекләре турында законнарның үтәлешен контрольдә тотуга, мәгълүмат алуга һәм башкаларга хокукларын билгели, шулай ук аларны гамәлгә ашыруның гарантияләрен урнаштыра.

«Һөнәр берлекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 18 гыйнварындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында һөнәр бер-





рылган һәм дөрес дип танылды, Дәүләт Советына 100 депутат сайланды. Бердәм республика сайлау округы буенча депутат мандатлары ике сәяси партия — «Бердәм Россия» һәм Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе арасында бүленде.

2009 елның 1 мартында өченче чакырылыш Дәүләт Советы депутатлары вәкаләтләренең бишьеллык срогы узгач, дүртенче чакырылыш Дәүләт Советы депутатларын сайлау уздырылды. «Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауның гомуми нәтиҗәләрен билгеләү турында» 2009 елның 4 мартындагы 11/156 номерлы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары нигезендә сайлау уздырылган һәм дөрес дип танылды. Дүртенче чакырылыш Дәүләт Советына 100 депутат сайланды: 50се — бердәм сайлау округы буенча (шулардан 44 мандатны «Бердәм Россия» бөтенроссия сәяси партиясе һәм алты мандатны Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе алды) һәм 50се — бермандатлы сайлау округлары буенча (шулардан 43 депутат «Бердәм Россия» бөтенроссия сәяси партиясе тарафыннан күрсәтелде, ә 7 депутат үз-үзен күрсәтте).

2014 елның 14 сентябрендә дүртенче чакырылыш Дәүләт Советы депутатлары вәкаләтләренең бишьеллык срогы узгач, бишенче чакырылыш Дәүләт Советы депутатларын сайлау уздырылды. «Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауның гомуми нәтиҗәләрен билгеләү турында» 2014 елның 17 сентябрендәге 48/150 номерлы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары нигезендә сайлау уздырылган һәм дөрес дип танылды. Бишенче чакырылыш Дәүләт Советына 100 депутат сайланды: 50се — бердәм сайлау округы буенча (шулардан 47 мандатны «Бердәм Россия» бөтенроссия сәяси партиясе һәм өч мандатны Россия Федерациясе Коммунистлар партиясе алды) һәм 50се — бермандатлы сайлау округлары буенча (шулардан 36 депутат «Бердәм Россия» бөтенроссия сәяси партиясе, бер депутат — Россиянең либераль-демократик партиясе тарафыннан күрсәтелде, унөч депутат үз-үзен күрсәтте).

«Сәяси партияләр турында» Федераль законның 32 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 6 маендагы 80-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен үстереп, «Парламент партияләренең эшчәнлеген бөтен кеше өчен мөмкин булган дәүләт телеканаллары һәм радиоканаллары аша яктыртканда аларның тигезлек гарантияләре турында» 2009 елның 12 маендагы 95-ФЗ номерлы Федераль закон аналогиясе буенча «Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктырт-

канда аларның тигезлек гарантияләре турында» 2010 елның 30 июлендәге 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән федераль башкарма хакимиятнең массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органының Татарстан Республикасы буенча территориаль органы тарафыннан теркәлгән региональ телеканал һәм радиоканал аша Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлекләре яктыртылганда аларның тигезлек гарантияләрен тәэмин итү буенча төп нигезләмәләр билгеләнә.

Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктырту партияләр эшчәнлеген яктыртуга дәүләт контроленең халык өчен ачык булуы, һәр партия эшчәнлеге турындагы мәгълүматны бертигез күләмдә тарату, телевидение тамашачыларына һәм радио тыңлаучыларга партияләр эшчәнлеге турында һәрьяклы һәм объектив мәгълүмат җиткерү, партияләр эшчәнлеген яктыртканда региональ телеканал һәм радиоканал редакцияләренең иҗади бәйсезлеге һәм һөнәри мөстәкыйльлеге принциплары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт Советындагы һәр сәяси партиянең эшчәнлеген яктыртуга бер календарь ай эчендә региональ телеканал һәм радиоканал тарафыннан тотылган эфир вакыты күләмен исәпкә алу тәртибе һәм методикасы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән раслана.

Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктыртканда аларның тигезлек гарантияләрен тәэмин итүне тикшереп тору шушы сәяси партияләр, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, теле- һәм радиотапшыруларны алып баручы оешма катнашында, шулай ук федераль башкарма хакимиятнең массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә тикшереп тору һәм күзәтчелек функцияләрен башкаруга вәкаләтле органының Татарстан Республикасы буенча территориаль органы, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән килештереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

«Профессиональ даими нигездә эшләүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары саны турында» 2003 елның 22 сентябрендәге 36-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон





дицина күзәтүләрен (тикшерүләрен) оештыру турында таләп, шулай ук хезмәткәрнең аларны узу бурычы кертелде.

1417 номерлы Законга аны федераль законнарга туры китерүгә бәйле үзгәрешләр кертелде (2004 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы, 2014 елның 23 июлендәге 60-ТРЗ номерлы, 2014 елның 24 июлендәге 76-ТРЗ номерлы законнары).

2014 елның 23 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән республика башкарма хакимиятенең хезмәтне саклау өлкәсендәге органының вәкаләтләре төгәлләштерелде. Аерым алганда, мондый орган хезмәтне саклау буенча инструктаж оештыру, хезмәт шартлары буенча эш урыннарына аттестация үткәрү һәм эшләрне оештыруның хезмәтне саклау буенча норматив таләпләргә туры килүен раслау вәкаләтләреннән мәхрүм ителгән.

Эш бирүчеләргә хезмәтне саклау белән идарә итү системасын булдыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү йөкләмәсен өстәделәр.

Аерым үзгәрешләр шулай ук хезмәт шартларын махсус бәяләү чараларын кертүгә бәйле. Ул хезмәт шартлары зарарлы һәм (яисә) куркыныч булган эшләргә карата гарантияләр һәм компенсацияләр бирү турындагы мәсьәләне хәл итү өчен төп чарага әверелә бара.

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 39-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру чараларын билгели.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендәге органнарының вәкаләтләре билгеләнде.

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 17 декабрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән 39-ТРЗ номерлы Законга үзгәрешләр кертелде, ул дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендәге органнарының вәкаләтләрен, шулай ук «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Фе-

тәртибе күрсәтелә, документларны кабул итеп алудан баш тартуның сәбәпләре бәян ителә.

Башкарма хакимиятнең социаль яклау өлкәсендә вәкаләтле органына 33-ТРЗ номерлы Закон белән «Хезмәт ветераны» исемен бирү турында карар кабул итү хокукы бирелә. Әлеге орган шулай ук «Хезмәт ветераны» исеме бирелгән гражданнарның реестрын алып бара. Таныклык югалган яисә бозылган очракта аның дубликатын бирү мөмкинлеге карала.

«Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба — Закон) хезмәткәрләрнең хезмәтне саклау хокукын гамәлгә ашыруның гарантияләрен билгели, хезмәтне саклау өлкәсендә барлык оештыру-хокукый һәм милек рәвешләрендәге оешмаларда эш бирүчеләр белән эшләүчеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салуның бердәй тәртибен тәэмин итә һәм хезмәт эшчәнлеге барышында һәм аңа бәйле рәвештә хезмәткәрләрнең гомерен һәм сәламәтлеген саклау таләпләренә җавап бирә торган хезмәт шартларын булдыруга юнәлдерелә.

1417 номерлы Закон хезмәтне саклауны, шул исәптән хезмәт иминлеге шартларын тәэмин итү, хезмәтне саклау өлкәсендә хезмәткәрләрнең бурычларын тәэмин итү буенча эш бирүченең вазыйфаларын регламентлауны да кертеп, төрле чараларны күздә тота.

1417 номерлы Закон белән хезмәтне саклау турында, шул исәптән хезмәт шартларына дәүләт экспертизасын үткәрү тәртибе турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору һәм контрольдә тоту эшләре җайга салына.

Хезмәтне саклау — хезмәт эшчәнлеге барышында эшләүчеләрнең исәнлек-саулыгын тәэмин итүнең хокукый, социаль-икътисадый, оештыру-техник, санитария-гигиена, дәвалау-профилактика, реабилитация чараларын һәм башка чараларны үз эченә алган системасы ул. Хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләре билгеләнде. Хезмәт саклауны тәэмин итү тәртибе, хезмәтне саклау турындагы законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү һәм контроль мәсьәләләре җайга салынды.

1417 номерлы Законда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәтне саклау өлкәсендәге органының вәкаләтләре билгеләнде.

1417 номерлы Законда эш бирүчегә үз акчалары исәбеннән, мәҗбүри башлангыч һәм даими медицина күзәтүеннән (тикшерүеннән) тыш, хезмәт законнарында һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив актларда каралган очракларда башка мәҗбүри ме-





һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Дәүләт Советында профессиональ даими нигездә егерме Дәүләт Советы депутаты, шул исәптән Дәүләт Советы Рәисе, Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары, Дәүләт Советы Секретаре, Дәүләт Советы комитетлары рәисләре эшли дип билгеләнә. Дәүләт Советының бүтән депутатлары профессиональ даими нигездә эшләү өчен Дәүләт Советы тарафыннан сайлана.

Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затын сайлау институтын кире кайтара торган «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 2 маендагы 40-ФЗ номерлы Федераль закон кабул итүгә бәйле рәвештә 2012 елның 22 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасы Президентын сайлау турындагы нигезләмәләре (75 статьяның 16 пункты, 91 статья, 93 статьяның 1 һәм 2 өлешләре) торгызылды, шулай ук Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен бирү турындагы нормаларның үз көчләрен югалтуы танылды.

Татарстан Республикасы Президентын сайлауны билгеләү, әзерләү һәм уздыру тәртибен җайга сала торган тиешле үзгәрешләр Татарстан Республикасы Сайлау кодексына да кертелде (2012 елның 22 июнендәге 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы). «Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар турында» 2004 елның 25 мартындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көчен югалткан дип танылды.

Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы территориясен үз эченә алган бердәм республика сайлау округы буенча сайлана.

Татарстан Республикасы Президентын сайлауда актив сайлау хокукына Дәүләт Советы депутатларын республика сайлау округы буенча сайлауда актив сайлау хокукына ия булган шул ук гражданнар ия була.

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Президентын сайлауны әзерләү һәм уздыру Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, территориаль комиссияләр һәм участок комиссияләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидат итеп 30 яшькә җиткән граждан күрсәтелергә мөмкин, кандидатларны күрсәтү хокукына бары тик сәяси партияләр генә ия була.

Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына кандидат күрсәтүне муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының һәм (яисә) муниципаль сайлауда сайланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларының Татарстан Республикасы Президентын сайлауны билгеләү турындагы карар кабул ителгән көнгә шушы муниципаль берәмлекләрнең уставлары белән каралган әлеге депутатларның гомуми санынннан һәм муниципаль сайлауда сайланган, әлеге карарны кабул итү көненә эшләп килүче шушы муниципаль берәмлекләр башлыклары санынннан 5 проценты хупларга тиеш. Муниципаль район составына керүче җирлекләр башлыкларыннан һәм шушы җирлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларыннан торган муниципаль районның вәкиллекле органы депутатлары бер генә мәртәбә исәпкә алына. Кандидатны хуплаучы затлар арасында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының вәкиллекле органнары депутатларының һәм (яисә) муниципаль сайлауда сайланган Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларының Татарстан Республикасы Президентын сайлауны билгеләү турындагы карар кабул ителгән көнгә муниципаль районнар һәм шәһәр округлары уставлары белән каралган әлеге депутатларның гомуми санынннан һәм муниципаль сайлауда сайланган, әлеге карарны кабул итү көненә эшләп килүче шушы Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары санынннан булган затлар 5 процентны тәшкил итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы Президентын сайлау нәтиҗәләрен билгеләү Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Президентын сайлауда тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның 50 проценттан артыграк тавышын җыйган теркәлгән кандидат сайланган дип санала.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алуны оештыру һәм уздыру тәртибен билгели торган «Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында» 2012 елның 25 декабрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде.

Чакыртып алу «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон,





бөтенроссия спорт федерациясе тарафыннан гамәлгә ашырылган очракта, мондый спорт төре буенча спорт дәрәҗәләре, спорт разрядлары, спорт судьяларының квалификация категорияләре Федераль закон нигезендә бирелә.

Гомумроссия спорт федерациясенә нигезләнеп үстерелә торган милли спорт төрләре кагыйдәләре федераль законнарга туры китереп эшләнә.

### Хезмәт һәм социаль яклау турындагы законнар

«Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Закон) «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 4 пункты нигезендә кабул ителде, аның буенча «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

33-ТРЗ номерлы Законда «Хезмәт ветераны» исеме түбәндәгеләргә бирелә дип билгеләнә:

1) СССР яисә Россия Федерациясе орденнары яисә медальләре белән бүләкләнгән йә мактаулы исемнәренә лаек булган, йә хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләнгән һәм картлык буенча яисә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кирәкле хезмәт стажына ия булган затларга;

2) хезмәт эшчәнлеген Бөек Ватан сугышы чорында балигъ булмаган яшьтә башлаган һәм хезмәт стажы ирләр өчен кимендә 40 ел һәм хатын-кызлар өчен кимендә 35 ел булган затларга.

Законда хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары дигәндә хезмәттәге казанышлар һәм ирешкән уңышлар өчен СССР, РСФСР, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм башка дәүләт органнары, СССР, РСФСР, Россия Федерациясе иҗтимагый берләшмәләренең һәм оешмаларының дәүләт (ведомство) функцияләрен гамәлгә ашыруда катнашучы (катнашкан) үзәк органнары тарафыннан гамәлгә куелган бүләкләр, шул исәптән мактау грамоталары, дипломнар, күкрәк һәм мактау тамгалары, тармак (ведомство) буенча мактаулы һәм атказанган хезмәткәрләре исемнәре дип аңлашыла. Бу органнарның исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан күрсәтелгән тәртиптә һәм шартларда билгеләнә.

33-ТРЗ номерлы Законда «Хезмәт ветераны» исемен бирү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге тәкъдим ителә, аларны территориаль социаль яклау органнары тарафыннан карау

федерацияләре тарафыннан төзелә һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан раслана. Шул ук орган Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларына кандидатлар исемлекләрен төзүнең гомуми принципларын һәм критерийларын раслый.

Чит дәүләтләрнең физик культура-спорт оешмалары тарафыннан медицина белгечләре сыйфатында тәкъдим ителгән затлар халыкара спорт чаралары вакытында медицина яисә фармацевтика эшчәнлеген башкаруга Федераль законнарда каралган рөхсәт алу процедурасын узмыйча медицина ярдәме күрсәтә ала.

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 18 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 3-ТРЗ номерлы Закон) нигезендә Татарстан Республикасында физкультура-спорт яисә спорт чараларын оештыручыларга рәсми спорт ярышларын оештыру һәм үткәрү өчен җаваплылык йөкләнә. Рәсми спорт ярышлары уздырганда алар шулай ук спорт объектлары милекчеләре, спорт объектларыннан файдаланучылар белән берлектә җәмәгать тәртибе һәм иҗтимагый иминлек чараларын тәэмин итә. Җәмәгать тәртибе һәм иҗтимагый иминлек чараларын тәэмин итү ярышларны оештыручылар яисә спорт объектлары милекчеләре, спорт объектларыннан файдаланучылар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Спорт ярышлары уздырыла торган объектларны тамашачыларның керү билетлары яисә аларны алмаштыра торган документларның булу-булмавын тикшерергә мөмкинлек бирә торган итеп тиешенчә техник җиһазлауны спорт объектлары милекчеләре, алардан файдаланучылар тәэмин итә.

Рәсми спорт ярышлары уздыру урыннарында кирәкле инфраструктура, физик затлар рәсми спорт ярышлары уздыру урыннарында булган вакытта аларны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган видеокүзәтү системалары һәм техник җиһазлар булырга тиеш.

Закон нигезендә тамашачылар физик культура һәм спорт субъектлары исәбенә кертелгән.

Рәсми спорт ярышлары нәтиҗәләренә законсыз рәвештә йогынты ясауны тыю физик культура һәм спорт турындагы законнарның төп принципларына кертелгән.

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 15 декабрендәге 121-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында милли спорт төрләрен үстерү мәсьәләләре төгәлләштерелде. Мәсәлән, милли спорт төрен үстерү тиешле





башка федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон нигезендә уздырыла.

Чакыртып алу хокукы турыдан-туры демократияне гамәлгә ашыру рәвешләренең берсе, шулай ук Татарстан Республикасы Президентының законнар белән беркетелгән үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан тикшереп тору чараларының берсе булып тора. Әмма чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасы Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына керешкән көннән кимендә бер ел узгач күрсәтелергә мөмкин.

Чакыртып алу түбәндәге нигезләрнең берсе буенча мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Президенты Россия Федерациясе законнарын һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнарын бозса, бозу факты тиешле суд белән билгеләнгән булса;

2) Татарстан Республикасы Президенты үз вазыйфаларын мөһим сәбәпләрсез тупас рәвештә берничә мәртәбә үтәмәсә, бу тиешле суд белән билгеләнгән булса.

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән фактларны билгеләү турындагы гариза белән Татарстан Республикасы Югары Судына сәяси партияләр, аларның региональ бүлекчәләре, башка иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук кимендә 100 кешедән торган, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлауда актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары төркеме мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2010 елда «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 11 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә шулай ук Татарстан Республикасы Президенты антының тексты да үзгәртелде. «Татарстан Республикасы Президентының үз вазыйфасына керешүе турында» 1991 елның 4 июлендәге 1141-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына кертелгән үзгәрешләр нигезендә Татарстан Республикасы Президенты Россия Федерациясе Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә тугрылыклы булуына ант итә: «Татарстан Республикасы халкына тугрылыклы хезмәт итәргә, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, Татарстан Республикасының дәүләт суверенлыгын тәэмин итәргә, Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Консти-

туциясен һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәргә, Татарстан Республикасы Президентының үземә йөкләнгән бурычларын намус белән үтәргә тантаналы рәвештә ант итәм.».

Татарстан Республикасы Югары Судының 2011 елның 3 мартындагы карары белән Татарстан Республикасы Президенты антының тексты Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан федераль законнарны үтәвен тексттан төшереп калдыру өлешендә федераль законнарга туры килми дип танылды. Шулай ук Татарстан Республикасы Югары Суды карары белән ант текстының Татарстан Республикасы дәүләт суверенлыгы искә алынган өлешендәге нигезләмәләре Россия Федерациясе субъектларының гамәлгә кую актлары нормаларына охшашлыгы расланды, ә бу нормалар элегрәк Россия Федерациясе Конституция Суды тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясенә туры килми дип танылды.

2010 елда вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Татарстан Республикасы Президентының тәҗрибәсен һәм белемнәрен Татарстан Республикасының сәяси, социаль-икътисадый һәм бүтән үсеше өчен һәрьяклап файдалану максатларында яңа гына вәкаләтләр тапшырылган Татарстан Республикасы Президенты инициативасы буенча «Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе турында» 2010 елның 30 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде.

Әлеге Закон белән Россия Федерациясе Конституциясенең 73 һәм 76 статьялары, Татарстан Республикасы Конституциясенең 4 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе вазыйфасы гамәлгә куелды, ул үзенең хокукый статусы буенча Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфасы булып саналмый.

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе вазыйфасына Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен үтәвен туктаткан зат билгеләнә. Вазыйфага билгеләү Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме буенча Дәүләт Советы тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукына ия. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституциясенең 75, 76, 94 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 30 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Конституциясенә тиешле үзгәрешләр кертелде.

Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларын гамәлгә ашыруны һәм яклауны тәэмин итү, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауны, Татарстан Респуб-





мәгариф системасында эш урыны, яшәү урыны һәм ял итү урыны буенча физик культура һәм спорт турындагы нигезләмәләр, сәламәтлеге чикле затларның һәм инвалидларның физик культура белән шөгыльләнүе һәм физик реабилитациясе, спортчылар әзерли торган физкультура-спорт оешмалары һәм мәгариф учреждениеләре төрле спорт төрләре буенча спортчылар әзерләү буенча укыту-тренировка программалары турындагы нигезләмәләр урын алды.

99-ТРЗ номерлы Законда балалар-яшүсмерләр спортын, мәктәп спортын һәм студентлар спортын үстерүгә ярдәм итү чаралары беркетелгән. Студентларның спорт лигалары физик культура һәм спорт субъектларына кертелгән. Дәүләт хакимияте органнары республика бюджеты акчалары исәбеннән студентлар спортын үстерү хокукына ия.

Мәгариф оешмаларында физик тәрбия һәм белем бирүне оештыруга өстәмә рәвештә мәктәп спортын һәм студентлар спортын үстерүгә ярдәм итү һәм аларның абруен арттыру да кертелә.

99-ТРЗ номерлы Закон белән спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар һәм бу оешмаларның спорт әзерлеге буенча федераль стандартларны үтәвен тикшереп тору тәртибе билгеләнде.

Федераль законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, әлеге Законга үзгәрешләр кертелде (2012 елның 25 декабрендәге 94-ТРЗ номерлы, 2013 елның 18 июнендәге 49-ТРЗ номерлы, 2014 елның 18 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы, 2014 елның 25 июлендәге 76-ТРЗ номерлы, 2014 елның 15 декабрендәге 121-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары).

2013 елның 18 июнендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 49-ТРЗ номерлы Закон) нигезендә республика спорт федерациясенә гомумроссия спорт федерациясенең структур бүлекчәсе (республика бүлекчәсе) статусы бирелә. Аның дәүләт тарафыннан аккредитация үтү һәм куелган таләпләрне үтәүне тикшереп тору тәртибе билгеләнә.

49-ТРЗ номерлы Законда волонтерлар турында нигезләмәләр бәян ителде. Волонтерларга компенсация түләүләре бирү һәм аларны матди-техник яктан тәэмин итү шартлары, тәртибе һәм нормалары федераль дәрәҗәдә җайга салынды.

Татарстан Республикасы территориясендә халыкара спорт чараларын уздыруга (мондый чараларны уздыру хокукы өчен конкурста катнашуга) гаризалар җибәрү физик культура һәм спорт өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә спортның тиешле төре буенча гомумроссия спорт федерациясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Законда Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларын төзү тәртибе беркетелде. Татарстан Республикасы спорт җыелма командаларына кандидатлар исемлекләре ел саен республика спорт

Сәламәтлек саклау өлкәсендә финанс тәэминаты чыганаклары федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджетлар акчаларыннан, мәҗбүри медицина иминияте акчаларыннан, оешмалар һәм гражданнар акчаларыннан, физик һәм юридик затлардан кергән акчалардан, шул исәптән ирекле иганәләрдән, һәм тыелмаган башка чыганаклардан гыйбарәт.

Медицина эшчәнлегенең сыйфатына һәм куркынычсызлыгына дәүләт, ведомство контролен һәм эчке контрольне оештыру тәртибе билгеләнде.

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 26 декабрендәге 104-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасында дарулар, медицина әйберләре, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары, дезинфекция чаралары, иммунобиологик препаратлар сатып алуны, медицина техникасын ремонтлауны һәм аңа техник хезмәт күрсәтүне оештыру тәртибе билгеләнде. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты аның ведомство буйсынуында булган дәүләт учреждениеләре яисә дәүләт унитар предприятиеләре арасыннан бердәнбер тәэмин итүчене (башкаручыны) билгели.

Бердәнбер тәэмин итүче вәкаләтләре исемлегенә, аерым алганда, сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле орган, дарулар, медицина әйберләре, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары белән бушлай тәэмин ителү хокукына ия медицина оешмалары һәм гражданнар өчен күрсәтелгән медицина чараларын сатып алу, саклау һәм илтеп тапшыруны тәэмин итү; гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасын гамәлгә ашыруда катнаша торган республика медицина оешмалары өчен медицина техникасын ремонтлау һәм аны техник яктан карау буенча хезмәтләр күрсәтү керә.

Республикада физик культура һәм спорт өлкәсендәге мөнәсәбәтләр «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән (алга таба – 99-ТРЗ номерлы Закон) җайга салына.

99-ТРЗ номерлы Закон белән Татарстан Республикасында физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекнең хокукый, оештыру, икътисадый, социаль һәм башка нигезләре билгеләнде. 99-ТРЗ номерлы Законда физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнара вәкаләтләре күрсәтелде.

Закон белән физкультура һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү мәсьәләләре җайга салына. 99-ТРЗ номерлы Законда





ликасы референдумын әзерләү һәм уздыру, Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Президентын һәм федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлауларны, Россия Федерациясе референдумын әзерләү һәм уздыру өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе һәм Татарстан Республикасы территориаль сайлау комиссияләре төзелә.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясен һәм Татарстан Республикасы территориаль сайлау комиссияләрен төзү тәртибе, аларның статусы, компетенциясе, вәкаләтләре һәм эшчәнлек тәртибе Татарстан Республикасы Сайлау кодексы белән җайга салына.

Тиешле референдумнар уздырганда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе һәм Татарстан Республикасы территориаль сайлау комиссияләре референдум комиссияләре сыйфатында эшлиләр.

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе үз карамагындагы мәсьәләләр буенча Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукына ия.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе һәм территориаль сайлау комиссияләре (район, шәһәр һәм башка комиссияләр) Татарстан Республикасының дәүләт органнары була һәм даими нигездә эшли. Аларның вәкаләтләре срогы 2010 елдан алып биш ел тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясен түбәндәгеләрнең тәкъдимнәре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм Татарстан Республикасы Президенты төзи:

Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында, Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрнең;

иҗтимагый берләшмәләрнең;

җирле үзидарәнең вәкиллекле органнарының, алдагы составтагы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең.

Комиссия хәлиткеч тавыш хокукына ия булган 14 әгъза составында төзелә. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең гамәлдәге составы 2012 елда 5 елга төзелде.

Территориаль сайлау комиссияләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе төзегәндә тәкъдимнәр кертү хокукына ия булган шул ук сәяси партияләр, иҗтимагый берләшмәләр тәкъдимнәре, шулай ук җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары, алдагы составтагы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе, җирле үзидарәнең вәкиллекле органында депутат мандатларын

бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләре тәкъдимнәре, шулай ук җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары, яшәү, эшләү, хезмәт итү, уку урыны буенча сайлаучыларның җыелышлары, алдагы составтагы территориаль сайлау комиссияләре тәкъдимнәре нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан төзелә. Территориаль сайлау комиссияләре, тиешле территориядә теркәлгән сайлаучылар санына карап, хәлиткеч тавыш хокукына ия булган 5 — 14 әгъза составында төзелә.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Татарстан Республикасында төзелә торган территориаль сайлау комиссияләре исемлеге һәм санлы составы турында» 2010 елның 12 октябрендәге 34/386 номерлы карары нигезендә Татарстанда 65 территориаль сайлау комиссиясе, шул исәптән 7 комиссия Казан шәһәре районнарында, 3 комиссия Чаллы шәһәрендә, 12 комиссия республика әһәмиятендәге шәһәрләрдә, 43 комиссия республика районнарында төзелде.

Татарстан Республикасы дәүләт тормышының һәм җирле әһәмияттәге аеруча мөһим мәсьәләләр буенча халык фикер алышуы тәртибе «Татарстан Республикасы дәүләт тормышының һәм җирле әһәмияттәге аеруча мөһим мәсьәләләр буенча халык фикер алышуы турында» 2003 елның 6 августындагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнде.

Әлеге Закон нигезендә халык фикер алышуына Татарстан Республикасы законнары проектлары, республиканың сәяси, икътисадый һәм социаль үсешенең төп юнәлешләренә, гражданнарның конституциячел хокукларын, ирекләрен һәм бурычларын гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт тормышының Татарстан Республикасы карамагындагы башка аеруча мөһим мәсьәләләренә кагылышлы карарлар проектлары чыгарыла.

Халык фикер алышуына чыгарыла торган җирле әһәмияттәге аеруча мөһим мәсьәләләр булып норматив хокукый актлар проектлары һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә карамагына кертелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләр тора.

Татарстан Республикасы законнары проектларын, республика дәүләт тормышының башка аеруча мөһим мәсьәләләрен халык фикер алышуына чыгару турындагы карар халык фикер алышуы хакындагы тәкъдим нигезендә Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителә, ул Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы хокукына ия булган субъектлар тарафыннан кертелергә мөмкин.

Норматив хокукый актлар проектларын һәм җирле әһәмияттәге аеруча мөһим мәсьәләләрне халык фикер алышуына чыгару



# IV БҮЛЕК

## СОЦИАЛЬ ҮСЕШ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЗАКОННАР

### Гражданнарның сәламәтлеген саклау, физик культура һәм спорт турындагы законнар

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба — 87-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасы компетенциясе чикләрендә республикада гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга сала.

87-ТРЗ номерлы Закон белән сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре билгеләнде. Республиканың аерым дәүләт вәкаләтләре башкару өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылырга мөмкин. Бу очракта гражданнарга медицина ярдәмен муниципаль сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары күрсәтәчәк.

Республикада сәламәтлек саклауны оештыру дәүләт, муниципаль һәм хосусый сәламәтлек саклау системалары эшчәнлегенә һәм үсешенә нигезләнә. Мәсәлән, хосусый сәламәтлек саклау системасын юридик һәм физик затлар тарафыннан төзелә торган медицина оешмалары, фармацевтика оешмалары һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә эшчәнлек белән шөгыльләнүче бүтән оешмалар тәшкил итә.

87-ТРЗ номерлы Закон белән Татарстан Республикасының эшләмәүче халкына медицина ярдәме күрсәтүне, аларны мәҗбүри медицина иминләштерүне оештыру, халык медицинасы белән шөгыльләнү мәсьәләләрен җайга сала. Сәламәтлек саклау өлкәсендә аерым категорияләрдәге гражданнарның (өч яшькә кадәрге балалар, балигъ булмаганнар, йөкле хатыннар һәм башкалар) хокуклары беркетелде.

87-ТРЗ номерлы Законда халыкка социаль әһәмияттәге авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу мөмкинлеге турында мәгълүмат җиткерү, шулай ук эпидемияләр килеп чыгу куркынычы һәм килеп чыгу турында мәгълүмат җиткерүне дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары башкара дип билгеләнде. Халыкка хәбәр итү предметы, сроклары һәм формалары билгеләнде.

Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында мәсьәләләр җайга салына.

йорт хайванын карауны аның табигый, шул исәптән тулы рационлы азыкка, суга, йокыга, физик нагрузкага ихтыяҗларын исәпкә алып башкару;

йорт хайванына ветеринария ярдәмен күрсәтүне һәм йорт хайванына карата мәҗбүри профилактик ветеринария чараларын үткәрүне үз вакытында тәэмин итү;

йорт хайванын тотканда гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итү;

гомуми файдаланудагы урыннарны һәм территорияләрне йорт хайваннары тарафыннан пычратуга юл куймау;

йорт хайванына милек хокукыннан яисә башка хокуктан баш тарткан очракта, аңа яңа хуҗа табу яисә аны күзәтүчесез хайваннарны вакытлыча тоту пунктына тапшыру.

16-ТРЗ номерлы Законның аерым статьялары этләрне тоту мәсьәләләрен җайга сала. Әйтик, 16-ТРЗ номерлы Законның 8 статьясы Татарстан Республикасы территориясендә этләрне теркәүгә багышлана, этләрне теркәү, алар турында хәбәр итеп, Татарстан Республикасы территориясендә этләрне исәпләү, кеше һәм хайваннар өчен уртак авырулар килеп чыгуны кисәтү, югалган этләрне эзләү һәм аларны хуҗаларына кайтару максатларында башкарыла. Этне теркәгәндә аның хуҗасына этне теркәү турында таныклык бирелә.

16-ТРЗ номерлы Законның 9 статьясы этләрне урамда йөртүне җайга сала һәм этне урамда йөртүче затның, әйләнәтирәдәгеләрнең иминлеген тәэмин итү максатларында, этнең хәрәкәтләрен контрольдә тотуны һәм урамда йөргәндә агрессив тәртибен булдырмаска тиешлеген билгели. Этне урамда йөртү, өч айга кадәрге көчекләрне һәм махсус сумкага (контейнерга) салынган яисә урамда йөртүче кулында булган кечкенә этләрне урамда йөртү очракларыннан тыш, бау (этне тотып тора торган башка җайланма), муенчак һәм борынчак кулланып башкарылырга тиеш. Билгеләнгән тәртиптә теркәлгән этнең муенчагында аның идентификация номеры күрсәтелгән булырга тиеш. Этне урамда баусыз йөртү торак пунктлар чикләреннән читтә, шулай ук урамда болай йөртүне рөхсәт итә торган билгеләр урнаштырылган урыннарда рөхсәт ителә.

16-ТРЗ номерлы Закон белән шулай ук үзләренең йорт хайваннарын урамда йөрткәндә эт хуҗалары үтәргә тиешле кайбер тыюлар билгеләнде.





турындагы карар үз инициативасы яисә тиешле территориядә яшәүче гражданнар таләбе буенча җирле үзидарәнең вәкиллекле органы билгеләгән тәртиптә шушы орган тарафыннан кабул ителә. Халык фикер алышуы йомгаклары хакындагы мәгълүмат халыкка җиткерелә.

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы Дәүләт Советы депутаты хокукларын һәм бурычларын билгели, үз вәкаләтләрен башкарганда төп хокукый һәм социаль гарантияләрне күз алдында тота.

Закон белән депутатның үз вәкаләтләрен башкару шартлары билгеләнде. Депутат үз эшчәнлеген төп эшчәнлегеннән аерылмыйча гамәлгә ашыра йә Дәүләт Советында профессиональ даими нигездә эшли. Дәүләт Советында профессиональ даими нигездә эшләүче депутатлар саны бүгенге көндә «Профессиональ даими нигездә эшләүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары саны турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә 20 кеше тәшкил итә.

Депутат эшчәнлегенең төп рәвешләре — Дәүләт Советы утырышларында, парламент тыңлауларында, комитетлар, Дәүләт Советы тарафыннан төзелүче килештерү комиссияләре һәм махсус комиссияләр, Дәүләт Советындагы фракцияләр һәм бүтән депутат берләшмәләре эшендә катнашу, законнар һәм Дәүләт Советы карарлары проектларын кертү, дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә һәм аларның вазыйфаи затларына депутат гарызнамәсе һәм тәкъдимнәр кертү, депутат мөрәҗәгатен җибәрү, шулай ук сайлаучылар белән эшләү һәм Татарстан Республикасы Конституциясендә, Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында каралган башка рәвешләр.

Депутат сайлаучылар белән элемтәдә тора. Бермандатлы сайлау округы буенча сайланган депутат үз округы сайлаучылары белән элемтәдә тора, ә бердәм республика сайлау округы буенча сайланган депутат исемлеге буенча үзе сайланган сайлау берләшмәсе тарафыннан төзелгән Дәүләт Советындагы тиешле фракция билгеләгән округтагы сайлаучылар белән элемтәдә тора. Депутат сайлаучылар белән очрашканда, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары аша үз эшчәнлеге турында сайлаучыларга мәгълүмат җиткерә. Моннан тыш, депутат Дәүләт Советы Президиумына сайлау округындагы эше турында мәгълүмат җиткерә. Әлеге мәгълүматны тапшыру тәртибе Дәүләт Советы

Президиумының 2011 елның 21 апрелендәге 1560-IV ДС номерлы карары белән расланды.

Депутатның ярдәмчеләре биштән артык була алмый, алар, мәсәлән, депутатка кабул итүгә язып баралар һәм алдан кабул итү уздыралар, шулай ук аналитик, мәгълүмати, белешмә һәм депутатка үз вәкаләтләрен башкару өчен кирәкле бүтән материаллар әзерли.

Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Дәүләт Советы депутатлары арасыннан Дәүләт Советы комитетларын төзи һәм сайлый. Дәүләт Советы комитетларын төзү, сайлау тәртибе һәм аларның компетенциясе «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары турында» 2004 елның 15 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнде. Комитетлар Дәүләт Советының эшчәнлеген тәэмин итә торган юнәлешләр буенча аның тарафыннан закон проекты эшен алып бару, Дәүләт Советы карамагындагы мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү, законнарның һәм Дәүләт Советы норматив хокукый актларының үтәлешен тикшереп тору өчен төзелә. Комитетлар Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукына ия була.

Комитетлар бер чакырылыш Дәүләт Советы вәкаләтләре срогына төзелә. Дәүләт Советы үз вәкаләтләре срогы дәвамында яңа комитетлар төзергә, элегрәк төзелгәннәрен бетерергә һәм үзгәртеп корырга, шулай ук аларның составларына үзгәрешләр кертергә мөмкин.

Комитетларның санлы составы, Дәүләт Советы депутатлары тәкъдимнәрен исәпкә алып Дәүләт Советының сайлаудан соңгы беренче утырышында билгеләнә, әмма ул Дәүләт Советының җиде депутатыннан кимрәк һәм унбиш депутатыннан артыграк була алмый. Дәүләт Советы депутаты бер генә комитет әгъзасы булырга мөмкин.

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын кабул итү гражданн җәмгыяте институтларын торгызуга, киң җәмәгатьчелекне Татарстан Республикасындагы дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләре буенча фикер алышуга һәм аларны гамәлгә ашыруга җәлеп итүгә таба мөһим адым булды.

Иҗтимагый палата Татарстан Республикасының дәүләти, икътисадый һәм социаль үсешенең иң мөһим проблемалары буенча ачык, хәбәрдар фикер алышуларны тәэмин итү, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан карарлар кабул ителгәндә иҗтимагый фикерне исәпкә алу механизмын камилләштерү, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле





ралар күрү вәкаләтләреннән аермалы буларак, Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына да бирелде. Моңа бәйле рәвештә 9-ТРЗ номерлы Законның исеме үзгәртелде.

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү җирле бюджетларга тиешле бюджетлардан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән генә башкарылганга күрә, 9-ТРЗ номерлы Законга кушымта итеп бирелгән Хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләү методикасы яңа редакциядә бәян ителде.

«Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» 2014 елның 7 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба — 16-ТРЗ номерлы Закон) җәмәгать тәртибен, йорт хайваннарының тискәре йогынтысыннан кешеләрне яклауны, йорт хайваннарына карата рәхимсезлек кылуны булдырмауны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның гомуми принципларын һәм төп кагыйдәләрен, шулай ук йорт хайваннарының аерым төрләрен тоту үзенчәлекләрен билгели. Шул ук вакытта авыл хуҗалыгы терлеген, фәнни оешмаларның фәнни тикшеренүләре объектлары булып торучы, хезмәт яисә коммерция максатларында кулланыла торган йорт хайваннарын, шулай ук читлектәге кыргый хайваннарны тоту өлкәсендәге мөнәсәбәтләр күрсәтелгән Закон белән җайга салынмый.

16-ТРЗ номерлы Законда йорт хайваннарын тотуның бер принцибы буларак йорт хайваннарын яклау гамәлләрен башкаруда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының катнашуы беркетелде. Моннан тыш, әлеге Законда йорт хайваннарын тоту өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләре билгеләнде.

Йорт хайваннары хуҗаларының җаваплылыгын арттыру һәм кешеләрне йорт хайваннарының тискәре йогынтысыннан яклау максатларында 16-ТРЗ номерлы Законда йорт хайваннарын тоту шартлары билгеләнде, шулай ук аларның хуҗаларының бурычлары күрсәтелде, алар арасында түбәндәгеләр бар:

нар өчен уртак булган авырулардан яклау чараларын уздыруны оештыру буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән (алга таба – 9-ТРЗ номерлы Закон) муниципаль районнар һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округы җирле үзидарә органнарына түләмә булган терлек зиратлары һәм биотермик чокырларны тоту, аларның иминлеген тәэмин итү буенча чаралар күрү, биотермик чокырларны консервацияләү буенча вәкаләтләр бирелә.

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнарының әлеге органнар тарафыннан Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән (моңа федераль бюджеттан субвенцияләр керми) мөстәкыйль рәвештә бергә башкару предметлары буенча вәкаләтләренә, Россия Федерациясе хәл итә алган мәсьәләләрдән тыш, Россия Федерациясе субъекты территориясендә хайван авыруларын кисәтү һәм бетерү чаралары, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайван өчен уртак булган авырулардан саклау чараларын оештыру мәсьәләләрен хәл итү керә.

Терлек зиратлары һәм биотермик чокырлар Россия Федерациясе субъектлары милкендәге мөлкәткә карый һәм күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда аларга ихтыяҗ туа, шуңа бәйле рәвештә терлек зиратларын һәм биотермик чокырларны тоту бурычы, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү, биотермик чокырларны консервацияләү буенча чаралар күрү Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына йөкләнә.

Күрсәтелгән вәкаләтләр түләмә булган терлек зиратлары һәм биотермик чокырлар урнашкан җирләрдә даими контрольнең булуын таләп иткәнгә күрә, әлеге вәкаләтләр 9-ТРЗ номерлы Закон белән муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына бирелде.

2013 елның 20 маендагы 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән 9-ТРЗ номерлы Законга үзгәрешләр кертелде һәм җирле үзидарә органнарына бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре исемлегенә күзәтүчесез йорт хайваннарын аулау, аларны вакытлыча тоту пунктында асрау, күзәтүчесез йорт хайваннары исәбен җайга салу вәкаләтләре өстәлде. Шул ук вакытта Татарстан Республикасының әлеге дәүләт вәкаләтләре, түләмә булган терлек зиратларын һәм биотермик чокырларны тәртиптә тоту, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү, биотермик чокырларны консервацияләү буенча ча-





үзидарә органнары белән иҗтимагый берләшмәләрнең үзара эшләвен тәэмин итү максатында төзелә.

Иҗтимагый палатаның төп бурычлары түбәндәгеләр:

1) оешмаларны һәм гражданнарны дәүләт сәясәтен булдыруга җәлеп итү, аларның дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара эшләвен тәэмин итү;

2) социаль-икътисадый өлкәне үстерү проблемалары буенча республика программаларын, Татарстан Республикасы законнарын, башкарма дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларын гамәлгә ашыру барышында иҗтимагый мониторинг уздыру, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына, программаларны гамәлгә ашыру механизмына үзгәрешләр кертү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тәкъдимнәр әзерләү;

3) гражданнарның һәм оешмаларның конституциячел хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән гражданнар инициативаларын тәкъдим итү һәм хуплау, Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын булдыруда оешмалар эшенең хәбәрдарлыгын тәэмин итү;

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, шулай ук Татарстан Республикасының массакүләм мәгълүмат чараларында сүз иреге үтәлешенә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру.

Иҗтимагый палата төзүнең төп принциплары түбәндәгеләр:

1) Иҗтимагый палата төзүдә оешмалар катнашуының иреклелеге;

2) оешмаларның оештыру-хокукый рәвешенә, санына, эшчәнлеге территориясенә бәйсез Иҗтимагый палата әгъзалыгына бер генә кандидатны тәкъдим итү хокукы;

3) дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының Иҗтимагый палата әгъзалыгына кандидатлар тәкъдим итү процессына катышмавы.

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның хокукый статусы нигезләрен, аңа бирелүче дәүләт гарантияләренең төрләрен һәм күләмен билгели, аның эшчәнлеген тәэмин итүнең бөтен мәсьәләләрен җайга сала.

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары вәкаләтләрен турыдан-туры үтәү өчен Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Рес-

публикасы законнары белән билгеләнә торган вазыйфа. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләү федераль законнарда, Татарстан Республикасы Конституциясендә, Татарстан Республикасының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының тиешле дәүләт вазыйфасына вәкаләтләр бирү, сайлау, раслау яисә билгеләп куюю юлы белән башкарыла.

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларының җыелма исемлеген раслау турында» 2006 елның 9 мартындагы 92-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларының җыелма исемлеге расланды, аңа 28 Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы кертелде.

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законын үстереп һәм аның нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын даими нигездә биләүче затларга социаль гарантияләр тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү максатларында Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга акчалата түләү турында» 2006 елның 27 мартындагы 122-ПУ номерлы Указ кабул ителде.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен оештыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләр, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт граждан хезмәтен үтү шартлары һәм аларның эшчәнлегенең гарантияләрен федераль законнар нигезендә билгеләү «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (алга таба – 3-ТРЗ номерлы Закон) җайга салына. Әлеге Закон «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» 2003 елның 27 маендагы 58-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кабул ителде.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча профессиональ хезмәт эшчәнлегеннән гыйбарәт. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары, Татарстан Республикасы судлары, Татарстан Респуб-





юридик затларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итүгә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә умартачылыкка дәүләт ярдәме күрсәтелүгә юнәлдерелде.

Законда умартачылык өлкәсендәге дәүләт ярдәме түбәндәгечә гамәлгә ашырыла дип каралды:

1) умартачылыкны үстерү буенча максатчан программаларны эшләп башкарып;

2) бал кортларының авыруларын кисәтү, аларны дәвалау, умарта күчләре корткычларына каршы көрәш һәм бал кортларын пестицидлар һәм агрохимикатлар белән агулауны булдырмау чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итеп;

3) умарталарның эпизоотиясен, карантинлы һәм аеруча куркыныч авыруларын бетерү, умартачылык өлкәсендә фәнни тикшеренүләр, шулай ук умарта кортларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау чараларын үткәрү чыгымнарына компенсацияләр биреп;

4) законнарда каралган тәртиптә салым ташламалары биреп;

5) ташламалы шартларда кредитлар бирү һәм инвестицияләр җәлеп итеп;

6) умартачылыкны үстерүгә ярдәм итүгә субсидияләр биреп;

7) Татарстан Республикасы милкендәге урман кишәрлекләрен урман турындагы законнар нигезендә умартачылык белән шөгыльләнү өчен биреп һәм күрсәтелгән максатлардагы урман кишәрлеге мәйданы бирәмлеге өчен аренда түләвенең ташламалы ставкаларын билгеләп;

8) икътисадый кызыксындыруның башка чараларын куллanып.

83-ТРЗ номерлы Законда умартачылык субъектларына дәүләт ярдәменең төп принциплары һәм шартлары бәян ителде һәм умартачылык субъектларының мондый ярдәм күрсәтелүне сорап мөрәҗәгать итү тәртибе каралды, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләргә ярдәм күрсәтүдән баш тарту очракларының ябык исемлеге билгеләнде.

83-ТРЗ номерлы Законда шулай ук күчмә умарта ояларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләрен бирү, умартачылык продуктларын сату, бал кортларын саклау мәсьәләләре җайга салына. Умарта кортларын тискәре йогынтыдан яклау һәм умартачылык продуктларының сыйфатын тәэмин итү максатларында стационар умарта ояларын урнаштыруга карата таләпләр куелды.

«Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, халыкны кеше һәм хайван-

«Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» 1996 елның 28 мартындагы 482 номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 482 номерлы Закон) Татарстан Республикасы территориясендә терлекчелекнең, кошчылыкны, җәнлекләр үрчетүне һәм умартачылыкны да кертеп, барлык тармакларында нәсел эшен оештыруның һәм гамәлгә ашыруның бердәй принципларын билгели. Әлеге Закон авыл хуҗалыгы терлекләренең булган токымнарын камилләштерү һәм яңа токымнарын, типларын, линияләрен һәм гибридларын булдыру, аларның генофондын саклау, токымлы терлекләрне үрчетүне яхшырту эшчәнлеген дәүләт тарафыннан кызыксындыруга һәм җайга салуга юнәлдерелгән.

482 номерлы Законда Татарстан Республикасы дәүләт нәсел хезмәте, җитештерү нәсел хезмәте, Нәсел эше советы, терлекчелектә нәселне исәптә тоту, нәселле хайваннарның генофондын саклау, терлекчелектә селекция казанышлары, нәсел эшен фәнни яктан тәэмин итү турында нигезләмәләр бар. Күрсәтелгән Закон шулай ук нәсел эшенә дәүләт ярдәме чараларын билгели.

482 номерлы Законны федераль законнарга туры китерү максатларында 2012 елның 20 июлендәге 61-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән 482 номерлы Законга 61 статья өстәлде, аның нигезендә нәселле терлекчелек өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан тиешенчә Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла. Моның белән бергә 482 номерлы Законның Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эшенә дәүләт идарәсе органы җитәкчесенә Татарстан Республикасының нәсел эше буенча баш дәүләт инспекторы вәкаләтләрен биргән 7 статьясы үз көчен югалткан дип танылды.

Бал кортларын карап тоту, алардан умартачылык продуктларын алу, авыл хуҗалыгының энтомофиль үсемлекләрен серкәләндерү өчен файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган «Татарстан Республикасында умартачылыкны дәүләт тарафыннан җайга салу һәм аңа дәүләт ярдәме турында» 2010 елның 22 ноябрендәге 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 83-ТРЗ номерлы Закон) умарта кортларының физик, психологик тискәре йогынтысыннан кешеләрнең иминлеген тәэмин итүгә, Татарстан Республикасы территориясендә умартачылык белән шөгыльләнүче физик һәм





ликасы законнары нигезендә оештырыла торган Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары аппаратларында гамәлгә ашырыла.

3-ТРЗ номерлы Закон белән дәүләт хезмәте принциплары, дәүләт хезмәте вазыйфаларының классификациясе, дәүләт хезмәте вазыйфаларына квалификация таләпләре, дәүләт хезмәткәренең төп бурычлары һәм гарантияләре, билгеле бер класслы чинда булу вакытын да кертеп, класслы чиннар бирү тәртибе билгеләнә. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры Татарстан Республикасы Президенты Указы белән раслана («Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы 9-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы).

Әлеге Закон белән дәүләт хезмәткәренә хезмәт өчен түләү системасы үзгәртелде. Дәүләт хезмәткәренә хезмәт өчен түләү дәүләт хезмәткәренең үзе биләгән дәүләт хезмәте вазыйфасы нигезендәге айлык окладыннан һәм дәүләт хезмәтенең аңа бирелгән класслы чины нигезендәге айлык окладыннан, шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләрдән тора, алар дәүләт хезмәткәренең айлык акчалата түләвен тәшкил итә.

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү һәм камилләштерү, аларның профессиональ хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 3-ТРЗ номерлы Закон нигезендә «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата хезмәт хакы турында» 2006 елның 5 апрелендәге 133-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы кабул ителде.

2012 елда «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителде. Әлеге Закон «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, 3-ТРЗ номерлы Закон нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең гомерен һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминләштерүе очракларын, түләүләр тәртибен һәм күләмнәрен билгели.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең гомере һәм сәламәтлеге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен узуның граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куелу көненнән алып граждан хезмәте вазыйфасыннан азат итү көненә кадәр исәпләнә торган бөтен чоры дәвамында дәүләт тарафыннан мәҗбүри иминләштерелергә тиеш.

Закон чыгару хакимиятенең иң югары органы буларак Дәүләт Советы эшчәнлегенең төп юнәлеше булып закон чыгару эшчәнлеге тора.

Россия Федерациясе субъектлары законнарын һәм бүтән норматив хокукый актларын кабул итү һәм аларның үз көчләренә керү процедурасы «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә җайга салына. Дәүләт Советының закон чыгару эшчәнлеге, үзенчәлегенә карап, шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты белән җайга салына. Закон чыгару эшчәнлеген җиренә җиткереп җайга салу өчен «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 27-ТРЗ номерлы Закон) кабул ителде.

Закон Татарстан Республикасы законнарын, Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү процедурасын җайга сала.

Закон белән Татарстан Республикасы территориясендә рәсми басылып чыккан Татарстан Республикасы законнары, Дәүләт Советы һәм аның Президиумы тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актлар гына кулланыла дип билгеләнә. Татарстан Республикасы законнары татар һәм рус телләрендә рәсми басылып Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан халыкка җиткерелә. Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актлары татар һәм рус телләрендә рәсми басылып чыгарга тиеш. Дәүләт телләрендә – татар һәм рус телләрендә басылып чыккан Татарстан Республикасы законнары, Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актлары текстлары бер үк юридик көчкә ия була.

«Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2002 елның 31 октябрендәге 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының гамәли көче кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив хокукый актларына кагыла.

Законнар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш. Басылып чыкмаган законнар кулланылмый. Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Респуб-





22-ТРЗ номерлы Законга 2014 елның 14 маендагы 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән үз ихтыяҗлары өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен төзү тәртибен (22-ТРЗ номерлы Законның 5 статьясы) билгели торган үзгәрешләр кертелде.

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы сәламәтлекне саклауга һәм уңай әйләнә-тирә мохиткә гражданнарның конституциячел хокукларын гамәлгә ашыру буенча төп шартларның берсе буларак халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелде. Әлеге Закон халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләрен билгели, шулай ук санитария һәм эпидемиягә каршы (профилактик) чараларны башкару һәм социаль-гигиеник мониторинг ясау турында нигезләмәләрне үз эченә ала.

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 1934-XII номерлы Закон) Татарстан Республикасы территориясендә ветеринария эшен оештыруның һәм гамәлгә ашыруның бердәй принципларын билгели.

Әлеге закон Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы вәкаләтләрен билгели, Татарстан Республикасында дәүләт ветеринария хезмәтен оештыруны һәм региональ дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыруны җайга сала торган нигезләмәләрне үз эченә ала, шулай ук терлек авыруларын кисәтүгә һәм бетерүгә, терлекчелек продукциясенең куркынычсызлыгын тәэмин итүгә карата гомуми таләпләр куя.

1934-XII номерлы Законга 2011 елның 18 июлендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, хайваннарның йогышлы авырулары чыганаклары барлыкка килгән очракларда, дәүләт ветеринария күзәтчелеге органнары вазыйфаи затларының хокуклары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының бурычлары билгеләнгән үзгәрешләр кертелде. Күрсәтелгән Закон белән дәүләт региональ ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашыруга кагылышлы, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендә вәкаләтле органы җитәкчесен вазыйфасына билгеләп кую һәм вазыйфасыннан азат итү тәртибенә кагылышлы нигезләмәләр төгәлләштерелә.

гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен урман фонды җирләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы милкендәге, шул исәптән республика әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләрендәге урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнарда әзерләгән агачын исәпкә алу (2014 елның 14 маендагы 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

агачны һәм аның белән алыш-бирешләр ясауны исәпкә алуның бердәм дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасына мәгълүмат тапшыру (2014 елның 14 маендагы 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

урман утыртмалары федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы билгеләгән критерийларга һәм таләпләргә туры килгән очракта, урманнарны торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман утыртмалары биләгән җирләргә кертү (2014 елның 14 маендагы 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

урман фонды җирләре чикләрендәге урман кишәрлекләреннән даими (чикләнмәгән вакытка) файдалану хокукын туктату турында карарлар кабул итү, урман фонды җирләре чикләрендәге урман кишәрлекләренә карата сервитутлар билгеләү турында килешүләр төзү, урман фонды җирләре чикләрендә урман кишәрлекләрен бирүне алдан килештерү турында карарлар кабул итү (2014 елның 15 декабрендәге 118-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы).

2012 елның 22 декабрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән 22-ТРЗ номерлы Законның урман үсентеләрен сату-алу шартнамәләре нигезендә агач әзерләүнең һәм агач булмаган урман ресурсларын әзерләүнең аерым очракларын билгели торган 3 бүлеге яңа редакциядә бәян ителде.

Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре нигезендә дәүләт ихтыяҗларын яисә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен агач әзерләүнең аерым очракларына урманны карау максатында кисүләр, санитар-савыктыру һәм янгынга каршы чаралар үткәргәндә, әгәр әлеге чаралар урманнарны саклау, яклау һәм торгызу буенча эшләрне дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары башкарганда исәпкә алынмаган булса, агач әзерләү керә дип билгеләнде.

Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре нигезендә яңа ел бәйрәмнәре өчен гражданнар, юридик затлар тарафыннан чыршылар һәм (яисә) башка ылыслы агачларны урман кишәрлекләре бирелмичә әзерләүнең аерым очракларына күрсәтелгән агач булмаган урман ресурсларын ел саен 1 ноябрьдән алып 31 декабрьгә кадәр булган, шул көнне дә кертеп, чорда әзерләү очраклары керә.





ликасының теләсә кайсы норматив хокукый акты, әгәр алар гомум игътибар өчен рәсми басылып чыкмаган булса, кулланыла алмый.

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары, әгәр шул ук актлар белән аларның үз көчләренә керүнең башка, соңрак срогы билгеләнмәгән булса, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын «Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы» (www.pravo.gov.ru) федераль электрон ресурсында урнаштыру мөмкинлеген тәэмин итү өчен «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 24 июлендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде.

Моннан тыш, «Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына һәм «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 4, 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 25 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән хокукый актларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары исемлеге киңәйтелеп «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) белән тулыландырылды.

«Татарстан Республикасы законнары җыелмасы турында» 1999 елның 15 сентябрендәге 2355 номерлы Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасы законнары җыелмасын әзерләүнең һәм чыгаруның хокукый һәм оештыру нигезләрен билгели.

Татарстан Республикасы законнары җыелмасы гамәлдәге законнарның һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Рес-

публикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларының системалаштырылган рәсми тулы җыелмасыннан гыйбарәт.

Законнар җыелмасына түбәндәгеләр керә:

– Татарстан Республикасы Конституциясе;

– Татарстан Республикасы кодекслары;

– Татарстан Республикасы законнары;

– норматив характердагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары;

– норматив характердагы Татарстан Республикасы Президенты указлары;

– норматив характердагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары.

Законнар җыелмасына Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында шартнамә керә, шулай ук Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының аерым нигезләмәләре (өземтәләре) кертелергә мөмкин.

«Татарстан Республикасы законнары мониторингы турында» 2010 елның 3 июлендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы Дәүләт Советының закон чыгару эшчәнлеге турындагы мәгълүматны җыю, анализлау, берләштерү һәм бәяләү, Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру эшчәнлеген җайга сала. Татарстан Республикасы законнарына мониторинг уздыру максаты булып кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, законлылык һәм хокук тәртибе режимын ныгыту, Татарстан Республикасы законнарының гамәли көченең нәтиҗәлелеген билгеләү тора.

Татарстан Республикасы законнары мониторингын уздыру бурычларына түбәндәгеләр керә: Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыруны тикшереп торуны тәэмин итү; Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру практикасының хокукый җайга салуның планлаштырыла торган нәтиҗәсенә туры килүен анализлау һәм бәяләү; хокукый җайга салудагы каршылыкларны, кабатлауларны һәм җитешсезлекләрне, хокук кулланучылар тарафыннан төрле мәгънәдә аңлашыла торган нормаларны, коррупция чагылышы өчен шартлар тудыруга мөмкинлек бирә торган нигезләмәләрне ачыклау; закон чыгару эшчәнлегенең перспектив юнәлешләрен билгеләү; Дәүләт Советы һәм хокук кулланучылар арасында даими элемтә булдыру; Россия Федерациясе субъектлары карамагындагы эшләргә һәм Россия Федерациясе белән Россия Федерациясе субъектларының





«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 22-ТРЗ номерлы Закон) Россия Федерациясе Урман кодексы нормаларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының урман мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтләрен билгели; Татарстан Республикасы территориясендә урманнардан файдалануга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала; гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен агач әзерләү тәртибен һәм нормативларын, гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен агач булмаган урман ресурсларын, ашарга яраклы урман ресурсларын әзерләү һәм җыю, дару үләннәрен җыю тәртибен; аучылык хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен билгели.

22-ТРЗ номерлы Закон кабул ителгәннән соң аңа төзәтмәләр шактый кертелде. Шулай итеп, Россия Федерациясе Урман кодексы нигезләмәләренең урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләрен билгеләү өлешендә үзгәртелүенә бәйле рәвештә 22-ТРЗ номерлы Законга урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары компетенциясен киңәйтүгә юнәлтелгән үзгәрешләр кертелде.

Урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләре исемлегенә Татарстан Республикасы территориясендә урман янгыннарын сүндерүнең җыелма планын федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы белән килештереп раслау вәкаләте өстәлде (2011 елның 30 июнендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы).

Урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәге вәкаләтләр кертелде:

республика әһәмиятендәге махсус саклanuлучы табигать территорияләре җирләрендә урнашкан урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруны һәм урман янгыннарын сүндерүне оештыру (2011 елның 30 июнендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрендә урнашкан урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруны оештыру (2011 елның 30 июнендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы).

Карала торган чорда 22-ТРЗ номерлы Законга Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органының урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу өлкәсендәге компетенциясен түбәндәге вәкаләтләр хисабына киңәйтә торган үзгәрешләр кертелде:

(2014 елның 7 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм мондый мәгълүматны алмашу, муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы турында яисә барлыкка килү турында халыкка үз вакытында хәбәр итүне тәэмин итү (2014 елның 7 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

вәкаләтләренә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау бурычларын хәл итү керә торган федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, шулай ук территорияләрендә гадәттән тыш хәл барлыкка килү ихтималы булган җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән килештереп, халыкка экстрен хәбәр итү зоналарының чикләрен билгеләү (2014 елның 7 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен исәпкә алып, халыкны һәм территорияләрне региональ, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә региональ дәүләт күзәтчелеген оештыру тәртибен билгеләү һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итү (2015 елның 6 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы).

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә җирле үзидарә органнары компетенциясе түбәндәге вәкаләтләр хисабына киңәйтелде:

Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасының тиешле идарә органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертү (2012 елның 29 сентябрендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

федераль законда билгеләнгән тәртиптә гадәттән тыш хәлгә карата чара күрүнең җирле дәрәҗәсен билгеләү (2012 елның 29 сентябрендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

«112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү системасын булдыруда, эксплуатацияләүдә һәм үстерүдә катнашу (2013 елның 11 апрелендәге 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирүнең муниципаль системаларын булдыру һәм даими әзерлек хәлендә тоту (2014 елның 7 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы).





уртак карамагындагы эшләргә кертелгән мәсьәләләрнең җайга салынышы дәрәҗәсен билгеләү.

Татарстан Республикасы законнары мониторингы нәтиҗәләре Татарстан Республикасының закон чыгару эшчәнлеге торышы турындагы докладның нигезе булып тора, доклад — Дәүләт Советы тарафыннан закон чыгару эшчәнлегенә йомгак ясау рәвеше, ул кабул ителгән Татарстан Республикасы законнары турында, законнар белән җайга салуның актуаль проблемалары һәм Татарстан Республикасы законнарын алга таба үстерү хакында системалаштырылган мәгълүмат белән дәүләт хакимияте органнарын, җирле үзидарә органнарын һәм Татарстан Республикасы халкын тәэмин итү максатларында әзерләнә.

Закон белән Татарстан Республикасы законнарын исәпкә алу мәсьәләләре дә тәртипкә салына, аның күрсәткечләре Татарстан Республикасы законнары мониторингын уздырганда кулланыла. Татарстан Республикасы законнарын исәпкә алганда һәр Татарстан Республикасы законы буенча мәгълүмат системалаштырыла һәм Татарстан Республикасы законы паспорты рәвешендә рәсмиләштерелә, аңа белешмә мәгълүмат (исеме, реквизитлары, законның үз көченә керү датасы, рәсми бастырып чыгару чыганагы, законның гамәлдә булу срогы); законга кертелгән үзгәрешләр турындагы белешмәләр (исеме, реквизитлары, тиешле законнарны рәсми бастырып чыгару чыганагы, аларның үз көченә керү датасы һәм гамәлдә булу срогы); Татарстан Республикасы законына карата суд карарлары, прокурор һәм юстиция органнары актлары исемлеге, шулай ук аны карау йомгаклары буенча кабул ителгән Дәүләт Советы карарлары кертелә.

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре карала. 2011 елга кадәр «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2004 елның 24 мартындагы 25-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы гамәлдә булды, аның белән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре гамәлгә куелды, аларның хокукый статусы һәм бүләкләү тәртибе билгеләнде.

2011 елда «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» яңа республика законы әзерләнде һәм кабул ителде. Яңа закон әзерләү зарурлыгы 2004 елның 24 мартындагы 25-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында бүләкләүнең гамәлдәге практикасы тулысынча исәпкә алынмаудан, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренең статус мәсьәләләренең кайберсе җайга салынмаудан килеп чыкты.

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республи-

касы Законы белән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре төшенчәсе төгәлләштерелә, гражданның Татарстан Республикасы һәм аның күпмилләтле халкы алдындагы казанышлары исемлеге киңәйтелә, бу казанышлар бүләкләү өчен нигез була, яңа гамәлгә куелган дәүләт бүләкләрен исәпкә алып Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре системасы һәм статусы билгеләнә.

Моннан тыш, 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре исемлегеннән Татарстан Республикасы Мактау Грамотасы төшереп калдырылды. Бу карарны кабул итү әлеге төр бүләкнең, ихтыяҗ булмау сәбәпле, бирелмәвенә бәйле булды.

2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре — Татарстан Республикасының дәүләти, икътисадый, социаль, фәнни һәм мәдәни үсешенә керткән зур өлешләре, законлылыкны ныгытудагы, гражданнарның сәламәтлеген һәм гомерен саклаудагы, хокукларын һәм ирекләрен яклаудагы казанышлары, тәрбияләүдәге, спортны үстерүдәге казанышлары өчен, актив хәйрия эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасы һәм аның күпмилләтле халкы алдындагы бүтән казанышлары өчен бүләкләнгәннәрнең дәүләт һәм җәмгыять тарафыннан тануның иң югары чагылышы.

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре — «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены, «Фидакарь хезмәт өчен» медале, «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале, «Ана даны — Материнская слава» медале, «Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале, 44 төрдә гамәлгә куелган Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре.

Татарстан Республикасы орденына, медальләренә һәм Татарстан Республикасының мактаулы исемнәренә Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар лаек булырга мөмкин.

Дәүләт бүләкләре турында республика законнарын гамәлгә ашыру максатларында «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2004 елның 16 июнендәге 460-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденының, «Фидакарь хезмәт өчен» медаленең тасвирламалары һәм Татарстан Республикасы мактаулы исемнәренә күкрәк тамгасының тасвирламасы расланды. Башка медальләрнең тасвирламалары Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 4 маен-





көчләрнең һәм чараларның җитәрлек булуы зарурлыгы, булган көчләрдән һәм чаралардан мөмкин кадәр күбрәк файдалану;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау мәсьәләләрен хәл иткәндә дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның иҗтимагый оешмалар һәм халык белән үзара хезмәттәшлеге;

халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлек.

62-ТРЗ номерлы Закон белән шулай ук халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының компетенциясе билгеләнә, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә дәүләт идарәсе һәм финанс тәэминаты мәсьәләләре жайга салына.

Әлеге Законда шулай ук табигатьтәге куркынычлы процессларга һәм күренешләргә мониторинг ясау, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләү һәм укыту, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә белемне пропагандалау турында нигезләмәләр бар.

62-ТРЗ номерлы Законга 2012 елның 29 сентябрендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты компетенциясен билгели торган 81 статья өстәлде, әлеге компетенциягә Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасының тиешле идарә органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертү, шулай ук федераль законда билгеләнгән тәртиптә гадәттән тыш хәлгә карата чара күрүнең төбәк (муниципальара) дәрәҗәсен билгеләү вәкаләтләре кертелде.

Карала торган чорда 62-ТРЗ номерлы Законга шулай ук халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре исемлеген киңәйтә торган үзгәрешләр кертелде.

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты компетенциясе түбәндәге вәкаләтләр хисабына киңәйтелде:

«112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләр чакыруны тәэмин итү системасын булдыру, аны эксплуатацияләүне һәм үстерүне тәэмин итү (2013 елның 11 апрелендәге 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү системаларын булдыру һәм даими әзерлек хәлендә тоту

үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 21 июлендәге 261-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертелде, аларда каралганча, углеводородлы чималны разведкалау һәм чыгаруны гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучылар җир асты байлыкларыннан файдалануны тау токымнары катламнарында ияреп чыгучы суларны һәм үзләренең җитештерү, технологик ихтыяҗларында файдаланган суларны урнаштыру өчен аерым лицензия алмыйча башкара алалар.

1722-XII номерлы Законга охшаш үзгәрешләр 2014 елның 15 декабрендәге 119-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелде.

«Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 62-ТРЗ номерлы Закон) халыкны һәм территорияләрне муниципальара һәм төбәк характерындагы табигый, техноген һәм биологик-социаль гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

62-ТРЗ номерлы Законның гамәлдә булуы муниципальара һәм төбәк характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, гадәттән тыш хәлләрдән килгән зыян һәм югалтулар күләмнәрен киметү, гадәттән тыш хәлләрдә халыкның яшәешен тәэмин итү, гадәттән тыш хәлләрне бетерү өлкәсендә дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм халыкның эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләргә кагыла.

62-ТРЗ номерлы Законда халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау гамәлгә ашырыла торган төп принциплар билгеләнде:

законлылык;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау бурычларын хәл иткәндә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар эшчәнлеген катгый регламентлаштыру;

гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә, шулай ук алар барлыкка килгәндә күргән зыян һәм югалтулар күләмнәрен мөмкин кадәр максималь киметүгә юнәлдерелгән гамәлләрне вакытында уздыру;

территорияләрнең икътисадый, табигый һәм башка үзенчәлекләрен, шулай ук гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычының реаль мөмкинлек дәрәҗәсен исәпкә алу;





дагы 221-ПУ номерлы («Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медаленә карата), 2010 елның 22 июнендәге 397-ПУ номерлы («Ана даны – Материнская слава» медаленә карата) һәм 2011 елның 22 августындагы 510-ПУ номерлы («Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медаленә карата) указлары белән расланды.

«Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия турында» 2004 елның 27 мартындагы 290-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия төзелде, аның төп максаты булып Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләргә җәмәгатьчелек бәясе бирү һәм казанышларны дәүләт һәм җәмгыять тарафыннан тануны белдерүнең иң югары төренә объектив якын килүне тәэмин итү тора.

Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 22 июнендәге 396-ПУ номерлы Указы белән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре таныклыкларының рәвешләре (үрнәкләре) һәм бүләкләү кәгазенең рәвеше расланды. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау хакында» 2011 елның 27 декабрендәге 875-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе расланды.

«30 августны Татарстан Республикасы көне – бәйрәм көне дип игълан итү турында» 1991 елның 29 августындагы Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасы Дәүләт суверенлыгы турында декларация кабул итү уңаеннан 30 августны Татарстан Республикасы көне – Татарстан Республикасы халык бәйрәме дип игълан итте. 30 август – эш көне булмаган бәйрәм көне.

Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итү уңаеннан «Татарстан Республикасы Конституциясе көне турында» 1992 елның 6 ноябрендәге 1635-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы белән 6 ноябрь бәйрәм көне – Татарстан Республикасы Конституциясе көне дип игълан ителде.

«Татарстан Республикасы бәйрәм көннәре һәм истәлекле көннәре турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә (2010 елның 14 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) түбәндәге эш көне булмаган бәйрәм көннәре билгеләнде:

Татарстан Республикасы көне – 30 август;

Татарстан Республикасы Конституциясе көне – 6 ноябрь;

Ураза бәйрәме;

Корбан бәйрәме.

Татарстан Республикасында шулай ук бәйрәм көне – Туган тел көне (26 апрель) һәм истәлекле көн – Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул иткән көне (21 май) билгеләнде.

Ай календаре һәм барлыкка килгән традицияләр нигезендә Ураза бәйрәмен һәм Корбан бәйрәмен бәйрәм итүгә туры килә торган көннәр Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә.

Татарстан Республикасында язгы кыр эшләре тәмамланганнан соң, татар халык бәйрәме «Сабан туе» һәм рус халык бәйрәме «Каравон» уздырыла. Әлеге бәйрәмнәрне уздыру көне Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә.

Татарстан Республикасында үзләрен аерым этник берлекләргә кертүче гражданнар бүтән милли бәйрәмнәр дә уздырырга хокуклы. Татарстан Республикасында гражданнар дини бәйрәмнәрне билгеләп үтәргә хокуклы.

### Дәүләт идарәсе турындагы законнар

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән (алга таба – Закон) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарын формалаштыруга һәм аларның эшләвенә бәйле хокук мөнәсәбәтләре җайга салына.

Татарстан Республикасы дәүләт башлыгы һәм Татарстан Республикасының иң югары вазыйфаи заты булган Татарстан Республикасы Президенты җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасына түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең даими эшләүче, гомуми компетенциядәге башкарма, боеру һәм коллегиаль органы булган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте;

2) тармак компетенциясендәге органнар булган Татарстан Республикасы министрлыклары, тармакара компетенциясендәге органнар булган Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары;

3) республика агентлыклары, хезмәтләре, инспекцияләре, үзәкләре, палаталары, департаментлары, комитетлары, баш идарәләре, идарәләре, комиссияләре һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең махсус компетенциядәге орган-





урнаштырганда әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясауга юл куймауны (2014 елның 15 декабрендәге 119-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы).

1722-XII номерлы Законга 2012 елның 14 июлендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалануга бирүне җайга сала торган яңа бүлек өстәлде. Бу бүлек нигезләмәләрендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән аукцион нәтиҗәләре буенча һәм аукцион үткәрмичә генә файдалану хокукын бирү очраклары билгеләнде, күрсәтелгән хокукны алу өчен кирәкле документлар исемлеге билгеләнде, аукционда катнашуга заявка алудан йә аукцион үткәрмичә генә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын алуга заявкадан баш тарту өчен нигезләр санап кителде. Моннан тыш, 1722-XII номерлы Законга гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләү турында статья өстәлде.

1722-XII номерлы Законга 2014 елның 20 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы, 2014 елның 11 апрелендәге 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә дәүләт фондына идарә итү органына түбәндәге вәкаләтләр бирелде:

гомумтаралган файдалы казылмалар ятмаларын чыгаруның техник проектларын һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшләр башкаруга бүтән проект документациясен килештерү (2014 елның 20 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен даими түләү ставкасының төгәл күләмен җир асты байлыкларыннан файдалануга билгеләнгән тәртиптә лицензия бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләренең һәркайсына аерым-аерым федераль законнарда каралган чикләрдә билгеләү (2014 елның 20 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшләре кишәрлегенең төгәлләштерелгән чикләрен таныклый торган һәм лицензиягә аның аерылгысыз состав өлеше буларак кертелә торган документларны (тау эшләре өчен бүлеп бирелгән кишәрлек турында акт һәм график кушымталар) рәсмиләштерү (Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән очракларда) (2014 елның 11 апрелендәге 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы).

«Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына

агып төшүче суларны, шул исәптән дренаж суларын агызу;
гомумтаралган файдалы казылмалар разведкалау һәм чыгару (законнарда билгеләнгән очраклардан тыш).

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 1722-XII номерлы Закон) Татарстан Республикасында җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә, алардан файдалануга һәм аларны саклауга бәйле барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Әлеге Закон белән җир асты байлыкларыннан файдалануның төп принциплары беркетелә, җир асты байлыкларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары компетенциясе билгеләнә, җир асты байлыкларыннан файдалану, җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау, җир асты байлыкларын эксплуатацияләү, җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен дәүләт тарафыннан җайга салу мәсьәләләре карала.

1722-XII номерлы Законның җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның төп хокукларын һәм бурычларын билгели торган нигезләмәләре, аның кабул ителү вакыты белән чагыштырганда, шактый үзгәрде.

Шулай итеп, 2009 елның 22 октябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән җир асты байлыкларыннан файдаланучының хокуклары исемлегенә лицензиядә яисә продукцияне бүлешү турында килешүдә билгеләнгән максатка туры килә торган эшчәнлек төрен мөстәкыйль сайлау хокукы өстәлде.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның төп бурычларына түбәндәгеләрне тәэмин итү бурычлары өстәлде:

кыйммәтле һәм хәвефле йөкләрнең, геологик, маркшейдерлык һәм башка документларның, махсус корреспонденциянең, шулай ук дәүләт серенә кертелгән белешмәләрне үз эченә алган чыганаклары булган йөкләрнең сакланышын (2012 елның 13 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

файдаланугa бирелгән җир асты байлыклары кишәрлеге чикләрендә урнашкан казылма табу урыннарының, бораулау скважиналарының һәм җир асты байлыкларыннан файдаланугa бәйле башка корылмаларның куркынычсызлыгын (2014 елның 11 апрелендәге 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

тау токымнары катламнарында ияреп чыгучы суларны һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның үзләренең җитештерү, технологик ихтыяҗлары өчен файдаланган суларын





нар буларак төзелүче башка органнары (Татарстан Республикасы ведомстволары);

4) Татарстан Республикасы вәкиллекләре.

Әлеге Законны үтәү йөзеннән «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте составына керүче вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2010 елның 22 апрелендәге 255-ПУ номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте составына керүче вазыйфаи затлар исемлеге расланды.

Тыю һәм каршы булу системасын булдыру, республикада закон чыгару һәм башкарма хакимиятләрнең тотрыклылыгын һәм мөстәкыйльлеген бозмыйча аларның балансын тәэмин итү максатларында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законында Дәүләт Советының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын формалаштыруда катнашу мәсьәләсе җайга салына. Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Премьер министры кандидатурасын раслый, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларын билгеләп кую, Татарстан Республикасы министрлыкларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт комитетларын төзү һәм бетерү турында Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен килештерә. Яңа төзелгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз вәкаләтләре чорына киләчәк эшчәнлеге программасын Дәүләт Советы каравына тәкъдим итә.

Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Премьер-министрына һәм аның урынбасарларына ышанычсызлык белдерергә мөмкин, бу аларның отставкасына китерергә мөмкин.

Татарстан Республикасы министрлыклары һәм Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары, Дәүләт Советы белән килештереп, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан төзелә.

Үз чиратында республика парламентының закон чыгару эшчәнлегендә закон чыгару инициативасы хокукына ия бүтән субъектлар белән бергә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты да катнаша.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Президенты, Дәүләт Советы кушуы буенча йә үз инициативасы буенча законнар проектларын, Дәүләт Советы карарлары проектларын әзерләүне оештыра һәм аларны Дәүләт Советы каравына кертә. Татарстан Республикасы Дәүләт Сове-

ты Регламенты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Дәүләт Советы каравында булган закон проектларына төзәтмәләр һәм Дәүләт Советы карарлары проектларына үзгәрешләр кертергә, шулай ук Дәүләт Советы карый торган законнарга һәм закон проектларына рәсми бәяләмәләрне Дәүләт Советына җибәрергә хокуклы.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Дәүләт Советына Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында, шулай ук Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән аерым мәсьәләләр буенча хисаплар тәкъдим итә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының мөһим вәкаләте – Татарстан Республикасы министрлыклары һәм Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары һәм аның ведомствосындагы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары эшен берләштерү һәм аларга юнәлеш бирү, шулай ук аларның эшчәнлеген тикшереп тору.

2014 елның 11 апрелендәге 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертелде. Республика башкарма хакимияте органнарының үз вәкиллекләрен булдыру мөмкинлеге турындагы нигезләмәләр төшереп калдырылды. Бу үзгәреш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасының законга караган норматив хокукый актларын кабул итүнең мониторингын уздыру нәтиҗәләре буенча кертелде, аның нигезендә 2005 елдан («Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Законны кабул итү елы) алып мондый вәкиллекләр булдыруның бер генә очрагы да ачыкланмаган.

Моннан тыш «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезләмәләрен үстерү йөзеннән «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының һәм республика башкарма хакимияте органнарының кабул ителгән норматив хокукый актларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрүләре турындагы нигезләмәләр белән тулыландырылды.

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» 2003 елның 10 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән (алга таба – 47-ТРЗ номерлы Закон) Татар-





рәвештә бердәм дәүләт экология мониторингы системасының ярдәмче системалары кысаларында күзәтчелек челтәрләрен һәм мәгълүмат ресурсларын булдырып һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итеп, шулай ук дәүләт экология мониторингының дәүләт мәгълүматлар фондын Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан төзеп һәм аннан файдаланып гамәлгә ашырылуы билгеләнде. Дәүләт экология мониторингын ясауда катнашучы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары аны уздыру барышында алган мәгълүматларын дәүләт экология мониторингының дәүләт мәгълүматлар фондына тапшырып барырга тиеш.

Татарстан Республикасы Экология кодексының бердәм дәүләт экология мониторингы системасына керми торган мөстәкыйль экология мониторингы системасы дип билгеләнгән әйләнә-тирә мохитнең һәм табигать ресурсларының бердәм региональ экология мониторингы системасын төзү һәм эшләтү мәсьәләләрен җайга сала торган статьялары үз көчләрен югалткан дип танылды.

2014 елның 14 маендагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Экология кодексының махсус саклана торган табигать территорияләрен булдыру һәм аларга идарә итү мәсьәләләрен җайга сала торган нигезләмәләре үзгәртелде. Әлеге Закон белән махсус саклана торган табигать территорияләренең категорияләре билгеләнде, кайбер төшенчәләргә төзәтмәләр кертелде, аларны булдыру тәртипләре тәгаенләнде. Эчтәлекләре белән федераль законнарга туры килмәгән аерым статьялар үз көчләрен югалткан дип танылды.

2014 елның 23 июлендәге 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертелде һәм су саклау зоналарыннан файдалануга карата өстәмә тыюлар билгеләнде. Кертелгән үзгәрешләрдә каралганча, су саклау зоналарында түбәндәгеләр тыела:

автомобильләргә ягулык салу станцияләре, ягулык-майлау материаллары складлары (моңа автомобильләргә ягулык салу станцияләре, ягулык-майлау материаллары складлары, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар һәм су турындагы законнар таләпләре үтәлеп, портлар, суднолар төзү һәм суднолар ремонтлау оешмалары, эчке су юллары инфраструктурасы территорияләрендә урнашкан очраклар керми), транспорт чараларын техник карау һәм ремонтлау өчен файдаланыла торган техник хезмәт күрсәтү станцияләре урнаштыру, транспорт чараларын юу;

пестицидлар һәм агрохимикатлар саклау өчен махсуслаштырылган урыннар булдыру, пестицидлар һәм агрохимикатлар куллану;

Татарстан Республикасы Экология кодексы нигезләмәләрен федераль законнарга туры китерү өчен аңа 2010 елның 16 маендагы 20-ТРЗ номерлы һәм 2012 елның 13 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары белән үзгәрешләр кертелде. Үзгәрешләр дәүләт региональ экология күзәтчелеген башкаруны, дәүләт күзәтчелеге органнарының вазыйфаи затлары хокукларын, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендәге эшчәнлек башкаруны, шулай ук экологик сертификацияләүне җайга сала торган нигезләмәләргә кагылды.

Татарстан Республикасы Экология кодексына 2011 елның 30 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән ау һәм аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган 1351 – 1357 статьялар өстәлде. Мәсәлән, яңа статьялар белән Татарстан Республикасы Экология кодексына Татарстан Республикасы территориясендә аучылык хуҗалыгы реестрын алып бару, аучылык ресурсларының һәм аларның яшәү тирәлегенең дәүләт мониторингы, ау һәм аучылык ресурсларын саклап калу өлкәсендә нормалар кертү турында нигезләмәләр өстәлә. Шулай ук һәркем өчен ачык аучылык урыннарында ау белән шөгыльләнүче физик затлар арасында аучылык ресурсларын атуга рөхсәтләр бүлү тәртибе билгеләнә.

Тояклы хайваннардан тыш, аучылык ресурсларын атуга рөхсәт алу хокукын бирү чираты аучылардан мөрәҗәгатьләр керү тәртибе буенча бирелә, дип билгеләнде. Тояклы хайваннарны атуга рөхсәт алу хокукы тиешле гариза биргән аучылар арасында очраклы сайлап алу (шобага тоту) буенча бирелә, аның төгәл тәртибе бар.

Татарстан Республикасы Экология кодексын федераль законнарга туры китерү максатларында 2013 елның 12 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Экология кодексының дәүләт экология мониторингын (әйләнә-тирә мохиткә дәүләт мониторингын) ясауны җайга сала торган нигезләмәләргә төзәтмәләр кертелде.

Кертелгән үзгәрешләр нигезендә «дәүләт экология мониторингы» терминына яңа билгеләмә бирелде, хәзер ул әйләнә-тирә мохитнең, шул исәптән табигать мохите компонентларының, табигый экологик системаларның торышына, аларда бара торган процессларга, күренешләргә комплекслы күзәтүне, әйләнә-тирә мохит торышындагы үзгәрешләрне бәяләүне һәм фаразлауны аңлата.

Шулай ук дәүләт экология мониторингының федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан бердәм дәүләт экология мониторингы системасы кысаларында аларның компетенциясенә ярашлы





стан Республикасы вәкиллекләре статусы, аларны төзү, оештыру тәртибе һәм аларның эшчәнлек тәртибе билгеләнә.

Татарстан Республикасы вәкиллекләре Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясе һәм аның субъектлары арасындагы үзара мөнәсәбәтләрдә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасының тышкы, шул исәптән чит дәүләтләрнең субъектлары һәм административ-территориаль берәмлекләре, халыкара оешмалар, ә Россия Федерациясе Хөкүмәте ризалыгы белән – чит илләрнең дәүләт хакимияте органнары белән, халыкара һәм тышкы икътисадый, сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, экологик, гуманитар, мәдәни һәм башка өлкәләрдәге багланышларын һәрьяклап үстерү максатларында ачыла.

47-ТРЗ номерлы Закон нигезендә Татарстан Республикасы вәкаләтле, даими һәм сәүдә-икътисад вәкиллекләре, халыкара оешмалар каршында даими вәкиллекләр төзергә мөмкин. Әлеге Закон Татарстан Республикасы вәкиллегенең төп функцияләрен, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вазыйфасына билгеләнеп куела һәм вазыйфасыннан азат ителә торган Татарстан Республикасы вәкиллеген җитәкләүче Татарстан Республикасы вәкиленең вәкаләтләрен билгели.

Чит дәүләтләрдә һәм Россия Федерациясе регионнарында Татарстан Республикасының уннан артык вәкиллеге төзелде.

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында була.

Бөтендөнья практикасы нигезендә кеше хокукларын яклау системасының үзәк элементларының берсе – омбудсмен яисә кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил. Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институтының күпьеллык халыкара тарихы бар. Аның эшчәнлеге бозылган хокукларны һәм ирекләрне торгызу максатларында граждан һәм хакимият органнары арасында үзара хезмәттәшлекнең нәтиҗәле механизмын булдыруга юнәлдерелгән. Шул ук вакытта әлеге эшчәнлек нәтиҗәлелегенең иң мөһим гарантларының берсе булып кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең закон чыгару, башкарма һәм суд хакимиятенең дәүләт органнарыннан бәйсез булуы тора.

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (алга таба – Вәкаләтле вәкил) вазыйфасы гамәлгә кертелде.

Закон Вәкаләтле вәкил вазыйфасына сайлап кую, аның вәкаләтләрен туктату һәм аны вазыйфасыннан азат итү тәртибен, аның компетенциясен, эшчәнлеген оештыру рәвешләрен һәм шартларын билгели.

Вәкаләтле вәкил вазыйфасы кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен дәүләт тарафыннан яклау гарантияләрен көчәйтү, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар тарафыннан бу хокукларның үтәлүенә һәм ихтирам ителүенә ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә гамәлгә куела.

Вәкаләтле вәкил үз вазыйфасына Дәүләт Советының сайланган депутатларының күпчелек тавышы белән Дәүләт Советы тарафыннан, ант итү вакытыннан алып, биш елга сайлана.

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы бәйсез һәм мөстәкыйль, махсус закон нигезендә эшләүче Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (алга таба – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил) институтын оештыру максатларында әзерләнде.

Әлеге Закон Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең статусын, компетенциясен, үз вазыйфасына сайлану һәм аны вазыйфасыннан азат итү тәртибен, шулай ук аның эшчәнлеген тәэмин итү нигезләрен һәм гарантияләрен, принципларын, вәкаләтләрен, гражданнар мөрәҗәгатьләрен (шикаятьләрен) карау тәртибен һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең башка мәсьәләләрен билгели.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы булып тора. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда, бәйсез була һәм кайсы да булса Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларга хисап бирми.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен дәүләт тарафыннан яклауның гамәлдәге чараларын тулыландыра, бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауны, баланың бозылган хокукларын торгызуны тәэмин итүче Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар компетенцияләрен юкка чыгармый һәм яңадан карауга китерми.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына 35 яшьтән дә яшь булмаган, юридик яисә педагогик югары





дәрәҗәдә кертеп, җәмгыятьнең икътисадый үсеше буенча заманча таләпләргә җавап бирә торган яңа хокукый институтлар булдыруның кирәклегенә бәйле.

Татарстан Республикасы Экология кодексы әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясый торган хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашырганда җәмгыять белән табигать арасында барлыкка килә торган үзара тәэсир итүгә караган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Татарстан Республикасы Экология кодексы түбәндәгеләр билгеләнде:

әйләнә-тирә мохитне саклауның төп принциплары;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының экология өлкәсендәге вәкаләтләре;

экология өлкәсендә гражданнарның, иҗтимагый һәм коммерциягә карамаган берләшмәләрнең хокуклары һәм бурычлары;

экологик нормалалар билгеләү нигезләре;

экологик экспертиза төрләре һәм аны ясау тәртибе;

экологик контроль максатлары һәм төрләре;

дәүләт региональ экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру нигезләре;

әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән нәтиҗәле файдалану өлкәсендә икътисадый җайга салу алымнары;

экология һәм экологик иминлек гарантияләрен тәэмин итү өлкәсендәге фәнни тикшеренүләрнең максатлары;

Татарстан Республикасында экологик белем бирүнең һәм агартуның төп принциплары, системасы;

атмосфера һавасын, су объектларын, җир ресурсларын һәм туфракларны, үсемлекләр дөньясын, урманнарны, хайваннар дөньясын, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланганда әйләнә-тирә мохитне, махсус саклана торган табигать территорияләрен саклауга карата таләпләр;

җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү тәртибе һ.б.

Татарстан Республикасы Экология кодексы кабул ителүгә бәйле рәвештә «Хайваннар дөньясын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында», «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында», «Үсемлекләр дөньясы турында», «Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында», «Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында», «Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау турында» Татарстан Республикасы законнары үз көчләрен югалткан дип танылды.

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын тәэмин итү максатларында кулланыла торган агрохимикатларның һәм пестицидларның сыйфатын тикшереп тору һәм алар белән куркынычсыз эш итүне тикшереп тору;

җир кишәрлекләре милекчеләренә, алардан файдаланучыларга, аларның хуҗаларына һәм аларны арендалаучыларга авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын тәэмин итү һәм аларның мөрәҗәгатьләре буенча агрохимик хезмәт күрсәтү мәсьәләләре хакында мәгълүмат бирү.

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турында» 2003 елның 6 августындагы 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба — 28-ТРЗ номерлы Закон) «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында» Федераль законның 1 статьясындагы 4 пункты нигезендә кабул ителде, анда каралганча, әлеге җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән вакыттан гамәлгә ашырыла.

28-ТРЗ номерлы Законның 1 статьясында: Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру әлеге Закон үз көченә кергән вакыттан — рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач — гамәлгә ашырыла, дип билгеләнде.

28-ТРЗ номерлы Законның 2 статьясында: бер муниципаль район территориясендә урнашкан һәм бер граждан һәм (яисә) бер юридик зат милкендә торырга мөмкин булган авыл хуҗалыгы җирләренең гомуми мәйданының максималь күләме мондый җир кишәрлекләрен бирү һәм (яисә) сатып алу вакытына күрсәтелгән территориядә урнашкан авыл хуҗалыгы җирләренең гомуми мәйданының 25 процентыннан артык була алмый, дип билгеләнде.

### Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар

Татарстан Республикасының табигатьне саклау законнарын камилләштерү максатларында әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсенә кагылышлы гамәлдәге законнар урынына бердәй кодлаштырылган хокукый акт әзерләү зарурлыгы килеп туды.

Татарстан Республикасы Экология кодексын кабул итү әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсенә кагылышлы мөнәсәбәтләрне тармак эчендә хокукый җайга салудан комплекслыга күчүнең, законнардагы эчке каршылыкларны һәм бушлыкларны бетерүнең, турыдан-туры тәэсир итә торган нормаларны максималь





һөнәри белемле, үзенә тап төшергән гамәлләр кылмаган, балалар проблемаларын белүче йә балалар белән эш тәҗрибәсенә, йә бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә эш тәҗрибәсенә ия зат — Россия Федерациясе гражданы сайланып куела.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үз вазыйфасына Дәүләт Советының сайланган депутатларының күпчелек тавышы белән Дәүләт Советы тарафыннан сайлана. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатураны Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Президенты тәкъдим итә.

Бүгенге көндә Россия Федерациясе субъектларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрне гамәлгә кую һәм аларның эшчәнлеге мәсьәләләре федераль законнар белән җайга салынмаган. Шуңа күрә Россия Федерациясе субъектлары бала хокуклары буенча региональ вәкаләтле вәкил институтын гамәлгә кую һәм аның эшчәнлеген җайга салу мәсьәләләрен хәл итү рәвешләрен мөстәкыйль билгелиләр.

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 11 ноябрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән 59-ТРЗ номерлы Законга үзгәрешләр кертелде, алар Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең оештыру-хокукый рәвешенә һәм милек рәвешенә бәйсез рәвештә оешмалар эшчәнлегенә тикшерү үткәрү хокукы турындагы нигезләмәләрне конкретлаштыруга юнәлдерелгән.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, ачыкланырга тиешле хәлләргә тикшерү үткәрүдә булышлык күрсәтүне сорап, җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хокукы бирелде, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гарызнамәләре буенча аның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләрне, документларны, материалларны, башка мәгълүматны тоткарлыксыз бирү мәҗбүрилеге беркетелде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләре — шәхеснең хокукларын гамәлгә ашыру һәм яклау, дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының халык белән элемтәсен ныгыту чарасы. Гражданнар мөрәҗәгатьләре дәүләт һәм җәмгыять әһәмиятендәге мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле мәгълүматның мөһим чыганагы, шулай ук гражданнарның дәүләт һәм җәмгыять эшләренә идарә итүдә катнашуның иң мөһим рәвешләренең берсе булып тора.

Гражданнарның дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм вазыйфаи затларга мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен билгеле торган «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 16-ТРЗ номерлы Закон) хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында яңа редакциядә бәян ителде («Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 24 июлендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы).

Татарстан Республикасында һәр граждан дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм аларның вазыйфаи затларына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә һәм халык өчен әһәмиятле булган функцияләрне гамәлгә ашыру йөкләнгән башка оешмаларга һәм аларның вазыйфаи затларына (алга таба – органнар һәм вазыйфаи затлар) шәхсән яисә вәкиле аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук индивидуаль һәм коллектив мөрәҗәгатьләр, моңа гражданнар, шул исәптән юридик затлар берләшмәләренең мөрәҗәгатьләре дә керә, җибәрергә хокуклы.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен бирүнең билгеләнгән тәртибе белән беррәттән 16-ТРЗ номерлы Закон белән мөрәҗәгатьнең органга, вазыйфаи затка телеграмма яисә факсимиль элемтә аша тапшырылу мөмкинлеге билгеләнә; вәкаләтләре туктатылган вазыйфаи затка адресланган мөрәҗәгатьне карауга кабул итү мәҗбүрилеге карала; органга яисә вазыйфаи затка үз компетенцияләре буенча кергән барлык төр индивидуаль һәм коллектив мөрәҗәгатьләр язмача мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып 30 көн эчендә карала; гражданнарны шәхси кабул итүне оештыру тәртибе һәм органнарның «турыдан-туры элемтә» һәм «мөһим элемтә» телефоннары буенча кабул ителгән гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау процедурасы регламентлаштырыла; гражданнарның коллектив мөрәҗәгатькә язмача җавап алуның өстәмә гарантияләре билгеләнә.

Гражданнар хокукларының конституциячел гарантияләренең берсе булып түләүсез юридик ярдәм алу мөмкинлеге тора. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 73-ТРЗ номерлы Закон) «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 324-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең хокукый нигезләрен билгели.





алардан файдаланучылар, шул исәптән арендалаучылар тарафыннан хуҗалык эшчәнлеге башкарылганда, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

595 номерлы Законда җир кишәрлекләре милекчеләренең, аларның хуҗаларының, алардан файдаланучыларның авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендәге хокуклары һәм бурычлары билгеләнә, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын дәүләт тарафыннан тәэмин итүне түбәндәге төп юнәлешләр буенча гамәлгә ашыру күздә тотыла:

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын тәэмин итүнең максатчан программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, күрсәтелгән программаларның үтәлешен тикшереп тору;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу һәм нәтиҗәле файдалану чараларын финанс, ресурс, җитештерү ягыннан, фәнни яктан һәм кадрлар белән тәэмин итү;

җир кишәрлекләре милекчеләрен, хуҗаларын, алардан файдаланучыларны авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын арттыруда икътисадый кызыксындыру, эрозиягә каршы чаралар комплексын гамәлгә кертү, җирдән файдаланучылар территориясендәге, махсус саклана торган табигать территорияләрендәге табигый туфрак комплексларын саклап калу;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы торышы күрсәткечләрен дәүләт тарафыннан исәпкә алуны башкару һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы торышына мониторинг ясау;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә махсус бүлеп бирелгән кишәрлекләрнең туфрагын билгеләү һәм исәпкә алу, аларның торышына мониторинг ясау;

радионуклидлар, авыр металлар һәм башка зарарлы матдәләр белән пычранган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне реабилитацияләү чаралары планнарын эшләү;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә агротехник, агрохимик, мелиоратив, фитосанитар һәм эрозиягә каршы чаралар үткәрү планнарын эшләү;

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендәге законнарның үтәлешен дәүләт тарафыннан тикшереп тору;

тәртибе билгеләнде. Моннан тыш, җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән бергә җирле үзидарә органнарына гражданнар тарафыннан тапшырыла торган документларның ябык исемлеге билгеләнде, бу, мөрәҗәгать итүчеләрне җир кишәрлеген алу хокукы булган гражданнар исемлекләренә кертү турында җирле үзидарә органнары тарафыннан карарлар кабул ителгәндә, өстәмә документлар таләп итү ихтималын юкка чыгара. Гражданнарны югарыда күрсәтелгән исемлекләргә керткәндә, аларга махсус исәпкә алу номерлары бирелә, соңыннан ул номерлар, чиратлылыкны күрсәтеп, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтына урнаштырыла, бу җир кишәрлекләрен бирүне мөмкин кадәр ачык алып барырга ярдәм итә.

Индивидуаль торак төзелешен, дача төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен җир кишәрлекләрен бирүгә альтернатива буларак, өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга үзләре милкендәге торак йорт урнашкан җир кишәрлеген, әлеге җир кишәрлеге аларга элек биләү яисә файдалану өчен бирелгән булса, милек итеп яңадан рәсмиләштерү хокукы бирелә.

Гражданнарның җир кишәрлекләрен кабат алуын булдырмау максатында, җир кишәрлекләре милек итеп бирелгән (тапшырылган) гражданнарның реестрын алып бару бурычы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органына йөкләнә.

Россия Федерациясе Җир кодексының 79 статьясында уңдырышлылыгы ягыннан аеруча кыйммәтле авыл хуҗалыгы җирләре Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә башка максатларда файдаланылуы рөхсәт ителми торган җирләр исемлегенә кертелергә мөмкин дип билгеләнгән. Күрсәтелгән мәсьәләне законнар белән җайга салу хокукы 2014 елның 7 мартындагы 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә ашырылды. Әлеге Законда Татарстан Республикасы территориясендәге уңдырышлылыгы ягыннан аеруча кыйммәтле авыл хуҗалыгы җирләренә керә торган, алардан башка максатларда файдалану рөхсәт ителми торган авыл хуҗалыгы җирләре, мондый җирләрнең исемлеген төзү һәм бастырып чыгару тәртибе билгеләнде.

«Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгы турында» 2001 елның 24 гыйнварындагы 595 номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 595 номерлы Закон), җир кишәрлекләренең милекчеләре, аларның хуҗалары,





73-ТРЗ номерлы Закон белән Татарстан Республикасында гражданнарга күрсәтелә торган түләүсез юридик ярдәм төрләре, дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия булган гражданнарның категорияләре билгеләнә. 73-ТРЗ номерлы Закон нигезендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар булып Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм аларга ведомство буйсынуындагы учреждениеләр, законнар нигезендә бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары тора. Адвокатлар Татарстан Республикасында дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Федераль законда һәм 73-ТРЗ номерлы Законда каралган тәртиптә катнаша.

Дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучылар юридик клиникалардан (студентларның консультацияләр бюроларыннан, студентларның юридик бюроларыннан һәм башкалардан) һәм дәүләтнеке булмаган түләүсез юридик ярдәм үзәкләреннән гыйбарәт.

Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү өлкәсендә федераль законнарның үзгәрүенә бәйле рәвештә 73-ТРЗ номерлы Законга үзгәрешләр кертелде, алар түләүсез юридик ярдәм алу хокукына ия булган гражданнарның категорияләрен киңәйтүгә юнәлдерелгән. Күрсәтелгән гражданнар категорияләре түбәндәгеләр белән тулыландырылды:

ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар;

баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы гаиләгә тәрбиягә урнаштыруга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүче затлар;

уллыкка алынган балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, уллыкка алучылар;

Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары.

73-ТРЗ номерлы Законны гамәлгә ашыру максатларында түбәндәге норматив хокукый актлар кабул ителде:

«Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучыларның үзара эшләү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 24 маендагы 444-ПУ номерлы Указы;

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-

ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 2 февралендәге 69 номерлы карары, ул Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгын Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү һәм авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга ашыгыч очракларда түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында карар кабул итү өлкәсендә вәкаләтле органы дип билгеләде;

«Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатларга хезмәт өчен түләү һәм түләүсез юридик ярдәм күрсәтүгә адвокатларның чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 21 октябрендәге 774 номерлы карары, аның нигезендә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы адвокатларга хезмәт өчен түләүгә һәм адвокатларның чыгымнарын компенсацияләүгә каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларының баш бүлүчесе булып тора.

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 91-ТРЗ номерлы Закон) Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар (алга таба – гавами чаралар) уздыруда катнашуга конституциячел хокукын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән һәм ул «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә эшләнде. 91-ТРЗ номерлы Закон белән түбәндәгеләр билгеләнде:

гавами чаралар уздыру турында хәбәрнамә бирү тәртибе;

гавами чаралар уздыру урыннарын билгеләү тәртибе;

махсус бирелгән урыннардан файдалану тәртибе;

гавами чаралар уздырганда махсус бирелгән урыннар тулуның иң чик нормалары;

иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләр турында күмәк фикер алышуда катнашучы затларның иң чик саны;

пикет уздырганда затлар арасындагы мөмкин булган минималь ара;





гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез бирү мөмкинлеге каралган нигезләмәләрен үстереп, 2011 елның 18 ноябрендәге 90-ТРЗ номерлы, 2012 елның 17 маендагы 22-ТРЗ номерлы, 2012 елның 29 маендагы 27-ТРЗ номерлы, 2014 елның 23 июлендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары белән үзгәрешләр кертелде.

Күрсәтелгән үзгәрешләр нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче һәм составында язылышкан яисә язылышмаган, әмма бергә яшәүче ата-аналар (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр) йә ата-ананың (уллыкка алучының, опекунның, попечительнең) берсе, шулай ук җир кишәрлеген үзләренә милеккә бирү (тапшыру) турында гариза бирелгән көнгә унсигез яше тулмаган өч яисә аннан күбрәк баласы, шул исәптән үги уллары, үги кызлары, уллыкка (кызлыкка) һәм опекага алынган (опека һәм попечительлек чикләнмәгән вакытта йә балигъ яшькә җиткәнче гамәлгә ашырыла торган) балалары булган күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре түләүсез бирелә (тапшырыла). Мондый очракта күпбалалы гаилә составына язылышмаган, әмма аларның кимендә өч уртак баласы булган атасы да, анасы да кертелә. Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар күпбалалы гаилә составына кертелми.

Гражданнар җир кишәрлекләрен түләүсез алу (тапшыру) хокукыннан бер мәртәбә генә файдалана алалар. Бу вакытта җир кишәрлеге милекчеләре хокукын алган балаларның, алар балигъ яшькә җиткәннән соң, шушы нигезләр буенча үзләренә бер тапкыр түләүсез җир кишәрлеге бирү (тапшыру) хокуклары саклана кала.

Җир кишәрлекләре, торглар уздырмыйча һәм объектларны урнаштыру урыннарын алдан килештермичә, индивидуаль торак төзелешен, дача төзелешен башкару, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен бирелергә мөмкин. Шәһәр округы территориясендә даими яшәүче гражданнарга җир кишәрлекләре тиешле шәһәр округы чикләрендә яисә, гражданның ризалыгы белән, башка муниципаль берәмлекләр территориясендә урнашып, шәһәр округы милкендә булган җир кишәрлекләреннән бирелә. Муниципаль район составына керүче шәһәр яисә авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнарга җир кишәрлекләре тиешле шәһәр яисә авыл җирлеге чикләрендә йә, муниципаль районның вәкиллекле органы хокукый акты белән билгеләнгән очракларда, шушы муниципаль район составындагы башка җирлек чикләрендә бирелә.

Татарстан Республикасы Җир кодексында күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләрен бирү тәртибе җентекле рәвештә регламентлаштырылды, тиешле гамәлләр кылу сроклары һәм

2012 елның 29 сентябрендәге 68-ТРЗ номерлы Закон белән гражданны торак урынга мохтаҗ дип таныганда документлар әйләнеше тәртибенә төзәтмәләр кертелде, шулай ук өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарның, торак йорт төзү өчен җир кишәрлеге алу хокукын гамәлгә ашыру-ашырмауларына бәйсез рәвештә, социаль наем шартнамәләре буенча дәүләт һәм муниципаль торак фондларының торак урыннары белән тәэмин ителү хокукын саклап кала торган норма беркетелде.

### Җир мөнәсәбәтләре өлкәсендәге законнар

Татарстан Республикасы Җир кодексы җир мөнәсәбәтләрен җайга сала торган Россия законнары тормыш чынбарлыгына туры килмәгән һәм алар бик аз булган шартларда кабул ителде.

Ул чорда 1993 елның 24 декабрендә соңгы тапкыр үзгәрешләр кертелгән РСФСР Җир кодексы гамәлдә иде, бу үзгәрешләрнең максаты Кодексны законнарга һәм икътисадый системага туры китерүгә түгел, ә 1991 елның 25 апрелендәге РСФСР Җир кодексының илле беренче статьясы нигезләмәләрен үз көчләрен югалткан дип танудан гыйбарәт булды. Ул вакытта Россия Федерациясе Граждан кодексының «Җиргә милек хокукы һәм башка хокуклар» турындагы 17 бүлеге дә гамәлдә түгел иде. Шул рәвешле Россия Федерациясенең комплекслы җир законнары бөтенләй булмады диярлек.

Татарстан Республикасы Җир кодексы беренче мәртәбә гражданнарга һәм юридик затларга, шул исәптән чит ил гражданнарына һәм юридик затларына, милек хокукында җир кишәрлекләре сатып алу мөмкинлеген бирде, шуңа күрә 2001 елга, Россия Федерациясе Җир кодексы кабул ителгән вакытка, Татарстан Республикасы аны практикада гамәлгә ашыруга әзер иде инде.

Татарстан Республикасы Җир кодексында җирләрнең максатчан билгеләнешенә; җирләрнең составына; җир кишәрлекләренә милек хокукларына һәм башка хокукларга; җир ресурсларына идарә итүгә, җирләрне саклауга; дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге җирләрне гражданнар һәм юридик затлар милкенә бирүгә; җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир хуҗаларының һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларның хокукларына һәм бурычларына; җиргә хокукларны туктатуга; авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнешенең үзенчәлекләренә багышланган нигезләмәләр бар.

Татарстан Республикасы Җир кодексына, Россия Федерациясе Җир кодексының өч һәм аннан күбрәк баласы булган





тарихи һәм мәдәни ядкәрләр булган объектлар территорияләрендә гавами чара уздыру тәртибе;

гомуми файдаланудагы транспорт өчен кулланыла торган транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру тәртибе;

транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру урынын һәм (яисә) вакытын үзгәртү;

гавами чаралар уздыру тыела торган урыннар.

Дәүләт идарәсе механизмының состав өлешен Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагында булган административ хокук бозулар һәм административ җаваплылык турындагы законнар тәшкил итә. Татарстан Республикасында әлеге мәсьәлә буенча үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы кабул ителде.

Административ хокук бозулар турындагы законнарның бурычларына шәхесне яклау, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, гражданнар сәламәтлеген, халыкның санитария-эпидемиология иминлеген саклау, иҗтимагый әхлаклылыкны яклау, әйләнә-тирә мохитне саклау, дәүләт хакимиятен гамәлгә ашыруның билгеләнгән тәртибен, иҗтимагый тәртипне һәм җәмәгатьчелек иминлеген, милекне саклау, физик һәм юридик затларның, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең законлы икътисадый мәнфәгатьләрен административ хокук бозулардан саклау, шулай ук административ хокук бозуларны кисәтү керә.

Кодекста хокукларны, аерым алганда, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау, төзекләндерү, иҗтимагый тәртипне саклау һәм су объектларында кешеләрне хәвеф-хәтәрдән саклау, милекне, транспортны саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын һәм дәүләт хакимияте, җирле үзидарә институтлары хокукларын бозган өчен административ җаваплылык билгеләнә.

2012 елның июленнән алып 2014 елның декабренә кадәр Кодекс хокук бозуларның берничә составы белән тулыландырылды, аларны кылган өчен административ җаваплылык карала. Күрсәтелгән үзгәрешләр белән мәдәни-тамаша чараларында булганда иҗтимагый тәртипне бозган, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасының законлы таләпләрен үтәмәгән, җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнгән, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә каршылык күрсәткән, бозның калынлыгы 7 сантиметрдан кимрәк булганда, су объ-

ектлары бозына җәяүләп һәм (яисә) транспортта кергән, тартмый торган тәмәке әйберләре белән Татарстан Республикасы территориясендә күпләп һәм ваклап сәүдә итүне тыюны бозган өчен җаваплылык карала.

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 27.13 статьясы белән, аның яңа редакциясе 2012 елның 1 июленнән гамәлгә керде, транспорт чараларын махсуслаштырылган урыннарга күчерү, аларны саклау, аларны күчергән һәм саклаган өчен түләү, транспорт чараларын хуҗаларына кире кайтару тәртибен билгеләү Россия Федерациясе субъектларына йөкләнде. Күрсәтелгән норманы үтәү йөзеннән «Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны түләү тәртибе турында» 2012 елның 17 маендагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде. Әлеге Законда тоткарланган транспорт чарасын аны тоткарлау турындагы карарны үтәүче затка тапшыру Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә тиешле административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан төзелә торган транспорт чарасын тоткарлау турындагы беркетмә итеп рәсмиләштерелүе каралган.

Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга күчергәндә транспорт чарасын тоткарлау турындагы карарны үтәүче зат һәм махсуслаштырылган урынның вазыйфаи заты тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга тапшыру-алу актын төзи. Тоткарланган транспорт чарасын саклау срогы аны махсуслаштырылган урынга кую вакытыннан алып йөртүчегә тапшыру вакытына кадәрге сәгатьләрдә исәпләнә. Татарстан Республикасында тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урыннарга күчергән һәм саклаган өчен түләү күләмнәрен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бәяләрне дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендәге вәкаләтле органы раслый.

### Суд системасы, иминлек һәм җәмәгатьчелек тәртибен саклау турындагы законнар

«Татарстан Республикасында Конституция суды турында» 1992 елның 22 декабрендәге 1708-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судын оештыру тәртибен һәм аның компетенциясен, аның судьяларының хокукый хәле үзенчәлекләрен,





рәвештә 2014 елның 20 ноябрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән конкурс нигезендә региональ оператор җитәкчесен билгеләп кую тәртибен кертү йөкләнде.

52-ТРЗ номерлы Закон региональ оператор эшчәнлеге мәсьәләләрен, аның эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын тәэмин итүгә карата таләпләрне, шулай ук аның эшчәнлеген тикшереп торуны җайга сала. 2014 елның 14 маендагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән капиталь ремонт фондларын исәпкә алу системасын алып бару буенча региональ оператор функцияләрен дәүләт бюджет яисә казна учреждениесе рәвешендә төзелгән бүтән юридик затның гамәлгә ашыра алуы каралды.

52-ТРЗ номерлы Законда капиталь ремонтка кертемнең минималь күләменнән чыгып булдырылган капиталь ремонт фонды акчалары исәбеннән финансланып күрсәтелә һәм (яисә) башкарыла торган күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеге билгеләнде һәм күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгын билгеләү критерийлары күрсәтелде.

Торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш кооперативларына яисә башка махсуслаштырылган куллануучылар кооперативларына, идарә итүче оешмаларга, региональ операторга күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга дәүләт ярдәмен республика бюджеты акчалары исәбеннән күрсәтү күз алдында тотыла.

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә һәм аның нормаларын гамәлгә ашыру максатларында гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү өчен гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керем күләмен һәм гаилә әгъзалары милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең хакын билгеләү тәртибен; гражданнарны аз керемле дип тану тәртибен; торак урынына мохтаҗ гражданнарның исәбен алып бару тәртибен; гражданнар торак урыннарына бәйле гамәлләр һәм граждан-хокукый алыш-бирешләр башкарган очракта, әгәр мондый гамәлләр башкару биләнә торган торак урыннарының күләмен киметүгә яисә аларны читләштерүгә китерсә, бирелә торган торак урынының гомуми мәйданын исәпләү тәртибен билгели.

Төбәк стандартларын барлыкка китерүнең гомуми принципларын халык ирешкән тормыш дәрәҗәсен төшермәү, торак-коммуналь хуҗалыкка Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын оптимальләштерү, төбәк стандартларын барлыкка китерү процедураларының ачыклыгы һәм үтә күренмәлелеге тәшкил итә.

Төбәк стандартларының күләмнәре Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары күләмнәрен исәпләп чыгару методикасы буенча исәпләп чыгарыла һәм ел саен, чираттагы финанс елына республика бюджеты кабул ителгәнче, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тарифларны дәүләт җайга салуы өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан раслана.

138-ТРЗ номерлы Законны федераль законнарга туры китерү максатларында 2013 елның 13 апрелендәге 30-ТРЗ номерлы һәм 2013 елның 20 маендагы 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары белән үзгәрешләр кертелде, аларда торак урыннар милекчеләре өчен торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр хакының төбәк стандарты күләме, шулай ук төбәк стандартларының күләмен исәпләп чыгару тәртибе төгәлләштерелә.

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 52-ТРЗ номерлы Закон) Россия Федерациясе Торак кодексына күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру өлешендә кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә кабул ителде.

52-ТРЗ номерлы Закон Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтны үз вакытында ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән һәм республикада күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыруның аерым мәсьәләләрен җайга сала.

52-ТРЗ номерлы Законда күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре билгеләнә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә, аерым алганда, капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү, Татарстан Республикасы тарафыннан бирелә торган дәүләт ярдәме акчалары исәбеннән финансланырга мөмкин күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр исемлеген билгеләү керә, шулай ук аңа өстәмә





конституциячел суд эшләре принципларын, шулай ук Татарстан Республикасы Конституция судында аерым категориядәге эшләр буенча суд эшләрен башкару үзенчәлекләрен билгели.

Татарстан Республикасы Конституция суды – Татарстан Республикасының конституциячел корылышын яклау, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, Татарстан Республикасы Конституциясенең Татарстан Республикасының хокук системасында өстен булуын һәм аның бөтен Татарстан Республикасы территориясендә турыдан-туры гамәлдә булуын саклау максатларында конституциячел суд эшләре рәвешендә суд хакимиятен гамәлгә ашыручы конституциячел контроль суд органы.

Суд системасын реформалау юлларын билгели һәм Россия Федерациясендә җәмәгать судьялары институтын булдыруны күздә тота торган суд реформасы концепциясен гамәлгә ашыру кысаларында «Россия Федерациясендә суд системасы турында» 1996 елның 31 декабрендәге 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон һәм «Россия Федерациясендә җәмәгать судьялары турында» 1998 елның 17 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә суд системасына федераль судлар һәм Россия Федерациясе субъектларының конституциячел (устав) судлары белән беррәттән җәмәгать судьялары да Россия Федерациясе субъектлары судларына кертелде.

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законы федераль законнар белән Россия Федерациясе субъектларына бирелгән вәкаләтләр нигезендә җәмәгать судьяларын сайлау һәм аларның эшчәнлек тәртибен билгели.

Җәмәгать судьялары вазыйфага Татарстан Республикасы Судьяларының квалификация коллегиясе бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан сайлап куела.

Юстиция үсешенең хәзерге этабында җәмәгать судьялары билгеләнә торган чорны үзгәртү зарурлыгы барлыкка килде. Россия Федерациясендә судьяларның алыштыргысызлыгы һәм судьялар статусының берлеге принципларын гамәлгә ашыру, квалификацияле кадрларны дөнья юстициясенә җәлеп итүне арттыру һәм гражданнарның хокукларын яклауга һәм законлы мәнфәгатьләрен тулысынча тәэмин итүгә шартлар тудыру өчен «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2014 елның 24 июлендә 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде. Әлеге Закон нигезендә, Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы кабат сайланган оч-

ракта, аның эшләү чоры биш елдан ун елга кадәр арттырылды. Күрсәтелгән Закон Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тәкъдиме белән кабул ителде.

2012 елның 1 июленнән хәзерге вакытка кадәр «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законына җәмәгать судьяларына эшнең тигез бүленешен тәэмин итү һәм җәмәгать судьясы вазыйфасын оставкадагы судьяга йөкләү мәсьәләләрен җайга сала торган; җәмәгать судьясы вазыйфасына сайлану тәртибен төгәлләштерүче, суд участокларының тиешле районнар, шәһәрләр, шәһәр районнары территориясе кергән суд районнары чикләрендә төзелергә тиешлеге хакында үзгәрешләр кертелде. Алар «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законын «Россия Федерациясендә җәмәгать судьялары турында» 1998 елның 17 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан эшләнде.

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 18 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә «Татарстан Республикасында суд участокларын төзү һәм җәмәгать судьялары вазыйфаларын булдыру турында» 2000 елның 31 маендагы 177 номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына Татарстан Республикасында җәмәгать судьяларының санын (188) ачыклаучы һәм суд участокларының тиешле районнар, шәһәрләр, шәһәр районнары территориясе кергән суд районнары чикләрендә төзелергә тиешлеген билгеләүче үзгәрешләр кертелде.

Татарстан Республикасында җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләрен төгәлләштерә торган түбәндәге Татарстан Республикасы законнары кабул ителде:

«Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 17 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасы Казан шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 17 апрелендәге 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

«Татарстан Республикасы Әгерже суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш





72-ТРЗ номерлы Законда гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән башкарма органнары вәкаләтләре билгеләнде.

72-ТРЗ номерлы Закон муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру тәртибен һәм республика дәүләт торак күзәтчелеге органының муниципаль торак контроле органнары белән хезмәттәшлек итү тәртибен билгеләде.

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өчен шартлар тудыру максатларында 72-ТРЗ номерлы Закон җирле үзидарә органнары тарафыннан идарәче оешмалар эшчәнлеге өчен тигез шартлар тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруны, идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә йә торак кооперативларына яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау өчен бюджет акчалары бирүне, күпфатирлы йортлар белән идарә итүче затларның квалификация дәрәҗәсен күтәрүгә һәм мондый эшчәнлекне башкару нияте булган затларны укытуны оештыруга ярдәм итүне, барлык урыннары да муниципаль берәмлек милкендә булган күпфатирлы йорт белән идарә итү тәртибен билгеләүне, күпфатирлы йортлар белән идарә итүдә катнашуны һәм үз компетенциясе чикләрендә башка чараларны гамәлгә ашыруны күз алдында тоталар.

72-ТРЗ номерлы Законда гражданнарның торак хокукларыннан файдалана алуларын тәэмин итү буенча идарәче оешмаларга карата куелган таләпләр, аларга республика бюджетыннан бюджет ассигнованиеләре бирү үзенчәлекләре билгеләнә, шулай ук идарәче оешмаларның күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә үз-үзен җайга салучы оешмалар төзи алуы карала.

«Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» 2005 елның 30 декабрендәге 138-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 138-ТРЗ номерлы Закон) торак урыны өчен һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә субсидияләрне исәпләп чыгару өчен кулланыла торган норматив торак урыны мәйданының төбәк стандартлары, торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр хакы һәм гаиләнең тулаем керемендә торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә гражданнар чыгымнарының рөхсәт ителә торган максималь өлеше күләмнәрен билгеләү буенча Россия Федерациясе субъектларына Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында кабул ителде.

үзләштерү өчен арендага тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом классы торакка кертү шартларына туры килә торган күпфатирлы йортларда һәм (яисә) блоклы төзелә торган торак йортларда торак урыннар, индивидуаль торак йортлар сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен төзү кагыйдәләрен билгели.

95-ТРЗ номерлы Закон Фондның җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелә торган эконом классы торак сатып алу хокукына ия гражданнарның исемлекләрен булдыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрен билгели, күрсәтелгән гражданнар тарафыннан гаризалар тапшыру һәм аларны исәпкә алу тәртибен регламентлаштыра. Исемлекләргә кертү турында гаризалар бирү хокукына республика территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән яисә төп эш (хезмәт) урыны булган, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән исемлеккә кертелгән гражданнар категорияләренә караган Россия Федерациясе гражданнары ия була. Гариза граждан тарафыннан шәхсән яисә вәкиле аша турыдан-туры йә дәүләт хезмәт күрсәтүләренең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәге аша электрон рәвештә яисә кәгазьдә яшәү урыны яисә төп эш (хезмәт) урыны буенча җирле үзидарәнең вәкаләтле органына бирелә.

95-ТРЗ номерлы Законга Федераль законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә 2014 елның 3 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән республиканың башкарма хакимияте органына арендалау шартнамәсе төзү хокукына аукционнар уздыру турында гозырнамә әзерләү һәм аны Фондка юллау вәкаләтләрен бирү өлешендә үзгәрешләр, шулай ук законнарда билгеләнгән тәртиптә уздырылган аукцион нәтиҗәләре буенча төзелергә мөмкин булган йортларның исемлеген үзгәртү өлешендә тиешле үзгәрешләр кертелде.

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 72-ТРЗ номерлы Закон) күпфатирлы йортлар белән идарә итү, күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең уртак мөлкәтен тоту, коммуналь хезмәтләр күрсәтү, торак урын һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү өлкәсендә гражданнарның торак хокукларын яклауны, шул исәптән республика дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру юлы белән һәм торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә тикшереп торуның яңа төре – 2012 елның 23 ноябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән беркетелгән муниципаль торак контролен ясап тәэмин итүгә юнәлдерелгән.





кертү хакында» 2013 елның 17 июлендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Әгерҗе, Мамадыш, Актаныш, Биектау һәм Зеленодольск суд районнары буенча суд участоклары чикләре тасвирламасы төгәлләштерелә торган «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 13 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

«Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2010 елның 3 июлендәге 50-ТРЗ номерлы һәм «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2010 елның 24 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2008 елның 22 декабрендәге 262-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кабул ителделәр һәм алар Татарстан Республикасы Конституция суды һәм Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турында мәгълүматтан аның Федераль закон белән җайга салынмаган өлешеннән файдалануны тәэмин итү үзенчәлекләрен билгелиләр. Әлеге вәкаләт Федераль закон нигезләмәсендә билгеләнгән, аның нигезендә, әгәр Россия Федерациясе субъектларының конституциячел (устав) судлары һәм җәмәгать судьялары вәкаләтләрен һәм эшчәнлек тәртибе билгеләнә торган Россия Федерациясе субъектлары законнарында судлар эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануга Федераль законда билгеләнгәннән тыш башка таләпләр каралган булса, Федераль закон нигезләмәләре Россия Федерациясе субъектлары таләпләрен исәпкә алып кулланыла.

Татарстан Республикасының әлеге законнары белән Татарстан Республикасы Конституция судының һәм Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының эшчәнлеге турындагы мәгълүматны бирү рәвеше һәм теле мәсьәләләре буенча кайбер үзенчәлекләр билгеләнде. Мәсәлән, тиешле мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә тапшырыла дигән таләп куела. Мәгълүматны тиешле рәвештә бирү мөмкинлеге булмаганда, ул булган рәвешендә бирелә. Мондый чакта мәгълүматтан файдаланучыга мәгълүматны тиешле рәвештә бирү мөмкинлеге булмау турында, файдаланучы тарафыннан күрсәтелгән рәвештә мәгълүмат бирелмәүнең сәбәбен күрсәтеп, хәбәр ителергә тиеш.

Татарстан Республикасы законнарында Татарстан Республикасы Конституция суды һәм Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны оештыру тәртибе, шулай ук мәгълүматның күрсәтелгән төрләрен

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибе җайга салынды. Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану аның вәкаләтле структур бүлекчәсе яисә вазыйфаи заты тарафыннан тәэмин ителә. Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү өчен җаваплы затлар Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе тарафыннан билгеләнеп куела. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану аның аппаратының Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы билгеләп куя торган җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан тәэмин ителә.

«Россия Федерациясендә судьялар бергәлеге органнары турында» 2002 елның 14 мартындагы 30-ФЗ номерлы Федераль закон белән бирелгән вәкаләтләргә нигезләнеп, «Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» 2002 елның 15 октябрендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясе составына җәмәгатьчелек вәкилләрен билгеләп куюның тәртибе җайга салынды. Җәмәгатьчелек вәкилләре Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме буенча Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнеп куела. Җәмәгатьчелек вәкилләре вазыйфаларына кандидатларны Дәүләт Советына тәкъдим итү өчен аларны алдан сайлап алу Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

«Россия Федерациясендә адвокат эшчәнлеге һәм адвокатура турында» 2002 елның 31 маендагы 63-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасының квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» 2003 елның 11 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасының квалификация комиссиясе составына Дәүләт Советы вәкилләрен сайлау тәртибе һәм аларга куела торган таләпләр билгеләнде.

Квалификация комиссиясе әгъзалары Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасының квалификация комиссиясе вәкаләтләре гамәлдә булган чорга Дәүләт Советының профильле комитеты тәкъдиме буенча Дәүләт Советы тарафыннан сайлана. Квалификация комиссиясе әгъзалары вазыйфаларына кандидатларны Дәүләт Советына тәкъдим итү өчен аларны алдан сайлап алу Дәүләт Советы тарафыннан раслана торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.





8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 8-ТРЗ номерлы Закон) кабул ителде.

8-ТРЗ номерлы Закон ятим балаларга махсуслаштырылган торак фондыннан махсуслаштырылган торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибен билгели. Махсуслаштырылган торак фонды торак урыннары белән социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар яисә наемга алучының гаилә әгъзалары булмаган йә торак урыннары милекчеләре булып тормаган ятим балалар, шулай ук социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар яисә наемга алучының гаилә әгъзалары булмаган йә торак урыннары милекчеләре булып тормаган ятим балалар моңа кадәр биләп тора торган торак урыннарында алар өчен яшәү мөмкинлеге булмавы 8-ТРЗ номерлы Законда билгеләнгән тәртиптә танылган очракта.

8-ТРЗ номерлы Законда махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыны алу хокукына ия ятим балалар исемлеген төзү тәртибе, шулай ук социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар яисә социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннарын наемга алучының гаилә әгъзалары булган йә торак урыннары милекчеләре булган ятим балаларның моңа кадәр биләп тора торган торак урыннарында яшәү мөмкинлегенең булмавы таныла торган шартлар билгеләнде.

8-ТРЗ номерлы Закон нормаларына 2013 елның 28 октябрендәге 84-ТРЗ номерлы һәм 2014 елның 18 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары белән төзәтмәләр кертелде, ятим балаларга торак урыннарын фактта бирү һәм алар белән наем шартнамәләрен төзү гамәлләрен башкаруны махсуслаштырылган оешмага (коммерциягә карамаган республика оешмасына) тапшыру мөмкинчелеге өлешендә ятим балаларга торак урыннарын бирү тәртибе, шулай ук ятим баланың моңа кадәр биләп тора торган торак урынында яши алмавын тану тәртибе төгәлләштерелде.

«Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законның $16^6$ һәм $16^{6-1}$ статьяларын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2012 елның 28 декабрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 95-ТРЗ номерлы Закон) Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү федераль фондының (алга таба – Фонд) эконом класслы торак төзү өчен түләүсез вакытлы файдалануга яисә арендага, шулай ук эконом класслы торакны минималь таләп ителә торган күләмдә төзү өчен, шул исәптән эконом класслы торакны һәм башка торак төзелешен минималь таләп ителә торган күләмдә төзү максатларында комплекслы

Әлеге Закон нормаларын үстереп, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды, фонд уставында каралган эшчәнлек предметына, максатларына һәм вәкаләтләренә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Президенты Указы белән «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруны башкаручы махсуслашкан оешма буларак билгеләнде.

2013 елның 5 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән 69-ТРЗ номерлы Закон нормаларына дәүләт һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен республика территориясендә торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен түләүсез бирү нигезләре исемлеген киңәйтү өлешендә төзәтмәләр кертелде. Үзгәрешләрдә каралганча, мондый җир кишәрлекләре социаль ипотека системасында эшчәнлекне гамәлгә ашыру һәм аерым категорияләрдәге гражданнарга карата торак шартларын яхшырту буенча дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыру өчен махсуслаштырылган оешма (республика коммерциягә карамаган оешма) милкенә тапшырылырга мөмкин.

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 29 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) кабул ителүгә бәйле рәвештә 2013 елның 1 гыйнварыннан ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү тәртибе шактый үзгәртелде.

Федераль законда ятим балаларны һәм алар арасыннан булган затларны торак белән тәэмин итү вәкаләте Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә кертеп каралган. Шул ук вакытта ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны (алга таба – ятим балалар) торак белән тәэмин итү Россия Федерациясе субъектының дәүләт торак фондыннан башкарылыр дип күз алдында тотыла. Бу хакта махсуслаштырылган торак фонды турында язылган Федераль законда ассызыкланган.

Күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектын законнар белән җайга салуны таләп итте, моңа бәйле рәвештә 2013 елның 12 гыйнварында «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында»





Россия Федерациясе Конституциясенең 129 статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары прокурорлары Россия Федерациясе Генераль прокуроры тарафыннан субъектлар белән килештерелеп билгеләнеп куелалар. «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» 1992 елның 17 гыйнварындагы 2202-1 номерлы Федераль законның 13 статьясында мондый килештерүнең Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең шул субъектлар билгели торган органнар тарафыннан гамәлгә ашырылуы төгәлләштерелә. Шушы нормаларны киңәйтү максатында «Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен кандидатура килештерү тәртибе турында» 2010 елның 21 декабрендә 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде, анда Россия Федерациясе Генераль прокуроры Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен үзе тәкъдим итә торган кандидатураны килештерә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы була дип билгеләнде. Республика законы белән шулай ук Татарстан Республикасы Прокуроры вазыйфасына билгеләп кую өчен кандидатураны килештерү процедурасына кагылышлы мәсьәләләр дә җайга салына.

«Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2014 елның 2 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында җәмәгатьчелек тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуын оештыруга бәйле мәсьәләләрне җайга сала, халык дружиначысы таныклыгы үрнәген һәм аны бирү тәртибен, халык дружиначысының махсус символикасы үрнәген, халык дружиналарының координацияләү органнарын (штабларын) төзү һәм аларның эшчәнлеге тәртибен билгели.

Моңа кадәр гамәлдә булган «Татарстан Республикасында җәмәгатьчелек тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында» 2005 елның 1 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көчен югалткан дип танылды.

«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» 2005 елның 29 декабрендәге 134-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы түбәндәгеләрне җайга сала:

Татарстан Республикасының һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен төзүнең һәм алар эшчәнлегенең гомуми оештыру-хокукый һәм икътиса-

дый нигезләрен, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук, оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, крестьян (фермер) хуҗалыклары, башка юридик затлар, иҗтимагый берләшмәләр, вазыйфаи затлар һәм гражданнар арасында Татарстан Республикасы территориясендә бу өлкәдәге үзара хезмәттәшлек тәртибен;

Татарстан Республикасы коткаручыларын, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерүдә катнашучы башка гражданнарны һәм аларның гаиләләре әгъзаларын хокукый һәм социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәте нигезләрен.

Законда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасының һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру өлкәсендәге оешмаларның вәкаләтләре билгеләнә; «Һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм коткаручылар статусы турында» 1995 елның 22 августындагы 151-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасында һәлакәттән коткару хезмәтләрен һәм һәлакәттән коткару формированиеләрен төзү, теркәү һәм аларның эшчәнлеге мәсьәләләре, аларның эшчәнлеген финанс һәм матди яктан тәэмин итү, Татарстан Республикасы коткаручылары статусын билгеләү һәм аларны аттестацияләү мәсьәләләре җайга салына, Татарстан Республикасы коткаручыларына торак, иминият һәм социаль гарантияләр бирелә.

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасында янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү системасы – янгыннарга каршы юнәлдерелгән көчләр һәм чаралар, шулай ук хокукый, оештыру, икътисадый, социаль һәм фәнни-техник характердагы гамәлләр бергәлеге ул.

Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү системасының төп нигезен янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә Россия Федерациясе законнары нигезендә катнашучы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, гражданнар тәшкил итә.

Татарстан Республикасының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү системасының төп функцияләре:

1) янгын куркынычсызлыгы өлкәсен норматив-хокукый җайга салу һәм бу өлкәдә дәүләт чараларын гамәлгә ашыру;





яне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру гамәлләрен мәгълүмат ягыннан тәэмин итү тәртибе билгеләнгән.

2007 елның 13 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән 2006 – 2020 елларга Татарстан Республикасы ягулык-энергетика комплексын үстерү программасы (алга таба – Программа) расланды.

Программа, Татарстан Республикасы һәм гомумән Россия Федерациясе ягулык-энергетика комплексында һәм шулай ук икътисадында барлыкка килгән эчке һәм тышкы факторларны исәпкә алып, Татарстан Республикасы ягулык-энергетика комплексын үстерүнең озак сроклы программасының максатларын, бурычларын һәм төп юнәлешләрен тәгаенләштерүче документ булып тора.

Татарстан Республикасы җыелма төбәк продуктын үстерүне тәэмин итү һәм халыкның яшәү дәрәҗәсен күтәрү өчен табигый ягулык-энергетика ресурсларыннан һәм энергетика секторы мөмкинлекләреннән мөмкин кадәр нәтиҗәле файдалану Программаны гамәлгә ашыруның максаты буларак билгеләнгән.

**Торак законнары**

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 69-ТРЗ номерлы Закон) керем дәрәҗәләре төрле булган гражданнарны сатып алырлык торак белән тәэмин итүнең нәтиҗәле системасын булдыруга, дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларының Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерү буенча эшчәнлекләрен берләштерүгә, шулай ук милек хокукы йә наем нигезендә даими яисә вакытлыча яшәү өчен сатып алырлык торак базарын булдыруга юнәлдерелде.

69-ТРЗ номерлы Закон Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне, шул исәптән гражданнарның индивидуаль һәм күпфатирлы торакны һәм инженер инфраструктурасы объектларын дәүләт акчалары, бюджеттан тыш, шулай ук җәлеп ителгән акчалар исәбеннән төрле торак программаларын гамәлгә ашыру юлы белән сатып алуына, төзүенә яисә реконструкцияләвенә бәйле рәвештә килеп чыгучы мөнәсәбәтләрне җайга сала. Законның гамәли көче Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыруда катнашу турында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән шартнамәләр төзегән җирле үзидарә органнарына кагыла.

публикасының озак сроклы максатчан программаларын финанс-икътисадый экспертизалау;

9) Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары үтәлеше турында, үткәрелгән тикшереп тору һәм эксперт-аналитика гамәлләренең нәтиҗәләре турында мәгълүмат әзерләү һәм мондый мәгълүматны Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшыру;

10) коррупциягә каршы юнәлдерелгән гамәлләрдә вәкаләтләре чикләрендә катнашу һәм башкалар.

37-ТРЗ номерлы Законда Хисап палатасы Рәисе, Рәисе урынбасарлары һәм аудиторлары вазыйфаларына кандидатураларга таләпләр, аерым алганда, югары белем һәм кимендә биш ел эш тәҗрибәсе булу, аларны вазыйфага билгеләү һәм азат итү тәртибе, вазыйфаи затларның хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы, шулай ук әлеге дәүләт вазыйфаларын биләүгә бәйле чикләүләр билгеләнгән.

Моннан тыш, 6-ФЗ номерлы Федераль законда муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруны һәм аларның эшчәнлекләрен хокукый җайга салуның аерым мәсьәләләре Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләренә кертелгән. Әлеге нигезләмәләрне гамәлгә ашыру йөзеннән «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында» 2012 елның 17 маенда 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде.

### Энергетика өлкәсендәге законнар

Татарстан Республикасында энергияне сак тоту өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында 2012 елның 14 июлендәге 49-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 49-ТРЗ номерлы Закон) кабул ителде.

Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

49-ТРЗ номерлы Законда энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкаләтләре, Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә дәүләт ярдәменең төп юнәлешләре һәм рәвешләре, шулай ук энерги-





2) янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге хокукларны, бурычларны һәм җаваплылыкны гамәлгә ашыру;

3) янгыннан саклау хезмәтен булдыру һәм аның эшчәнлеген оештыру;

4) янгынга каршы пропаганда үткәрү һәм халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларын күрүгә өйрәтү;

5) ирекле янгын сүндерүчеләр эшчәнлегенә ярдәм итү, халыкны янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә җәлеп итү;

6) янгын куркынычсызлыгын фәнни-техник тәэмин итү;

7) янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә мәгълүмати тәэмин итү;

8) янгын техникасы продукциясен җитештерү;

9) янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтү;

10) янгыннар сүндерү, һәлакәттән коткару эшләрен башкару;

11) янгыннарны һәм алардан килгән зыяннарны исәпкә алу;

12) янгыннарга каршы махсус режим билгеләү.

«Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 1 августындагы 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы «Янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 6 маендагы 100-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә һәм янгыннан ирекле саклау хезмәтенең мөлкәтен булдыру өлкәсендәге; янгыннан ирекле саклау хезмәтенең эшчәнлеген җайга салу өлкәсендәге; ирекле янгын сүндерүчеләргә һәм янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләренә, шулай ук янгыннан ирекле саклауның иҗтимагый берләшмәләренә дәүләт ярдәме чараларын билгеләү өлкәсендәге мәсьәләләрне җайга салу зарурлыгына бәйле рәвештә кабул ителде.

«Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау турында» 2008 елның 13 октябрендәге 105-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы законлылыкны, хокук тәртибен һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итү максатларында һәм Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау эшчәнлеген гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Хокук бозуларны профилактикалауның төп юнәлешләре түбәндәгеләр:

хокук бозуларга китерүче сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү;

гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен хокукка каршы гамәлләрдән яклауны тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының хокук бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән норматив хокукый актлар кабул итүе;

хокук бозуларны кисәтүгә юнәлдерелгән профилактик чаралар күрү;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын һәм хокук бозуларын кисәтү, шуларны барлыкка китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү;

социаль куркыныч хәлдәге гражданнарны социаль-психологик реабилитацияләү;

хокук бозуларны профилактикалау эшчәнлеген гамәлгә ашыручы органнар һәм учреждениеләр арасында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салу, шулай ук аларның эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү;

гражданнарны хокук бозуларны профилактикалау эшчәнлегендә катнашуга җәлеп итү;

гражданнарны законлылыкны һәм хокук тәртибен үтәү рухында тәрбияләү.

«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» 2009 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре эшчәнлегенә бәйле барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала. Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре институты балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын һәм хокук бозуларын кисәтү һәм гаиләне, балаларны яклау буенча конституциячел нормаларны гамәлгә ашыру өлкәсендә социаль сәясәтне камилләштерү максатларында төзелә.

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү, аларның эшчәнлек тәртибен һәм вәкаләтләрен билгели, бу комиссияләр — балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре эшчәнлеген координацияләү, балигъ булмаганнарның хокукларын яклау буенча законнарда каралган чараларны гамәлгә ашыра торган даими эшләүче коллегиаль органнар.





37-ТРЗ номерлы Законда Хисап палатасының статусы билгеләнә. Ул — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан төзелә, аның алдында хисап тота торган һәм тышкы дәүләт финанс контроленең даими эшләүче орган. Хисап палатасының төп вәкаләтләренә түбәндәгеләр кертелгән:

1) Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары үтәлешен тикшереп тору;

2) Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетларының керемнәр һәм чыгымнар статьяларының күләмнәре, структурасы һәм максатчан билгеләнеше буенча вакытында үтәүне оператив тикшереп торуны оештыру һәм уздыру;

3) Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон проектын, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары турындагы законнар проектларын экспертизалау;

4) Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары үтәлеше турындагы еллык хисапларны тышкы тикшерү һәм аларның үтәлеше турындагы бәяләмәләрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшыру;

5) Татарстан Республикасы бюджеты чараларын, Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт территориаль фондлары бюджетлары чараларын һәм Россия Федерациясе законнары белән каралган бүтән чыганакларны куллануның нәтиҗәлелегенә аудит уздыру, аларны куллануның законлылыгын һәм нәтиҗәлелеген (эффектлылыгын һәм сакчыллыгын) тикшереп торуны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

6) Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге мөлкәткә, шул исәптән акыл эшчәнлегенең сакланылучы нәтиҗәләренә һәм Татарстан Республикасының индивидуальләштерү чараларына, идарәнең һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен үтәүне тикшереп тору;

7) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән салым һәм бүтән ташламаларны һәм өстенлекләрне, бюджет кредитларын бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү;

8) Татарстан Республикасы законнары проектларын һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актларын Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләренә кагылышлы өлешендә (финанс-икътисадый нигезләүләрнең нигезлелеген кертеп), шулай ук Татарстан Рес-

йә аны үзгәртү проекты Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проекты белән бергә тапшырыла һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы рәсми басылып чыккан көннән ике айдан да артмаган чорда расланырга тиеш.

Әлеге Закон кысаларында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бюджетара трансфертлар бирү мәсьәләләре хокукый яктан өстәмә җайга салынды, Татарстан Республикасы законы һәм аның нигезендә кабул ителә торган муниципаль район уставы, авыл җирлекләре уставлары нигезендә муниципаль районнар хәл итә торган җирле мәсьәләләр авыл җирлекләренә беркетелгән булса, муниципаль районнар бюджетларына күчерелергә тиешле федераль салымнардан һәм җыемнардан авыл җирлекләре бюджетларына керемнәр түләү нормативларын билгеләү буенча Татарстан Республикасына өстәмә вәкаләт бирелде.

Законлылык, объективлык, системалылык, бәйсезлек һәм хәбәрдарлык принципларына нигезләнеп, Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасы бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларының үтәлешен тикшереп тору өчен Татарстан Республикасында Хисап палатасы булдырылды, аның статусы, составы һәм вәкаләтләре «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (алга таба — 37-ТРЗ номерлы Закон) билгеләнгән.

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлекләренең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон белән (алга таба — 6-ФЗ номерлы Федераль закон) тышкы дәүләт һәм муниципаль финанс контроле өлкәсендә федераль җайга салу урнаштырылган иде.

Моңа бәйле рәвештә, федераль җайга салуның яңа таләпләренә тулы күләмдә җавап бирми торган 37-ТРЗ номерлы Закон, 2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән тулысынча яңа редакциядә бәян ителде. 37-ТРЗ номерлы Законның яңа редакциясе бәйсез тышкы финанс контроле институтын үстерүгә, Хисап палатасы статусын күтәрүгә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын куллануны тикшереп тору нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән.





Күрсәтелгән вәкаләт «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3 статьясы һәм «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Законында комиссияләрнең төп бурычлары итеп түбәндәгеләр билгеләнгән:

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарының һәм учреждениеләренең эшчәнлеген координацияләү;

балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау һәм торгызу, аларны дискриминацияләүнең барлык рәвешләреннән, физик яисә психик җәберләүдән, мәсхәрәләүдән, тупас мөнәсәбәттән, сексуаль һәм бүтән төрле эксплуатацияләүдән яклау чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнарны социаль-педагогик реабилитацияләү чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын, хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләрен кисәтү, шуңа китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау, анализлау һәм бетерү;

балигъ булмаганнарны җинаятьләр кылуга һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр башкаруга җәлеп итү очракларын ачыклау һәм булдырмый калу чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалауга, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга бәйле эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләренә кагылышлы төп мәсьәләләрне хәл итүгә карата килешенгән алымнар эшләү;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын, хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләрен профилактикалау, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча дәүләт теркәве узган иҗтимагый берләшмәләр, дини оешмалар, шулай ук бүтән оешмалар һәм гражданнар белән үзара хезмәттәшлек;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарының һәм учреждениеләренең уңай эш тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату, аларга оештыру-методик ярдәм күрсәтү.

Балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе һәм җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен биргәндә муниципаль районнарда, шәһәр округларында төзелә торган балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре системасын төзи.

2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре бирелде.

Наркоманиянең һәм токсикоманиянең барлыкка килүен һәм таралуын кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар системасын булдыру, психоактив матдәләрне чамадан тыш кулланган затлар санын һәм психоактив матдәләрне чамадан тыш куллану аркасында җәмгыятьтәге югалтуларны киметү максатларында «Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» 2009 елның 29 октябрендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба — Закон) кабул ителде. Закон дәүләт хакимияте органнарының, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм оешмаларның наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау өлкәсендәге эшчәнлеген координацияләү нигезләрен билгеләү; наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау чараларын финанслау тәртибен билгеләү; психоактив матдәләрне чамадан тыш куллануны профилактикалауның, психоактив матдәләрне кулланучыларны дәвалауның, психоактив матдәләрне чамадан тыш куллanudан дәваланган затларны медик-социаль һәм социаль реабилитацияләүнең төп юнәлешләрен билгеләү кебек бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән.

Закон наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау чараларын гамәлгә ашыручы дәүләт органнарының вәкаләтләрен билгели; дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, массакүләм мәгълүмат чараларының, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм оешмаларның наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау өлкәсендәге эшчәнлеген координацияләү мәсьәләләрен җайга сала; психоактив матдәләрне медицина билгеләнешеннән тыш кулланучы затларны ачыклау һәм исәпкә алу, шулай ук аларны дәвалау, медик-социаль һәм социаль реабилитацияләү мәсьәләләрен җайга сала; наркотикларга





2014 елның 10 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Бюджет кодексына Татарстан Республикасы дәүләт милке объектларына капитал салулар рәвешендә бюджет инвестицияләрен бирү механизмын камилләштерүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелде. Күрсәтелгән максатлар өчен дәүләт бюджет учреждениеләренә һәм автоном учреждениеләргә һәм дәүләт унитар предприятиеләренә субсидияләр бирү юлы белән капитал салуларны гамәлгә ашыру тәртибе билгеләнде. Күрсәтелгән законда Татарстан Республикасы дәүләт заказчыларының Татарстан Республикасы бюджетыннан инвестицияләрне гамәлгә ашырганда дәүләт контрактлары төзү һәм үтәү буенча үз вәкаләтләрен дәүләт бюджет учреждениеләренә һәм автоном учреждениеләргә һәм дәүләт унитар предприятиеләренә тапшыру хокукы каралган һәм бу вәкаләтләрне тапшыру тәртибе төгәлләштерелгән.

2014 елның 18 декабрендәге 124-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Бюджет кодексына 2016 елга, 2017 һәм 2018 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетыннан башлап Татарстан Республикасы бюджетын программалар нигезендә төзү принцибын урнаштыручы үзгәрешләр кертелде. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларын һәм дәүләт программаларына кертелә торган үзгәрешләрне карау хокукы бирелгән. 2016 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәре чыганаклары реестрын мәҗбүри алып бару билгеләнгән. Әлеге вазыйфа Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләнгән.

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына бюджетны озак вакытка планлаштыру турында нигезләмәләр кертелде, ул озак вакытка Татарстан Республикасы бюджеты фаразларын булдыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Озак сроклы чорга Татарстан Республикасы бюджеты фаразы дигәндә Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының төп характеристикалары фаразын, гамәлдә булган чорларында Татарстан Республикасы дәүләт программаларын финанс белән тәэмин итү күрсәткечләрен, Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын тасвирлый торган башка күрсәткечләр, шулай ук озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет сәясәтен булдыруның төп алымнарын үз эченә алган документ аңлашыла. Озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразы унике елга һәм аннан озагракка һәр алты ел саен тиешле чорга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразы нигезендә әзерләнә. Татарстан Республикасы бюджетын фаразлау проекты

Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрү каралган. Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләрен булдыру һәм куллану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 14 февралендәге 118 номерлы карары белән билгеләнде.

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына 2013 елның 22 июлендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә Татарстан Республикасы Инвестиция фонды булдыру каралган, ул Татарстан Республикасы бюджетының Татарстан Республикасы территориясендә дәүләти-хосусый партнерлык принципларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектларын башкару максатларында файдаланырга тиешле акчалары өлешен тәшкил итә. Татарстан Республикасы Инвестиция фондының бюджет ассигнованиеләре күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана. Татарстан Республикасы Инвестиция фондының бюджет ассигнованиеләре агымдагы финанс елында һәм план чорында Татарстан Республикасы Инвестиция фондының финанс хисабы елында файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасына, шулай ук Татарстан Республикасы Инвестиция фонды акчаларының финанс хисабы елында файдаланылмаган акчалары исәбеннән башка бюджетларга бирелгән субсидияләрне кире кайтарудан алынган керемнәр күләменә арттырылырга тиеш. Татарстан Республикасы Инвестиция фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм алардан файдалану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

2013 елның 23 июлендәге 252-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Бюджет кодексына дәүләт һәм муниципаль финанс контроле системасын үстерүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелде: тышкы һәм эчке дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары арасында вәкаләтләрне бүлешү; дәүләт хакимияте органнарының (җирле үзидарә органнарының) финанс контролен башкару буенча бюджет вәкаләтләре төгәлләштерелде; законнар белән дәүләт (муниципаль) финанс контроле ысуллары һәм объектлары билгеләнде; бюджет законнарын бозуның һәр очрагы өчен җаваплылык чаралары урнаштырылды. Шуңа бәйле рәвештә 2013 елның 16 октябрендәге 79-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезләмәләренә үзгәрешләр кертелде, алар Татарстан Республикасында дәүләт (муниципаль) финанс контролен гамәлгә ашыруга кагыла.





каршы укыту, тәрбияләү һәм пропагандалау өлкәсендә аерым таләпләрне билгели.

«Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 2010 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, хокук тәртибен һәм иҗтимагый иминлекне хокукый саклау чарасы буларак, төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны тәэмин итү мәсьәләләрен җайга сала, күпфатирлы һәм индивидуаль торак йортларда, хастаханәләрдә, диспансерларда һәм башка медицина учреждениеләрендә, шифаханәләрдә, ял йортларында, пансионатларда, тәүлек буе балалар тора торган мәгариф учреждениеләрендә, балалар, өлкән гражданнар һәм инвалидлар өчен интернат йортларда, кунакханә номерларында һәм тулай торак бүлмәләрендә, йорт яны территорияләрендә, кемпинглар, мотельләр, ял итү базалары территорияләрендә, бакчачылык, яшелчәчелек һәм коммерциягә карамаган дача берләшмәләре территорияләрендә эш көннәрендә кичке сәгать 10нан иртәнге сәгать 6га кадәр, ә ял көннәрендә һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә кичке сәгать 10нан иртәнге сәгать 9га кадәр гражданнарның тынычлыгын боза торган кайбер гамәлләрне башкаруга тыюлар билгели. Шундый тыю кагылмый торган билгеле бер гамәлләрне башкару да әлеге Татарстан Республикасы Законы белән тыела.

Әлеге Закон төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны боза торган гамәлләргә түбәндәгеләрне кертә:

1) төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп телевизорларны, радиоалгычларны, магнитофоннарны һәм башка тавыш чыгара торган җайланмаларны, шулай ук тавыш көчәйткеч җайланмаларны, шул исәптән транспорт чараларында, сәүдә, җәмәгать тукылануы объектларында һәм күңел ачу үзәкләрендә урнаштырылганнарны куллану;

2) берничә мәртәбә эшләп киткән саклау сигнализациясенең тавыш сигналларын вакытында сүндермәү, шул исәптән транспорт чараларында урнаштырылганнарын да, йә төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп төзек булмаган саклау сигнализациясен куллану;

3) төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп пиротехник чараларны куллану;

4) төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп музыка коралларында уйнау, кычкырулар, сызгыру, җырлау, шулай ук тавыш чыгара торган бүтән гамәлләр;

5) төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозуга китерә торган итеп ремонт, төзелеш, төяү-бушату эшләрен башкару.

### Коррупциягә каршы көрәш турындагы законнар

«Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 апрелендәге 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен тәэмин итү бурычларын, принципларын, төп чараларын билгели, шулай ук Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен оештыру ягыннан тәэмин итү мәсьәләләрен җайга сала.

Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәт субъектларының үз вәкаләтләре чикләрендә эшчәнлегеннән гыйбарәт, ул коррупциягә каршы торуга һәм аның тискәре йогынтысын киметүгә юнәлдерелгән һәм түбәндәге төп чараларны гамәлгә ашыру юлы белән тәэмин ителә:

коррупциягә каршы республика, ведомство һәм муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру;

коррупциягә каршы экспертиза үткәрү;

коррупциягә каршы мониторинг;

коррупциягә каршы белем бирү һәм пропаганда;

коррупциягә каршы тору буенча иҗтимагый эшчәнлеккә дәүләт ярдәме;

дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең гавамилеген һәм мәгълүмати ачыклыгын тәэмин итү;

дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеген хокукый регламентлаштыру.

Республика Законы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законга кадәр кабул ителгән иде, шуңа бәйле рәвештә, Федераль закон кабул ителгәннән соң, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләренә шактый үзгәрешләр кертү зарурлыгы барлыкка килде. «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 19 гыйнварындагы 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәте бурычларын, төп принципларын, тәэмин итү чараларын һәм Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәт субъектларын билгели торган нормалары коррупциягә каршы экспертиза мәсьәләләрен җайга салу, коррупциягә каршы мониторинг, коррупциягә каршы көрәш буенча иҗтимагый эшчәнлеккә дәүләт ярдәме, Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтенең оештыру нигезләре өлешендә үзгәрешләр кертелде.





Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүгә бәйле чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен җирле бюджетларга субсидияләр бирүгә; гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә.

Татарстан Республикасының Резерв фонды күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә. Татарстан Республикасының Резерв фонды акчаларыннан файдалану турында карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә.

Россия Федерациясендә юл эшчәнлегенең бердәм хокукый нигезләрен тәэмин итү максатларында 2011 елның 6 апрелендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Бюджет кодексына Россия Федерациясендә юллар фондлары төзүнең хокукый нигезләрен урнаштыручы үзгәрешләр кертелде. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 1 августындагы 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасында 2012 елның 1 гыйнварыннан Юллар фонды төзелде, ул Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 552 статьясы нигезендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген, шулай ук торак пунктларның күпфатирлы йортларының ишегалды территорияләрен, күпфатирлы йортларының ишегалды территорияләренә килү юлларын капиталь ремонтлауны һәм ремонтлауны финанс белән тәэмин итү максатларында файдаланылырга тиешле Татарстан Республикасы бюджеты чаралары өлешен тәшкил итә. Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләме Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына, турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизельле һәм карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле акцизлардан; транспорт салымыннан; юл эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан субсидияләрдән; региональ яисә муниципальара әһәмиятле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә физик һәм юридик затларның кире кайтарылмый торган кертемнәреннән, шул исәптән иректе иганәләреннән фаразлана торган күләмдә чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән раслана. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Юллар фондының агымдагы финанс елында кулланылмаган бюджет ассигнованиеләрен чираттагы финанс елында Татарстан

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының V бүлеге бюджетара мөнәсәбәтләргә багышланган. Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр һәм муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр; җирле бюджетларга субсидияләр; федераль бюджетка субсидияләр; Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

Бюджетара трансфертларның күләме һәм аларны муниципаль районнар буенча бүлү ел саен Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы һәм (яисә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән раслана.

Татарстан Республикасы Бюджет кодексы белән Татарстан Республикасы бюджеты процессы да җайга салынды: бюджет процессында республика дәрәҗәсендә бюджет вәкаләтләре бирелгән барлык катнашучылар ачыкланды, аларның вәкаләтләре, шул исәптән искәрмә рәвешендә, һәм җаваплылыгы билгеләнде. Киләсе финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законын эшләү, карау һәм раслау процесслары җентекләп җайга салынды.

Бюджет кодексының «Бюджет хисабын төзү, тышкы тикшерү, карау һәм раслау» турында IX1 бүлегендә бюджет хисабы составына таләпләр, Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан тышкы тикшерү үткәрү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан хисапны тапшыру сроклары, Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына хисапны кертү сроклары билгеләнгән, бюджет үтәлеше турындагы хисап белән бергә тапшырылучы документлар исемлеге расланган, бюджет үтәлеше турында Татарстан Республикасы законына таләпләр билгеләнгән h.б.

2009 елның 4 июлендәге 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында республика бюджетының чыгым өлеше составында Татарстан Республикасының Резерв фондын төзү мөмкинлеге каралган, бу фонд акчалары, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре җитәрлек булмаган очракта, тиешле финанс елына һәм план чорына бюджет турындагы законда каралган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итү өчен файдаланыла. Татарстан Республикасының Резерв фонды акчалары беренче чиратта Татарстан Республикасының түбәндәге чыгым йөкләмәләрен үтәүгә юнәлдерелә: Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүгә; җирле бюджетларга субвенцияләр бирүгә;





## Җирле үзидарә турындагы законнар

Җирле үзидарә өлкәсендә төп закон булып «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы Закон) санала, ул «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә оештыруны хокукый җайга салуны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән. 131-ФЗ номерлы Федераль закондагы үзгәрешләр нигезендә әлеге Законга үзгәрешләр кертү турында 2005 елдан 2014 елга кадәр 22 Татарстан Республикасы законы кабул ителде (соңгысы – 2014 елның 29 ноябрендәге 110-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы).

45-ТРЗ номерлы Закон нигезендә Татарстан Республикасында җирле үзидарә – халыкның Россия Федерациясе Конституциясендә, федераль законнарда, ә федераль законнарда каралган очракларда – Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән чикләрдә тәэмин ителүче үз хакимиятен гамәлгә ашыру, халык мәнфәгатьләреннән чыгып, тарихи һәм башка җирле традицияләрне исәпкә алып, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры халык һәм (яисә) җирле үзидарә органнары аша мөстәкыйль рәвештә, җаваплылыкны үз өстенә алып гамәлгә ашыру рәвеше ул.

Россия Федерациясе гражданнары җирле үзидарәне җирле референдумнарда, муниципаль сайлауларда катнашу юлы белән, ихтыяр белдерүнең башка рәвешләре аша, шулай ук җирле үзидарәнең сайланулы һәм башка органнары аша гамәлгә ашыралар һәм чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, нинди расадан һәм милләттән булуына, җенесенә, белеменә, теленә, сәяси карашларына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, шөгыльләренең төренә һәм характерына, нинди иҗтимагый берләшмәләрдә торуына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гамәлгә ашыруда бертигез хокукларга ия.

45-ТРЗ номерлы Закон нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары җирле үзидарә системасын төзү һәм үстерү өчен кирәкле шартлар тудырырга һәм җирле үзидарәгә хокукларын гамәлгә ашыруда халыкка ярдәм итәргә тиеш.

Татарстан Республикасында җирле үзидарәгә дәүләт ярдәме җирле үзидарә төзү һәм үстерү өчен кирәкле хокукый, оештыру, матди һәм финанс шартлары булдыру белән тәэмин ителә.

Татарстан Республикасының бөтен территориясендә җирле үзидарә 131-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә Татарстан Республикасы законнары белән территорияләренең чикләре билгеләнә торган шәһәр, авыл җирлекләрендә, муниципаль районнарда һәм шәһәр округларында гамәлгә ашырыла. Муниципаль берәмлекләрнең чикләрен үзгәртү Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә ашырыла. Закон нигезендә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органнары исемнәре түбәндәгечә булырга мөмкин: совет, собрание, дума, җыен, җыелыш.

Муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе башкарма комитет дип атала. Муниципаль берәмлек уставы нигезендә тиешле муниципаль берәмлек башлыгы җитәкли торган шәһәр округының һәм шәһәр җирлегенең җирле администрациясе мэрия дип аталырга мөмкин. Җирле администрациягә бер генә башлык принципларында җирле администрация башлыгы җитәкчелек итә.

Җирле администрация башлыгы вазыйфасын муниципаль берәмлек башлыгы йә күрсәтелгән вазыйфаны биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлек уставында карала торган вәкаләтләр чорына төзелүче контракт нигезендә билгеләнеп куела торган зат башкара.

Вазыйфасына контракт буенча билгеләнеп куела торган җирле администрация башлыгы муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесе дип атала.

Муниципаль районның административ үзәге булып торучы муниципаль район һәм җирлек уставларында муниципаль районның җирле администрациясен төзү каралырга мөмкин, аңа күрсәтелгән җирлекнең җирле администрациясе вәкаләтләрен үтәү йөкләнә. Мондый очракта муниципаль районның административ үзәге булып торучы җирлектә җирле администрация төзелми.

45-ТРЗ номерлы Закон Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең түбәндәге гарантияләрен билгели:

– җирле үзидарә хокукларын чикләүне тыю;

– җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының мөрәҗәгатьләрен карау;

– җирле үзидарәнең суд яклавында булуы.

45-ТРЗ номерлы Законның 11 статьясында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре реестрын (алга таба – Реестр) булдыру һәм аны алып баруны тәэмин итү эшен башкару күздә тотыла. Күрсәтелгән Реестрга Татарстан Республикасы территориясендәге барлык муниципаль берәмлекләр кертелә, ә аны төзү һәм алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Ми-





**Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы өлкәсендәге законнар**

2004 елның 5 июненнән Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Бюджет кодексы гамәлгә керде, ул Татарстан Республикасы бюджет системасының барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларының һәм бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетларының керемнәрне барлыкка китерү һәм чыгымнарын гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасының дәүләт хисаплашуларын һәм муниципаль хисаплашуларны гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасының дәүләт бурычын һәм муниципаль бурычны җайга салу барышында бюджет-хокук мөнәсәбәтләре субъектлары арасында барлыкка килә торган бюджет-хокук мөнәсәбәтләрен, шулай ук Татарстан Республикасы бюджет системасының барлык дәрәҗәләрдәге бюджетлары проектларын эшләү һәм карау, Татарстан Республикасы бюджет системасының барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларын раслау һәм үтәү, аларның үтәлешен тикшереп тору барышында бюджет-хокук мөнәсәбәтләре субъектлары арасында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Татарстан Республикасының бюджет системасы структурасы «Татарстан Республикасы бюджет төзелеше» турындагы II бүлектә билгеләнгән. Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларына түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты;

җирле бюджетлар, шул исәптән:

муниципаль районнар бюджетлары, шәһәр округлары бюджетлары;

шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетлары.

Бюджет кодексының III бүлеге бюджетларның керемнәренә һәм чыгымнарына багышланган, анда тулы күләмдә һәм санау нормативлары белән бергә Татарстан Республикасы бюджетының барлык салым керемнәре саналган, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советының һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен барлыкка китерү буенча вәкаләтләре билгеләнгән.

Дәүләт бурычы өлкәсендәге хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган «Татарстан Республикасы дәүләт бурычы турында» 1997 елның 22 маендагы 1181 номерлы Татарстан Республикасы Законы 2004 елның 16 мартыннан үз көчен югалткан дип танылды. Бу өзеклек Татарстан Республикасы Бюджет кодексының дәүләт бурычы хакында нигезләмәләре булган «Бюджет кытлыгы һәм аны каплау чыганаклары» турындагы IV бүлеге белән җайга салынды.

кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары-резидентлары өчен дә гамәлгә кертелә.

Татарстан Республикасы салым законнары нигезендә индивидуаль эшкуарларның патент системасын куллану мөмкинлеге каралган. «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» 2012 елның 29 сентябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы индивидуаль эшкуарларга патент нигезендә салым түләү хокукы бирә торган эшкуарлык эшчәнлеге төрләрен һәм һәр эшчәнлек төре буенча индивидуаль эшкуарның потенциаль алырга мөмкин булган еллык кереме күләмнәре билгеләнә. Керем күләме хезмәткәрләр санына, транспорт чаралары санына, шулай ук Татарстан Республикасы торак пунктларындагы халык санына дифференцияләнгән.

2015 елның 1 гыйнварыннан Россия Федерациясендә физик затлар мөлкәтенә җирле салым булдырылды, ул Салым кодексының яңа 32 статьясында бәян ителә. Салымның төп таләпләре Салым кодексында билгеләнгән, аерым алганда, салым базасы объектның (торак йорт, торак урын (фатир, бүлмә) гараж, машина кую урыны, бердәм күчемсез мөлкәт комплексы, тәмамланмаган төзелеш, башка бина, корылма, төзелмә, урын) кадастр бәясеннән чыгып билгеләнә. Шул ук вакытта Россия Федерациясе субъектының закон чыгару (вәкиллекле) органы 2020 елның 1 гыйнварына кадәр Россия Федерациясенең шул субъект территориясендә салым базасын кадастр бәясеннән чыгып билгеләү кулланыла башлауның бердәм датасы хакында карар кабул итәргә тиеш. Мондый карар кабул ителгәнгә кадәр, әгәр мондый карар кабул ителмәсә – 2020 елның 1 гыйнварына кадәр, бу субъект территориясендә салым салу объектларның инвентаризация бәясеннән чыгып исәпләнә.

Татарстан Республикасы территориясендә күчемсез милек объектларын 2011 елның 4 июненә дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 282 номерлы карары белән раслануга бәйле рәвештә 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын объектларның кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен 2015 елның 1 гыйнварыннан кулланa башлау турында карар кабул ителде.





нистрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә. 45-ТРЗ номерлы Законның 11 статьясындагы 2 өлеше һәм 58 статьясындагы 7 өлешенең 2 пункты нигезендә Министрлар Кабинеты Реестрны алып бару тәртибен, шулай ук Реестрны алып барырга вәкаләтле башкарма хакимият органын раслый.

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 26.3 статьясына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 27 маендагы 136-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә федераль законнарга кертелгән яңалыкларны гамәлгә ашыру максатларында 2014 елның 29 ноябрендәге 110-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде. Бу Закон нигезендә муниципаль районның муниципаль район составына керүче җирлекләр башлыкларыннан һәм әлеге җирлекләрнең вәкиллекле органнарының җирлек халкы санына бәйсез рәвештә вәкиллекнең тигез нормасы нигезендә җирлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан үз составларыннан сайлана торган депутатларыннан торучы вәкиллекле органын төзү схемасы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларының муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан үз составыннан сайлануы билгеләнде.

Моннан тыш, авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре исемлегенә өстәмәләр кертү турында федераль законда бирелгән хокукны гамәлгә ашырып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 статьясында билгеләнгән мәсьәләләрдән тыш, күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законы нигезендә авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыюны һәм читкә чыгаруны оештыру, шулай ук ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру һәм мәет җирләү урыннарын карап тоту да кертелде.

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән (алга таба – 23-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасы территориясендә җирле референдумны билгеләү, аны әзерләү һәм уздыру тәртибе җайга салына.

Җирле референдум җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне халык турыдан-туры үзе хәл итү максатларында уздырыла. Җирле референдум муниципаль берәмлекнең бөтен территориясендә уздырыла.

Җирле референдумда тавыш бирү, ягъни референдумда катнашу хокукына 18 яшь тулган, яшәү урыны муниципаль берәмлек чикләрендә булган Россия Федерациясе гражданы ия була. Тавыш бирү көненә 18 яше тулган граждан законнарда референдумны әзерләү һәм уздыру буенча 23-ТРЗ номерлы Законда каралган һәм законлы ысуллар белән уздырыла торган башка гамәлләрдә катнашырга хокуклы. Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре нигезендә һәм 23-ТРЗ номерлы Законда билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль берәмлек территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары җирле референдумда Россия Федерациясе гражданнары катнаша торган шартларда катнашырга хокуклы.

Референдумга бары тик җирле әһәмияттәге мәсьәләләр генә чыгарылырга мөмкин.

Күрсәтелгән Законда билгеләнгәнчә, референдумда катнашу хокукына ия гражданнар, уставларында сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда катнашу каралган һәм федераль законнарда билгеләнгән тәртипләрдә һәм срокларда теркәлгән сайлау берләшмәләре, башка иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук җирле администрация башлыгы белән берлектә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы референдумны уздыру инициативасын күрсәтүче субъектлар булалар.

Референдум уздыру инициативасы белән чыгу тәртибе 23-ТРЗ номерлы Закон таләпләренә, муниципаль берәмлек уставына туры килгән очракта, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы җирле референдумны билгели. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы һәм җирле администрация башлыгы тарафыннан бергәләп күрсәтелә торган референдумны уздыру инициативасы муниципаль берәмлек вәкиллекле органының һәм җирле администрация башлыгының хокукый актлары белән рәсмиләштерелә.

Муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе, әгәр җирле референдумда муниципаль берәмлек территориясендәге референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның яртысыннан артыгы катнашса, җирле референдумны узган дип таный. Җирле референдум карары, әгәр тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучыларның 50 проценттан артыгы аны хуплап тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

Референдумда кабул ителгән карар катгый һәм тиешле муниципаль берәмлекнең бөтен территориясендә гамәлдә була.

«Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законына, «Татарстан Республикасы референдумы турында» Татарстан Республикасы Законы кебек үк, аның нигезләмәләрен





49-ТРЗ номерлы Законда билгеләнгән салым ташламалары салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектларына карата бирелми.

Россия Федерациясе Салым кодексында (284 статья) Россия Федерациясе субъектларына субъектлар бюджетларына кертелергә тиешле оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен киметү хокукы бирелгән. Шул ук вакытта бу салым ставкасы 13,5 процентта да ким була алмый. Бу хокук «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2008 елның 2 августындагы 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында гамәлгә ашырыла, анда инвестиция эшчәнлеге субъектларының аерым категорияләре өчен; эшкәртү производствосы, фәнни тикшеренүләр, тәҗрибә-конструктор эшләнмәләре һәм федераль ихтыяҗлар өчен дәүләт оборона заказын үтәүче оешмалар өчен әлеге салым ставкасы 13,5 процентка кадәр киметелгән. «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 8 маендагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында 2011 елның 1 гыйнварыннан 2013 елның 1 июленә кадәр кулланылышка тапшырылган, техник документация нигезендә машина урыны саны кимендә 150 берәмлек булган күпкатлы һәм җир асты урыннарында (парковкаларда) автомототранспорт чараларын куеп тору урыннары (парковкалар) хезмәте күрсәтүләрдән керем тиешле хисап (салым) чорына керемнең 100 процентын тәшкил иткән оешмалар өчен дә салым ставкалары киметелде.

2006 елның 10 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона оешмалары-резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын ун елга 2016 елның 1 гыйнварына кадәр киметү каралган. «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона оешмалары-резидентлары өчен табышка салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 1 ноябрендәге 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә әлеге салым преференциясе Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә

төзелешен стимуллаштыру максатларында 2011 елның 1 гыйнварыннан 2014 елның 1 гыйнварына кадәр кулланылышка тапшырылган, техник документация нигезендә кимендә 100 берәмлек машина урынына исәпләнгән күпкатлы һәм җирасты машина кую урыннарында (парковкаларда) автомототранспорт чараларын кую урыны (парковкалар) хезмәте күрсәтү өчен файдаланыла торган мөлкәткә 0,01 процент күләмендә салым ставкасы урнаштырылды.

Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында 1872 номерлы Закон нигезендә төзелгән шартнамә буенча инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар мөлкәтенә, оешма бизнес-планда каралган шартларны үтәгән очракта; инновация проектларын гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы хөкүмәтләре карарлары белән төзелгән технопаркларның (индустрия паркларының), инновация-технология үзәкләренең түләү бәрабәренә вакытлыча биләүгә һәм файдалануга яисә вакытлыча файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән мөлкәтенә салым ставкасы 0,1 процент күләмендә билгеләнде. 2013 елның 8 октябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә йөк автотранспорты чараларын җитештерүчеләрнең мөлкәтенә салым ставкасы 0,5 процент күләмендә билгеләнде.

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 12 статьясына һәм икенче өлешендәге 30 бүлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 2 ноябрендәге 307-ФЗ номерлы Федераль законы белән Россия Федерациясе субъектларына күчемсез мөлкәтнең кайбер объектлары өчен салым базасын кадастр бәясеннән чыгып билгеләү хокукы бирелде. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 30 октябрендәге 81-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы бу вәкаләтне гамәлгә ашырды. 2015 елның 1 гыйнварыннан халык саны 145 мең кешедән артык булган торак пунктлар территорияләрендә урнашкан гомуми мәйданы 3000 квадрат метрдан артык сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннарга карата салым базасы аларның билгеләнгән тәртиптә расланган кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә. Чираттагы салым чорына күчемсез мөлкәт объектлары исемлеге бу салым чорының 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан билгеләнә. Салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган гомуми мәйданы 3000 квадрат метрдан артык сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннарга карата карата салым ставкасы 2015 елда – 1,2 процент, 2016 елда – 1,5 процент, 2017 елда – 1,8 процент, 2018 елда һәм аннан соңгы елларда 2 процент күләмендә билгеләнә.





«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү зарурлыгына бәйле рәвештә шактый үзгәрешләр кертелде.

Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары депутатларын, сайланулы органы әгъзаларын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын сайлаулар, шулай ук Федераль закон нигезендә муниципаль сайлаулар уздырганда Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларын гарантияләү тәртибе Татарстан Республикасы Сайлау кодексы (алга таба – Кодекс) белән билгеләнә. Муниципаль сайлаулар җирле үзидарәнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә. Муниципаль сайлауларны билгеләү турындагы карар тавыш бирү көненә кадәр 90 көннән дә алданрак булмаган һәм 80 көннән дә соңрак булмаган вакытта кабул ителергә тиеш.

Актив сайлау хокукына – җирле үзидарә органнары депутатларын, сайланулы органы әгъзаларын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын сайлау хокукына – Кодекста күрсәтелгәнчә, 18 яше тулган, яшәү урыны сайлау округы чикләрендә булган Россия Федерациясе гражданы ия була.

21 яшькә җиткән граждан җирле үзидарә органы депутаты, сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты булып сайланырга мөмкин (пассив сайлау хокукы).

Пассив сайлау хокукына ия гражданнар бердәм сайлау округы буенча җирле үзидарәнең вәкиллекле органына сайлаулар уздырганда депутатлыкка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзаларына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына турыдан-туры йә сайлау берләшмәсе тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлеге составында кандидатлар итеп чыгарылырга мөмкин. Кандидатларның турыдан-туры күрсәтелүе үз-үзен күрсәтү юлы белән, сәяси партия, башка иҗтимагый берләшмә тарафыннан күрсәтү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Татарстан Республикасы Сайлау кодексында муниципаль сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыручы сайлау комиссияләре системасы билгеләнгән, бу – муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре, округ сайлау комиссияләре һәм участок сайлау комиссияләре.

Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә муниципаль берәмлек уставында тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның кандидатларны сайланган дип тану өчен кирәкле минималь тавышлары саны билгеләнә.

Татарстан Республикасында җирле үзидарә оештыру максатларында 131-ФЗ номерлы Федераль законның 85 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты һәм 3 өлеше нигезендә муниципаль берәмлекләрнең чикләрен билгеләү һәм тиешле муниципаль берәмлекләргә шәһәр, авыл җирлеге, шәһәр округы, муниципаль район статусы бирү турында түбәндәге Татарстан Республикасы законнары кабул ителде:

1) «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм аның статусы турында» 2004 елның 15 сентябрендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

2) «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеген төзү, аның чикләрен билгеләү һәм аңа шәһәр округы статусын бирү турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

3) «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

4) «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

5) «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

6) «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

7) «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

8) «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;





маль ставкаларын билгели торган яңа «Уен бизнесына салым ставкалары турында» 2012 елның 24 февралендәге 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде.

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 49-ТРЗ номерлы Закон) белән Татарстан Республикасы территориясендә оешмалар мөлкәтенә салым кертелде, максималь рөхсәт ителгән 2,2 процент күләмендә салым ставкасы, салымны түләү тәртибе һәм вакытлары, шулай ук салым ташламалары һәм алардан файдалану нигезләре билгеләнде.

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 11 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Салым кодексы нигезләмәләре буенча гомуми файдаланудагы тимер юлларга, магистраль торбаүткәргечләргә, электр тапшыруы линияләренә, шулай ук күрсәтелгән объектларның аерылгысыз технологик өлеше булып торган корылмаларга карата ташламалы салым ставкалары билгеләнде: 2013 елда – 0,4 процент, 2014 елда – 0,7 процент, 2015 елда – 1,0 процент, 2016 елда – 1,3 процент, 2017 елда – 1,6 процент, 2018 елда 1,9 процент күләмендә.

Оешмалар мөлкәтенә салым буенча ташламалар салым түләүдән тулысынча азат итү рәвешендә, шулай ук салым түләүчеләрнең аерым категорияләре буенча дифференцияләшкән киметелгән салым ставкалары рәвешендә карала.

Мәсәлән, «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 1872 номерлы Закон) нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы Алабуга районында урнашкан «Алабуга» Алабуга автомобиль заводы сәнәгать мәйданчыклары территориясендәге оешмалар; оешмалар – законнарда билгеләнгән тәртиптә җирле һәм региональ әһәмиятле тарихи һәм мәдәни ядкарьләр дип танылган һәм мәдәният һәм сәнгать, мәгариф, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэмин итү ихтыяҗлары өчен яисә дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган объектларга карата; оешмалар – торак фонды объектларына карата; гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача хуҗалыгы берләшмәләре мөлкәте – бакчачылыкны, яшелчәчелекне һәм дача хуҗалыгын алып баруның социаль-хуҗалык мәсьәләләрен тәэмин итү максатларында куллана торган мөлкәткә карата һәм башкалар салым түләүдән азат ителгән. Яңа парковкалар

2010 елның 14 октябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән 24-ТРЗ номерлы Законның элекке редакциясендәге текстына Россия Федерациясе Салым кодексы нормалары кабатлана торган нигезләмәләрне төшереп калдыруга кагылышлы шактый төзәтүләр кертелде, турыдан-туры Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләренә керүче мәсьәләләрне регламентлаучы нормалар гына гамәлдә калды.

2014 елның 2 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 24-ТРЗ номерлы Законнан шулай ук салым түләүчеләр – физик затлар тарафыннан салым түләү тәртибен һәм срокларын җайга сала торган нигезләмәләр дә төшереп калдырылды, бу әлеге мәсьәләләрнең 2015 елның 1 гыйнварыннан Салым кодексы белән җайга салынуына бәйле. Мәсәлән, Салым кодексының 363 статьясы нигезендә 2015 елның салым чорыннан башлап физик затлар булган салым түләүчеләр салымны, үткән салым чорыннан соң килә торган елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча, салым түләүчеләргә, түләү вакыты җитәргә кимендә 30 көн кала, транспорт чарасының теркәлү урыны буенча салым органы җибәрә торган салым хәбәрнамәсе нигезендә түлиләр.

2014 елның 11 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 2014 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона оешмалары-резидентлары белән беррәттән, Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы оешмалары-резидентлары да транспорт чарасы теркәлгән вакыттан алып 10 ел дәвамында транспорт салымы түләүдән азат ителә.

Россия Федерациясе Салым кодексының «Уен бизнесына салым» турында 29 бүлегендә уен бизнесына карата Россия Федерациясе субъектларына үз территорияләрендә салым ставкалары урнаштыру хокукы бирелә. 2011 елның 16 ноябрендәге 319-ФЗ номерлы Федераль закон белән Россия Федерациясе Салым кодексының 29 бүлегенә үзгәрешләр кертелде, аерым алганда, салым салуның яңа объектлары барлыкка килде: тотализаторның процессинг үзәге, букмекер конторасы процессинг үзәге, тотализатор ставкаларын кабул итү пункты, букмекер конторасы ставкаларын кабул итү пункты, болар «Татарстан Республикасында уен бизнесына салым ставкалары турында» 2003 елның 23 сентябрендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көчен югалткан дип тануны таләп итте. Бер үк вакытта күрсәтелгән объектлар буенча уен бизнесына салымның макси-





9) «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

10) «Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

11) «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

12) «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

13) «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

14) «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

15) «Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

16) «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

17) «Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турын-

да» 2005 елның 31 гыйнварындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

18) «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

19) «Чүпрәле муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

20) «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

21) «Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

22) «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

23) «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 25-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

24) «Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

25) «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

26) «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең террито-





яңа производство төзү һәм (яисә) гамәлдәге производствоны яңадан торгызу (киңәйтү, реконструкцияләү, техник яктан яңадан кораллandыру).

Инвестицияле салым кредиты Татарстан Республикасы бюджетына күчерү өчен билгеләнгән салым ставкасы буенча оешмалар табышына салым буенча, шулай ук региональ салымнар: оешмалар мөлкәтенә салымга, транспорт салымына — кредиттан файдаланган өчен Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының икедән бере күләмендә процентлар санап, бер елдан җиде елга кадәр срокка бирелергә мөмкин.

Инвестицияле салым кредиты оешманың салымнар һәм җыемнар буенча бурычлары, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына пенялар, штрафлар булмаган, шулай ук оешмага инвестицияле салым кредитын алу өчен нигез булып торучы инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт ярдәменең башка рәвешләре күрсәтелмәгән очракларда бирелә.

Инвестицияле салым кредиты бирү турында карар, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килешенеп, кызыксынучы оешма гаризасы нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан кабул ителә. Шул ук вакытта оешма инвестицияле салым кредиты буенча бурычларын, шул исәптән инвестицияле салым кредитыннан файдаланган өчен процентларны, мөлкәт залогы йә поручительлек рәвешендә кире кайтару йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә тиеш. Залог предметы булып торучы мөлкәткә карата оешма тарафыннан мөлкәт иминияте шартнамәсе төзелә. Инвестицияле салым кредиты бирү Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм әлеге оешма арасында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы раслаган рәвештә шартнамә белән рәсмиләштерелә.

«Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба — 24-ЗРТ номерлы Закон) белән Татарстан Республикасы территориясендә Салым кодексы нигезендә транспорт салымы кертелә, салымның дифференцияләштерелгән ставкалары, салым түләүче оешмалар тарафыннан аны түләү тәртибе һәм вакытлары билгеләнә, шулай ук салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен салым ташламалары һәм алардан файдалану нигезләре карала. Хисап чорында 24-ТРЗ номерлы Законга берничә мәртәбә үзгәрешләр кертелде, аерым алганда, 2009 елның 29 ноябрендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә транспорт салымы ставкалары арттырылды.

сроклары. Шулай ук Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) органнары салымнар турында законнар ярдәмендә Кодекста каралган тәртиптә һәм кысаларда салым ташламаларын, аларны куллану нигезләрен һәм тәртибен урнаштырырга мөмкин.

Региональ салымнар буенча буенча салым салуның башка элементлары һәм салым түләүчеләр Салым кодексында билгеләнә.

Салымнарны законнар белән җайга салу буенча федераль законнарда бирелгән барлык хокуклар Татарстан Республикасында региональ салымнар турындагы законнар һәм салымнар һәм җыемнар турындагы башка законнар белән гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендә каралган Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен «Татарстан Республикасында инвестицияле салым кредиты турында» 2011 елның 10 октябрендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 68-ТРЗ номерлы Закон) кабул ителде, бу Закон нигезендә салым түләү срогын инвестицияле салым кредиты рәвешендә үзгәртү мөмкинлеге урнаштырыла. Инвестицияле салым кредиты белән салым түләүнең срогын үзгәртү ярдәмендә оешмага, Россия Федерациясе Салым кодексының 67 статьясында һәм 68-ТРЗ номерлы Законның 4 статьясында билгеләнгән нигезләрнең берсе булганда, кредит суммасын һәм саналган процентларны киләчәктә этаплап түләп, салым буенча түләүләрен билгеле бер вакытта һәм билгеле бер кысаларда киметү мөмкинлеге бирелә. Мондый нигезләргә түбәндәгеләр керә:

фәнни-тикшеренү яисә тәҗрибә-конструкторлык эшләре йә үз производствосын техник яктан яңадан коралландыру, шул исәптән инвалидлар өчен эш урыннары булдыру яисә әйләнәтирә мохитне сәнәгать калдыклары белән пычратудан яклау һәм (яисә) товарлар җитештерүнең, эшләр башкаруның, хезмәтләр күрсәтүнең энергетик нәтиҗәлелеген арттыру;

гамәлгә кертү яисә инновация эшчәнлеген, шул исәптән яңа технологияләр булдыруны йә булганнарын камилләштерүне, чималның һәм материалларның яңа төрләрен булдыруны тормышка ашыру;

иң югары класслы энергетика нәтиҗәлелегенә ия, шул исәптән күпфатирлы йортлар, һәм (яисә) яңартыла торган энергия чыганакларына караган һәм (яисә) җылылык энергиясе, электр энергиясе эшләп чыгару буенча файдалы эш коэффициенты 57 процентган югарырак булган объектларга караган объектлар һәм (яисә) Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган исемлек нигезендә югары энергетика нәтиҗәлелегенә ия башка объектлар, технологияләр булдыруга инвестицияләр кертү;





рияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

27) «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

28) «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

29) «Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

30) «Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 29-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

31) «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 30-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

32) «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

33) «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 36-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

34) «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

35) «Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

36) «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

37) «Саба муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

38) «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

39) «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

40) «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

41) «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

42) «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

43) «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005





нарына авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча түбәндәге вәкаләтләр бирелә: авыл хуҗалыгы исәбенә алына торган объектлар турында белешмәләр җыючы затларны өйрәтү һәм аларның эшләве өчен, авыл хуҗалыгы исәбен алу кәгазьләрен, авыл хуҗалыгы исәбен алуның башка документларын саклау өчен яраклы биналар белән тәэмин итү; авыл хуҗалыгы исәбенә алына торган объектлар турында белешмәләр җыючы затларны өйрәтү һәм аларның эшләве өчен, авыл хуҗалыгы исәбен алу кәгазьләрен, авыл хуҗалыгы исәбен алуның башка документларын саклау өчен яраклы биналарны тиешенчә саклауны оештыру, шулай ук транспорт чаралары һәм элемтә хезмәтләре күрсәтү.

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2014 елның 14 маендагы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 31-ТРЗ номерлы Закон) нигезендә күрсәтелгән вәкаләтләр муниципаль районнар һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына бирелә. Җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруына бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган федераль бюджет акчалары исәбеннән башкарыла. Субвенцияләр Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән җирле бюджетлар арасында 31-ТРЗ номерлы Законда расланган методика нигезендә бүленә.

### Салымнар һәм җыемнар өлкәсендәге законнар

Россия Федерациясендә салымнар һәм җыемнарның федераль, региональ һәм җирле төрләре билгеләнгән. Россия Федерациясе субъектлары законнары белән бары тик региональ салымнар гына урнаштырылырга һәм кертелергә мөмкин, аларга оешмалар мөлкәтенә салым, уен бизнесына салым һәм транспорт салымы керә. Шул ук вакытта Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) органнары, региональ салым урнаштырганда, федераль дәүләт хакимияте органнарына федераль салымнар һәм җыемнар урнаштырганда бирелгән тулы хакимияткә ия түгел. Россия Федерациясе Салым кодексы (алга таба – Салым кодексы) нигезендә Россия Федерациясе субъектлары законнары Кодекста каралган тәртиптә һәм кысаларда региональ салымнар буенча салым салуның түбәндәге элементларын билгели: салым ставкалары, салымнарны түләү тәртибе һәм

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 66-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча, шул исәптән, күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзүдә катнашучылар шартнамә буенча түләгән акчаларның төзүче тарафыннан максатчан кулланылуын тикшереп тору; өлешле төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында төзүчеләрдән квартал саен хисап алу; суд органнарына мөрәҗәгать итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирә.

2014 елның 23 июлендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт җайга салуын гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимияте органы тарафыннан билгеләнгән критерийлар нигезендә акчалары күпфатирлы йортларны төзүгә җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнарны зыян күргәннәр дип тану һәм мондый гражданнарның реестрын алып бару вәкаләтләрен бирә.

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2014 елның 14 маендагы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 10 апрелендәге 316 номерлы карары нигезендә 2016 елның 1 июленнән 15 августына кадәр 2016 елның 1 июле мәгълүматлары буенча 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны (алга таба шулай ук – авыл хуҗалыгы исәбен алу) үткәрү турында карар кабул ителде.

«Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 108-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте орган-





елның 31 гыйнварындагы 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

44) «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

45) «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

131-ФЗ номерлы Федераль законның 85 статьясындагы 3 өлеше нигезендә муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләренең картографик тасвирламалары булдырылды һәм түбәндәге законнар кабул ителде:

1) «Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору, аларның чикләрен үзгәртү һәм Татарстан Республикасының кайбер законнарына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 28 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

2) «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 19 маендагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

3) «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 20 маендагы 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

4) «Әтнә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 25 июлендәге 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

5) «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 25 июлендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

6) «Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 26 июлендәге 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

7) «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 29 июлендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

8) «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 29 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

9) «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 29 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

10) «Муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 29 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

11) «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 7 августындагы 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

12) «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 8 августындагы 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

13) «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»





тыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы вәкаләтләрен билгели.

9-ТРЗ номерлы Закон нигезендә граждан вәкаләтле орган билгеләгән срокта универсаль электрон карта алудан баш тарту турындагы гариза белән вәкаләтле оешмага мөрәҗәгать итмәгән һәм (яисә) банк сайлау турындагы мәгълүматны җибәрмәгән очракларда мондый кушымтаның эшләвен тәэмин итү максатларында электрон банк кушымтасы кысаларында хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итүче банкны сайлап алу буенча конкурс уздырыла.

Конкурсны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы оештыра.

«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 58-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасының мәгълүмат системаларын Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә бертигез нигездә булдыру һәм үстерүгә, Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләреннән нәтиҗәле файдалануны арттыруга, киң мәгълүмат кырында Татарстан Республикасының катнашуы өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

58-ТРЗ номерлы Закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасын мәгълүматлаштыру программасы раслана, анда, бюджет чыгымнарының күләмнәрен күрсәтеп, Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен кертү чараларының исемлеге, шулай ук аларны гамәлгә ашыру планы бирелә.

Татарстан Республикасын мәгълүматлаштыру программасын гамәлгә ашыруны нәтиҗәле тәэмин итү максатларында тикшереп тору һәм мониторинглау системасын булдыру карала, моңа Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары эшчәнлегендә мәгълүмат һәм коммуникация технологияләреннән файдалануның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү дә керә.

58-ТРЗ номерлы Законда мәгълүматлаштыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре билгеләнә, аларга 2010 елның 25 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Закон белән Татарстан Республикасында мәгълүмат технологияләре өлкәсендә кластер булдыру кертелде. Күрсәтелгән Законда шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдалануны туктату һәм алардан исәптән төшерү тәртибе дә билгеләнгән.

Законда пассажирлар йөртүне оештыруга төп таләпләр (пассажирлар йөртүне оештыру тәртибе, маршрут челтәрен төзү, пассажирлар йөртүчеләргә таләпләр, пассажирлар йөртүнең һәм пассажир транспорты эшчәнлегенең тотрыклылыгын, иминлеген тәэмин итү, пассажирлар йөртүгә диспетчер хезмәте күрсәтү һәм пассажирлар йөртүне тикшереп тору өлешендә) раслана.

2012 елның 13 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында йөртүләрнең коммерциячел пассажирлар йөртү төренә сылтама төшереп калдырыла (Законның элеккеге редакциясендә коммерциячел пассажирлар йөртү дигәндә расланган дәүләт заказыннан тыш (муниципаль заказдан) автомобиль транспортында өстәмә рәвештә пассажирлар йөртүне аңларга кирәк, алар, мондый йөртүләргә ихтыяҗ булганда, өстәмә маршрутлар буенча әлеге Закон, башка норматив хокукый актлар таләпләре нигезендә башкарылырга мөмкин).

2012 елның 2 ноябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы халыкның имин һәм сыйфатлы йөртүгә ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатында пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның иң яхшы шартларын тәэмин итәрлек пассажирлар йөртүчеләрне конкурс нигезендә сайлап алуны урнаштыра. Конкурс предметы (даими йөрү маршрутында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга шартнамә төзү) һәм объекты (кирәкле параметрлары (маршрутның башы һәм ахыры, хәрәкәт составы саны һәм аны куллану характеристикалары, хәрәкәт итү интерваллары яисә рейслар саны) күрсәтелгән бер яисә берничә маршрутны үз эченә алган лотлар (лот) билгеләнә. Гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру хокукына конкурсны оештыру пассажирлар йөртү заказчысына – Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

«Татарстан Республикасында универсаль электрон карталарны чыгару, бирү һәм аларга хезмәт күрсәтү эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләре турында» 2014 елның 20 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы (алга таба – 9-ТРЗ номерлы Закон) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасында универсаль электрон карталарны чыгару, бирү һәм аларга хезмәт күрсәтү эшчәнлеген оештыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга сала.

9-ТРЗ номерлы Закон Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләрен, шулай ук универсаль электрон карталарны чыгару, бирү һәм аларга хезмәт күрсәтү эшчәнлеген оеш-





2008 елның 8 августындагы 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

14) «Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 8 августындагы 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

15) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Саба муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 7 октябрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

16) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 9 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

17) «Әлмәт муниципаль районының Яңа Никольский һәм Урсалы авыл җирлекләрен үзгәртеп төзү һәм «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 13 октябрендәге 104-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

18) «Аксубай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 19 ноябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

19) «Минзәлә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 19 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

20) «Балык Бистәсе муниципаль районы территориясе чиген үзгәртү, Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелешен үзгәртү һәм «Балык Бистәсе муниципаль районы»

муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 19 ноябрендәге 108-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

21) «Нурлат муниципаль районының Фома авыл җирлеген үзгәртеп оештыру һәм «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 20 ноябрендәге 110-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

22) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 20 ноябрендәге 111-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

23) «Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 20 ноябрендәге 112-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

24) «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 21 ноябрендәге 113-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

25) «Мамадыш муниципаль районы территориясе чиген үзгәртү, Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелешен үзгәртү һәм «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 24 ноябрендәге 115-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

26) «Зәй муниципаль районы территориясе чиген үзгәртү һәм «Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008





мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы), дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар, күрсәтелгән мөлкәтне сату турында һәм аны сату йомгаклары хакында мәгълүмати хәбәрләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәсми матбугат басмаларында бастырып чыгарылырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларда урнаштырылырга тиеш.

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 23 июлендәге 244-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә 43-ТРЗ номерлы Законга үзгәрешләр кертелде, алар дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турындагы карар эчтәлеге өлешенә кагыла. Аерым алганда, электр челтәре хуҗалыклары объектларын, җылылык энергиясе чыганакларын, җылылык челтәрләрен, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларын һәм мондый системаларның аерым объектларын хосусыйлаштырган очракта, хосусыйлаштыру турындагы карар составына инвестиция һәм эксплуатация шартлары кертелергә тиеш.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына күрсәтелгән объектлар хосусыйлаштырылганда йөкләнгән эксплуатация йөкләмәләре шартларын үтәүне тикшереп тору тәртибен билгеләү вәкаләтләре бирелә. (2014 елның 20 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы).

«Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында» 2006 елның 13 ноябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 70-ТРЗ номерлы Закон) даими муниципальара һәм муниципаль маршрутларда халыкка транспорт хезмәте күрсәтү буенча гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.

70-ТРЗ номерлы Законда пассажирлар йөртүдә халыкның ихтыяҗларын канәгатьләндерүне тәэмин итү; пассажирлар йөртүнең сыйфат дәрәҗәсен арттыру; пассажирлар йөртүчеләрнең транспорт дисциплинасын ныгыту; пассажирлар йөрткәндә юл хәрәкәте иминлеген арттыру; пассажирлар йөртүчеләр арасында намуслы конкуренцияне тәэмин итү; пассажирлар йөртү белән дәүләт һәм муниципаль идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру бурычлары хәл ителә.

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 елның 26 июлендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 35-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтеннән рациональ һәм нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү, шулай ук аның сакланышын тикшереп торуны оештыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү тәртибен билгели. 35-ТРЗ номерлы Законның гамәли көче, акцияләрдән тыш, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм башка финанс активлары белән; федераль, муниципаль, хосусый һәм милекнең башка рәвешләрендәге объектлар белән; Татарстан Республикасының җир, су һәм башка табигать ресурслары белән идарә итүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

35-ТРЗ номерлы Закон нигезләмәләре белән дәүләт мөлкәте белән идарә итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре; дәүләт мөлкәтен исәпкә алу, Татарстан Республикасы казнасының күчемсез мөлкәте белән идарә итү, хуҗалык җәмгыятьләренең (ширкәтләренең) устав (тупланма) капиталларындагы акцияләр, өлешләр белән идарә итү тәртибе; дәүләт мөлкәтен түләүсез файдалануга, арендага, залогка, ышанычлы идарәгә тапшыру шартлары, шулай ук дәүләт мөлкәтен федераль һәм муниципаль милеккә тапшыру, дәүләт мөлкәтен бүләк итү, Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәт объектларын инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бирү урнаштырыла.

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 43-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштырганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне һәм дәүләт мөлкәтенә идарә итү буенча шуларга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

43-ТРЗ номерлы Закон нигезендә дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан бер елдан өч елга кадәр вакытка раслана. Фаразлау планында (программасында) план чорына хосусыйлаштыруның төп юнәлешләре һәм бурычлары, әлеге мөлкәтне хосусыйлаштыруның икътисадтагы, шул исәптән икътисадның аерым тармакларындагы, структур үзгәрешләргә йогынтысы фаразы, хосусыйлаштырылырга тиешле дәүләт мөлкәтенә характеристика һәм аны хосусыйлаштыруның якынча вакыты күрсәтелә.

43-ТРЗ номерлы Закон дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итүне җайга сала. Аерым алганда, дәүләт





елның 16 декабрендәге 119-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

27) «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 18 декабрендәге 122-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

28) «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 декабрендәге 128-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

29) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 23 декабрендәге 129-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

30) «Кукмара муниципаль районы территориясе чиген үзгәртү һәм «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 23 декабрендәге 130-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

31) «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

32) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 23 декабрендәге 132-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

33) «Чүпрәле муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»

Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 23 декабрендәге 133-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

34) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү, Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелешен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 24 декабрендәге 134-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

35) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү, Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелешен үзгәртү һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе һәм аның статусы турында» һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 29 декабрендәге 139-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

36) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 29 декабрендәге 140-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

37) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 29 декабрендәге 141-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

38) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 29 декабрендәге 142-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

39) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Кайбыч муниципаль районы» муници-





касы катнашында дәүләти-хосусый партнерлыкны гамәлгә ашыру максатларын, бурычларын, принципларын, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашу рәвешләрен (финанс, мөлкәти һәм мәгълүмати ярдәм) билгели.

50-ТРЗ номерлы Законда дәүләти-хосусый партнерлык дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүләр төзү һәм үтәү юлы белән социаль әһәмияткә ия инфраструктура, инновация, инвестиция проектларын һәм башка проектларны, программаларны гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы һәм хосусый партнерлар арасында, шул исәптән муниципаль берәмлекләр катнашында, үзара файдалы хезмәттәшлек буларак билгеләнә.

Дәүләти-хосусый партнерлык проектларын гамәлгә ашыруга инвесторларны җәлеп итәр өчен кирәкле шартлар тудыру һәм дәүләти-хосусый партнерлык принципларында проектларны гамәлгә ашыру рәвешләрен киңәйтү максатларында 2014 елның 9 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән 50-ТРЗ номерлы Законга үзгәрешләр кертелде, алар дәүләти-хосусый партнерлык өлкәсендә кулланыла торган төп төшенчәләрне һәм терминнарны, дәүләти-хосусый партнерлык субъектларын, шулай ук дәүләти-хосусый партнерлык турында килешүнең эчтәлегенә таләпләрне төгәлләштерүгә юнәлдерелгән. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлык килешүләрендә катнашу төрләренең тулы исемлеге, шулай ук килешү якларының дәүләти-хосусый партнерлык килешүләрендә катнашуының төрле рәвешләреннән берьюлы файдалану мөмкинлеге билгеләнгән. Килешү объектларын эксплуатацияләгәндә гамәлгә ашырыла торган товарларга, эшләргә һәм хезмәт күрсәтүләргә тарифларны дәүләт җайга салуы карала торган дәүләти-хосусый партнерлык проектларын башкарганда, килешүнең гамәлдә булуы дәвамында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бәяләрне (тарифларны) дәүләт җайга салуы өлкәсендәге вәкаләтле органы һәм хосусый партнер арасында озак срокка өчьяклы тариф килешүе (алга таба – тариф килешүе) төзелергә мөмкин.

Дәүләти-хосусый партнерлыкны үстерүнең төп юнәлешләрен билгеләү, килешүләрне, карарларны, республикада дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын камилләштерүгә юнәлдерелгән башка мәсьәләләрне хәл итүне мониторинглау Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасында инвестиция климатын яхшырту буенча коллегиаль киңәшү органына йөкләнгән.

фасына республика территориясендә эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, аларга юридик ярдәм күрсәтү, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлүен тикшереп тору, эшкуарлар җәмәгатьчелеге белән үзара хезмәттәшлек итү, эшкуарлык эшчәнлеген үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу керә.

54-ТРЗ номерлы Законда Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасындагы территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының, бүтән органнарның, оешмаларның, вазыйфаи затларның эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен боза торган карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләрен карау тәртибе һәм сроклары билгеләнә.

Күрсәтелгән шикаятьләрне карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил гариза бирүчегә аның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы мәсьәләләрне аңлатырга, шикаятьне асылы буенча хәл итәргә тиешле дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка җибәрергә йә карарларында яисә гамәлләрендә (гамәл кылмавында) эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозыла дип таныган органга үз бәяләмәсен җибәрергә тиеш.

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил иҗтимагый башлангычларда эш итүче экспертлар, консультатив һәм иҗтимагый советлар, эш төркемнәре һәм башка киңәшү органнары төзергә һәм, алар эшчәнлегендә катнашу өчен, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, эшкуарлар җәмәгатьчелеге, иҗтимагый оешмалар вәкилләрен җәлеп итәргә хокуклы.

«Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» 2011 елның 1 августындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 50-ТРЗ номерлы Закон) республикада дәүләти-хосусый партнерлыкны үстерү өчен хокукый нигезләр булдыру максатларында Татарстан Республи-





паль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 29 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

40) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 29 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

41) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 29 декабрендәге 145-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

42) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» һәм «Питрәч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 29 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

43) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 29 декабрендәге 147-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

44) «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү, Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелешен үзгәртү һәм «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 30 декабрендәге 149-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

Күрсәтелгән законнарның концепциясендә районнар чикләрендә муниципаль берәмлекләрне төзү, аларга муниципаль район статусын бирү, муниципаль районнарның административ үзәкләрен билгеләү күздә тотыла. Шулай ук законнарда муниципаль районнарның һәм муниципаль районнар составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләренең карта-схемалары һәм картографик тасвирламалары нигезендә аларның чикләре, муниципаль берәмлекләргә шәһәр яисә авыл җирлекләре статусын бирү карала, шәһәр һәм авыл җирлекләре төзелә, авыл җирлекләренең административ үзәкләре билгеләнә.

Татарстан Республикасының күрсәтелгән законнары нигезендә республикада 43 муниципаль район; 38 шәһәр җирлеге, шулардан 11 яңа төзелгәннәр – Азнакай шәһәре, Баулы шәһәре, Алабуга шәһәре, Чистай шәһәре, Лениногорск шәһәре, Нурлат шәһәре, Түбән Кама шәһәре, Зеленодольск шәһәре, Зәй шәһәре, Бөгелмә шәһәре, Әлмәт шәһәре; 916 авыл җирлеге, шулардан 1 яңа төзелгән – Круглое Поле авыл җирлеге; шәһәр округы статусы бирелгән 2 муниципаль берәмлек – Казан шәһәре һәм Чаллы шәһәре.

2014 елның 13 декабрендәге 115-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Введенский Бистәсе авыл җирлеген үзгәртеп кору юлы белән Татарстан Республикасының яңа муниципаль берәмлеге – «Иннополис шәһәре» шәһәр җирлеге төзелде.

Шулай итеп, 2015 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында 956 муниципаль берәмлек санала: 43 муниципаль район, 2 шәһәр округы, 911 шәһәр һәм авыл җирлекләре.

131-ФЗ номерлы Федераль законның 84 статьясы нигезендә «Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составында шәһәр эче муниципаль берәмлеген төзү турында» 2005 елның 2 апрелендәге 61-ТРЗ номерлы һәм «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составында шәһәр эче муниципаль берәмлекләрен төзү турында» 2005 елның 2 апрелендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары белән «Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составындагы «Түбән Нурлат җирле үзидарәсе» һәм аның җирле үзидарә органнары, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе составындагы 25 шәһәр эче муниципаль берәмлеге һәм аларның җирле үзидарә органнары 2006 елның 1 гыйнварыннан бетерелде.

131-ФЗ номерлы Федераль законның 85 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктындагы беренче абзацы нигезләмәләрен гамәлгә ашыру кысаларында «Татарстан Республикасында яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрдә җирле үзидарә органнарын оешты-





эшкуарлыкны үстерүнең федераль, региональ муниципаль программалары нигезендә генә күрсәтелергә мөмкин.

Моннан тыш, федераль закон чыгаручы ташламалы шартларда сатып алына торган бина мәйданының иң чик күләмен чикләүне бетерде, шулай ук күчемсез мөлкәт өчен түләү тәртибен төгәлләштерде – сатып алына торган мөлкәт өчен кичектереп түләү кимендә өч елга бирелә һәм ай саен яисә квартал саен тигез өлешләп түләнә. Шуңа бәйле рәвештә «Арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары сатып ала торган арендаланучы биналар мәйданының иң чик күрсәткечләрен һәм сатып алына торган мөлкәт өчен түләүне кичектереп тору срогын билгеләү турында« 2008 елның 3 октябрендәге 79-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көчен югалткан дип танылды.

Эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнү өчен шартларны яхшырту максатларында Россия Федерациясе Президентының «Дәүләтнең озак вакытка икътисадый сәясәте турында» 2012 елның 7 маендагы 596 номерлы Указы белән Россия Федерациясе Хөкүмәтенә эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил институтын булдыру йөкләнде. Россия Федерациясе Президентының әлеге Указын гамәлгә ашыру өчен «Россия Федерациясендә эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр турында» 2013 елның 7 маендагы 78-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителде, ул Россия Федерациясе субъектларында эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил институтын булдыруны күздә тота.

Федераль законны гамәлгә ашырып, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең хокукый хәлен, төп бурычларын һәм компетенциясен билгели торган «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 54-ТРЗ номерлы Закон) кабул ителде.

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил вазыйфага, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил белән килештерелеп, эшкуарлар җәмәгатьчелеге фикерен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан биш елга билгеләп куела.

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил вазый-

мөнәсәбәтләрне җайга сала, шундый ярдәмнең принципларын, шартларын, рәвешләрен һәм төрләрен, ярдәм итү чаралары һәм ресурслары чыганакларын билгели, шулай ук Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән башка чараларны күздә тота.

7-ТРЗ номерлы Закон кече һәм урта эшкуарлык субъектлары үсеше өчен уңай шартлар тәэмин итүгә, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының санын арттыруга һәм аларның конкуренциягә сәләтлелеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

7-ТРЗ номерлы Законда кече һәм урта эшкуарлык субъектларын бу өлкәдә дәүләт сәясәтен эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга җәлеп итү; республика, муниципальара әһәмиятле, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән инициативалар күрсәтү һәм аларга ярдәм итү; кече һәм урта эшкуарлык үсешен җайга сала торган законнар һәм бүтән норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрү; кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендәге өстенлекләрне билгеләгәндә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына тәкъдимнәр эшләү; гражданнарның эшкуарлык эшчәнлеген башкару хокукын гамәлгә ашыруга кагылышлы мәсьәләләр турында фикер алышуга һәм әлеге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләүгә гражданнарны, иҗтимагый берләшмәләрне һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен җәлеп итү максатларында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә координация һәм киңәшләшү органнарын оештыру каралган.

«Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү тәртибен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 2 июлендәге 144-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга һәм «Техник җайга салу турында» Федераль законның 46 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 23 июлендәге 238-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә 7-ТРЗ номерлы Законга үзгәрешләр кертелде. Күрсәтелгән федераль законнарны гамәлгә ашыру өчен кабул ителгән 2014 елның 20 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерүнең муниципальара программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру вәкаләтләре бетерелде, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан кече һәм урта





ру турында» 2005 елның 8 апрелендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде, ул муниципаль район составына керә торган һәр җирлектән вәкилләр билгеләү юлы белән яңа төзелгән муниципаль районнарның беренче чакырылыш вәкиллекле органнарын төзү тәртибен; Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары тарафыннан яңа төзелгән муниципаль берәмлекләр башлыкларын сайлау тәртибен; яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең беренче чакырылыш вәкиллекле органнарының муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче халык санына бәйле рәвештә санлы составын; яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең биш еллык срогын билгели һәм вәкиллекле органнар депутатларын сайлаулар датасын 2005 елның 16 октябрендә уздырырга дип билгели.

Күрсәтелгән Закон нигезендә республикада җирле үзидарә органнарын төзү буенча максатчан эш башкарылды.

Куелган бурычлар үтәлү сәбәпле, бу закон 2011 елның 23 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән үз көчен югалткан дип танылды.

131-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясы нигезендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлеге турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының (Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнарының) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлеге принципларын һәм Муниципаль берәмлекләр советы белән үзара эшчәнлек буенча әлеге органнарның вәкаләтләрен билгели.

131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы нигезендә «Муниципаль районның (шәһәр округының) башкарма комитеты җитәкчесе өчен федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы контракт шартлары турында» 2005 елның 12 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән (алга таба – 123-ТРЗ номерлы Закон) муниципаль районның башкарма комитеты җитәкчесе өчен федераль

законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы контракт шартлары расланды.

Күрсәтелгән Законның 2 статьясы башкарма комитет җитәкчесенең аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешендәге түбәндәге хокукларын һәм бурычларын билгели: бу вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү, шулай ук башкарма комитетның аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен кирәкле эшен оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәләр чыгару хокукын; аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алу хокукын; аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе турындагы тәкъдим белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына мөрәҗәгать итү хокукын; башкарма комитетның аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле эшен оештыру бурычын; матди ресурсларның һәм финанс чараларының саклanышын һәм максатчан кулланылуын үз вәкаләтләре чикләрендә тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар күрү бурычларын һәм башкаларны. Бу очраклар контракт өчен кирәкле шартлар булып тора һәм башкарма хакимият җитәкчесе белән контракт төзү текстына катгый рәвештә кертелергә тиеш.

123-ТРЗ номерлы Законның 3 статьясы нигезендә башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге критерийлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган индикаторлар белән карала һәм тапшырылган һәр дәүләт вәкаләте буенча башкарма комитет җитәкчесе белән төзелә торган контракт текстына кертелә.

Башкарма комитет җитәкчесе аерым дәүләт вәкаләтләрен башкармаган яисә тиешенчә башкармаган өчен шушы максатлар өчен муниципаль берәмлеккә бүлеп бирелгән матди ресурслар һәм финанс чаралары чикләрендә федераль законнар нигезендә җаваплы була.

Муниципаль хезмәткә урнашу һәм аны узу тәртибе федераль һәм республика законнары белән регламентлаштырыла. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру йөзеннән «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» кабул ителде (2013 елның 22 июнендәге 50-ТРЗ номерлы), ул 2008 елдан бирле гамәлдә булган өч республика законының — «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында», «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт реестры турында» һәм «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граж-





рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр җайга салына. Әлеге Законда инновация эшчәнлеге субъектлары һәм объектлары, инновация эшчәнлегенең асылы, Татарстан Республикасы инновация сәясәтенең максаты, бурычлары, асылы һәм принциплары, инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтү рәвешләре һәм шартлары, дәүләт ярдәменә дәгъва белдерә торган инновация проектларына куела торган таләпләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының инновация эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләре, инновация эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу рәвешләре һәм ысуллары билгеләнә. Инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән, шулай ук законнар белән тыелмаган бүтән акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

63-ТРЗ номерлы Закон нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инновация эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органы һәр өч ел саен инновация меморандумы эшли, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана. Инновация меморандумы — Татарстан Республикасын инновацияле үстерү стратегиясен уртача срокка перспективада гамәлгә ашыру механизмын һәм төп макроикътисадый күрсәткечләрне, инновация эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләрен һәм инновация продуктларының өстенлекле төрләрен билгели торган документ. Шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең инновация эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органы ел саен Татарстан Республикасында инновация эшчәнлегенең үткән елгы йомгаклары турында дәүләт доклады әзерли, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана, Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрелә һәм рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

Инновация эшчәнлеге мәсьәләләрен җайга сала торган махсус федераль закон булмау сәбәпле, 63-ТРЗ номерлы Законда Татарстан Республикасы инновация сәясәте, беренче һәм икенче дәрәҗәдәге инновация продукты, технополис, инновация фонды, венчур фонды, технопарк, технологик инкубатор, бизнес-инкубатор төшенчәләре ачыклана.

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба — 7-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, юридик һәм физик затлар арасында барлыкка килә торган

әһәмияттәге объектлар һәм җирле әһәмияттәге объектлар төрләре буенча Татарстан Республикасында шәһәр төзелешен проектлау нормативлары реестрын алып бару юлы белән гамәлгә ашырыла.

«Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 77-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала һәм җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын арттыру, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, транспорт хезмәтләре күрсәтү базарында пассажирлар йөртүчеләр (багаж ташучылар) арасындагы конкуренцияне үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

77-ТРЗ номерлы Законда «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 21 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җиңел таксига, җиңел такси йөртүчегә, пассажирлар йөртүчегә (багаж ташучыга) карата таләпләр, билгеләнгән таләпләрне пассажирлар йөртүчеләр (багаж ташучылар) тарафыннан үтәүне тикшереп тору тәртибе, җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль ярдәм итү төрләре билгеләнгән. Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеге пассажирлар йөртүчеләрнең (багаж ташучыларның) җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан бирелә торган рөхсәтне алу шарты белән гамәлгә ашырыла. Рөхсәтнең рәвеше, аның гамәлдә булу срогы, рөхсәт, рөхсәт дубликатын бирү һәм яңадан рәсмиләштерү тәртибе, бирелгән рөхсәтләр реестрын алып бару тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2011 елның 6 декабрендәге 999 номерлы карары белән билгеләнә.

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (алга таба – 63-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасы территориясендә инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме чараларын билгеләүгә һәм гамәлгә ашыруга бәйле





дан хезмәте вазыйфалары нисбәте турында» Татарстан Республикасы законнарының төп нигезләмәләрен туплаган.

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» (алга таба – Кодекс) Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне оештыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала, шулай ук федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәтне узу шартларын һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хокукый хәлен (статусын) билгели. Моннан тыш, әлеге Кодекста Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрын төзү, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына билгеләнеп куела торган зат белән төзелә торган контрактның үрнәк рәвеше һәм муниципаль хезмәткәрләргә аттестация уздыру турында үрнәк нигезләмә, шулай ук Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нисбәте билгеләнде.

Муниципаль хезмәт – хезмәт шартнамәсе (контракты) төзү юлы белән биләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфаларында гражданнарның даими нигездә гамәлгә ашырыла торган профессиональ эшчәнлеге.

Муниципаль хезмәткәрнең яллаучысы муниципаль берәмлек була, аның исеменнән ялаучы вәкаләтләрен яллаучының вәкиле (эш бирүче) гамәлгә ашыра.

Муниципаль вазыйфалар түбәндәге төркемнәргә бүленә: муниципаль хезмәтнең югары, баш, әйдәүче, өлкән, кече вазыйфалары.

Кодексның 9 статьясы нигезендә муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри әзерлек дәрәҗәсенең муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен күрсәтә торган класслы чиннар бирелә.

Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләргә түбәндәге класслы чиннар бирелә:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфаларын биләүчеләргә – 1, 2 яисә 3 класслы хакыйкый муниципаль киңәшчесе;

муниципаль хезмәтнең баш вазыйфаларын биләүчеләргә – 1, 2 яисә 3 класслы муниципаль киңәшче;

муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфаларын биләүчеләргә – 1, 2 яисә 3 класслы муниципаль хезмәт киңәшчесе;

муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфаларын биләүчеләргә – 1, 2 яисә 3 класслы муниципаль хезмәт референты;

муниципаль хезмәтнең кече вазыйфаларын биләүчеләргә – 1, 2 яисә 3 класслы муниципаль хезмәт секретаре.

Кодексның 10 статьясы муниципаль хезмәткәрләргә класслы чиннар бирү һәм муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәтнең башка вазыйфаларына күчерелгәндә һәм муниципаль хезмәттән азат ителгәндә бу чиннарның сакланып калу тәртибен билгели.

Муниципаль хезмәт вазыйфаларын югарыда күрсәтелгән төркемнәргә кертү Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры (Кодекска 1 нче кушымта) нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының җирле үзидарә органнары, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре, муниципаль районда, шәһәр округында, шәһәр һәм авыл җирлекләрендә тарихи һәм башка җирле традицияләрне исәпкә алып билгеләнә торган вазыйфалар төркемнәре һәм функциональ билгеләре буенча классификацияләнгән исемнәрнең исемлеге расланды.

Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфаларының һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының нисбәте (Кодекска 2 нче кушымта) күрсәтелгән вазыйфаларның муниципаль хезмәттәге һәм дәүләт граждан хезмәтендәге тиешле вазыйфаларга куела торган квалификация таләпләренә бәйле рәвештә аларга туры килү нисбәтлелеген билгели.

2009 елның 12 февралендә «Муниципаль берәмлек вәкиллекле органы депутатының, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 15-ТРЗ номерлы Закон) кабул ителде, ул 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль берәмлек вәкиллекле органы депутатының, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләрен билгели. Әлеге Законның гамәли көче шулай ук муниципаль берәмлекләр сайлау комиссияләренең тиешле сайлау комиссияләрендә даими штат нигезендә эшләүче әгъзаларына, ә муниципаль вазыйфаларны даими биләгән затларны пенсия белән тәэмин итү өлешендә – муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасарына һәм аудиторына, әгәр бу вазыйфалар муниципаль берәмлекләргә кертелгән булса, кагыла. 15-ТРЗ номерлы Законның 1 статьясы нигезендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга гарантияләр федераль законнар





«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 98-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасы территориясендә территориаль планлаштыру, шәһәр төзелешен зоналаштыру, территорияне планлаштыру, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өлкәсен җайга сала. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә 98-ТРЗ номерлы Законда республиканы территориаль планлаштыру документлары һәм Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документлары төрләре, республиканы территориаль планлаштыру схемасы, муниципаль районнарны территориаль планлаштыру схемасы, составы һәм аларны әзерләү тәртибе, җирлекләрнең, шәһәр округларының генераль планнары составы һәм аларны әзерләү тәртибе, шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативлары составы, аларны әзерләү һәм раслау тәртибе, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең проектын әзерләү комиссиясе составына һәм аның эшчәнлек тәртибенә таләпләр, территорияне планлаштыру проектларының составы һәм эчтәлеге, территорияне планлаштыру документациясен әзерләү тәртибе билгеләнә.

98-ТРЗ номерлы Законны федераль законнарга туры китерү максатларында 2014 елның 20 ноябрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителде, әлеге Законда республиканы территориаль планлаштыру схемасы проектын әзерләгәндә шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын исәпкә алырга кирәклеге билгеләнде. Бу нормативларны әзерләү Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелешен, халыкның социаль-демографик составын һәм урнашу тыгызлыгын, табигать-климат шартларын, Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеше стратегиясен, программасын һәм фаразлауларын, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм кызыксынучы затлар тәкъдимнәрен исәпкә алып эшләнә.

Шәһәр төзелешен проектлауның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган республика нормативлары күрсәтелгән нормативлар расланган көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокукый актларын рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга, территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш.

Шәһәр төзелешен проектлау нормативларын системага салу Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан региональ

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан автомобиль юлларына кагыла.

43-ТРЗ номерлы Закон юл эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт идарәсен җайга салуга, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан автомобиль юлларының төзеклеген һәм үсешен тәэмин итүгә, аларның техник торышы дәрәҗәсен күтәрү чараларын эшләүгә, юл эшчәнлегендә перспектив технологияләрне һәм стандартларны кертүгә ярдәм итүгә, юл эшчәнлеген гамәлгә ашырганда эшләр һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләр базарында нәтиҗәле конкуренцияне тәэмин итүгә, автомобиль юлларын проектлау, төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау, тоту, файдалану өлкәсендә инвестиция климатын яхшыртуга юнәлдерелгән.

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә 43-ТРЗ номерлы Законда автомобиль юлларын урнаштыру өчен бирелгән җир кишәрлекләреннән файдалану үзенчәлекләре, автомобиль юлларыннан файдалану үзенчәлекләре, түләүле автомобиль юлларыннан һәм түләүле өлешләре булган автомобиль юлларыннан файдалану үзенчәлекләре, автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында законнарны бозган өчен җаваплылык билгеләнә.

43-ТРЗ номерлы Закон Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә вәкаләтләрен, автомобиль юлларыннан файдалануда, юллар төзүдә һәм аларны реконструкцияләүдә, юл сервисын үстерүдә катнаша торган физик һәм юридик затларның бурычларын һәм хокукларын билгели. Закон региональ һәм җирле әһәмияттәге, гомуми булмаган файдаланудагы һәм хосусый автомобиль юлларын проектлау, төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тотуның финанс нигезләрен билгели.

Законның транспорт чарасының автомобиль юлы буйлап хәрәкәт итүен вакытлыча чикли яисә туктата торган нормасына «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 11 апрелендәге 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән өстәмә кертелде, аның нигезендә республика торак пунктлары чикләрендәге региональ, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына мондый чикләүләр халыкара спорт чаралары үткәрү чорына кертелә.





һәм әлеге Закон нигезендә муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә.

Муниципаль норматив хокукый актларны системалаштыруны һәм исәпкә алуны, гражданнарның муниципаль норматив хокукый актлар турында дөрес мәгълүмат алуга конституциячел хокукларын тәэмин итү, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар һәм оешмалар тарафыннан муниципаль норматив хокукый актлар алу өчен шартлар булдыру максатларында «Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары реестры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 14-ТРЗ номерлы Закон) кабул ителде. Әлеге Закон Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару тәртибен билгели. Регистрга җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителгән (чыгарылган) гамәлдәге барлык норматив хокукый актлар, шулай ук җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән һәм хокукый актлар буларак рәсмиләштерелгән карарлар кертелергә тиеш. Муниципаль регистрга «хезмәттә файдалану өчен», «бастырып чыгарылмый торган», «матбугат өчен түгел» дигән грифлар куелган кулланылуы чикләнгән муниципаль норматив хокукый актлар кертелми. Муниципаль регистрны оештыру һәм алып бару чыгымнарын финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Әлеге Законга «Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистры турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 13 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән муниципаль норматив хокукый актларга юридик экспертиза үткәрү турында $4^1$ статья өстәлде. Мондый экспертизаны үткәрү муниципаль норматив хокукый актлар реестрын оештыручы һәм алып баручы вәкаләтле органга йөкләнә. Муниципаль норматив хокукый актта Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль берәмлек уставына каршы килә торган нигезләмәләр табылганда, вәкаләтле органның эксперт бәяләмәсе мондый актны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органына (җирле үзидарәнең вазыйфаи затына), шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм прокуратура органнарына җибәрелә.

Җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләре бирү өлешендә билгеле бер закон чыгару базасы барлыкка китерелде. Мәсәлән, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 6 өлеше таләпләрен исәпкә алып, җирле үзидарә органнарына түбәндәге Татарстан Республикасы законнары белән Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләре бирелде:

1) «Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына җирлекләрнең региональ финанс ярдәме фондыннан җирлекләргә дотацияләр исәпләү һәм бирү турында» 2005 елның 22 декабрендәге 132-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

2) «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

3) «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

4) «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга вәкаләтләр бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы);

5) «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

6) «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 16 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

7) «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 7 апрелендәге 29-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

8) «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру





конверцияләү (чит ил инвесторлары тарафыннан җыела торган бурычны дисконтлаудан килгән файда); Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләреннән, җитештерү биналарыннан файдалануның ташламалы шартлары.

2180-XII номерлы Законда чит ил инвестицияләрен дәүләт тарафыннан җайга салуның төрле рәвешләре һәм ысуллары, шулай ук чит ил инвестицияләрен җайга салуда җирле үзидарә органнары катнашуының мөмкин булган рәвешләре һәм ысуллары билгеләнә.

«Татарстан Республикасында ваклап сату базарларын оештыру хокукына рөхсәтләр бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә органнарын билгеләү турында» 2007 елның 26 июлендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба — 33-ТРЗ номерлы Закон) «Ваклап сату базарлары турында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә кабул ителде, әлеге Федераль законның 4 статьясы нигезендә базар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм базарны оештыру күздә тотыла торган территория чикләрендә урнашкан мөлкәт объектына яисә объектларына ия юридик зат тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә Россия Федерациясе субъекты законында ачыкланган җирле үзидарә органы тарафыннан бирелгән рөхсәт нигезендә оештырылырга мөмкин.

33-ТРЗ номерлы Законның 1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасында тиешле муниципаль берәмлекләр территориясендә ваклап сату базарларын оештыру хокукына рөхсәт бирүгә вәкаләтле органнар буларак муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары билгеләнгән.

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба — 43-ТРЗ номерлы Закон) Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юлларыннан файдаланганда һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала. 43-ТРЗ номерлы Законның гамәли көче, федераль әһәмиятле автомобиль юлларыннан һәм аларның участокларыннан тыш,

«Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре турында» 1994 елның 19 июлендәге 2180-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 2180-XII номерлы Закон) инвестицияләрнең активлыгын кызыксындыруга һәм Татарстан Республикасы икътисадына чит ил инвестицияләрен җәлеп итүгә, Татарстан Республикасы территориясендә чит ил инвесторлары хокукларының дәүләт гарантияләрен, аларны яклауны һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

2180-XII номерлы Закон, моңа кадәрге редакциясе кебек үк, чит ил инвесторлары эшчәнлегенә төрле гарантияләр билгели. Шулай ук Законда Татарстан Республикасы территориясендә чит ил инвесторлары эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт ярдәме чаралары каралган. Мәсәлән, инвестиция проектын нәтиҗәле гамәлгә ашыру, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук оешмалар белән үзара эш иткәндә гамәли ярдәм алу максатларында, бизнес оештыру өчен старт шартларын билгеләгәндә һәм гамәлгә ашырганда чит ил инвесторы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының махсус вәкаләтле башкарма хакимият органына (алга таба – вәкаләтле орган) мөрәҗәгать итә ала, ул әлеге мөрәҗәгатьне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган регламент нигезендә универсаль процедура тәртибендә («бер тәрәзә» принцибы буенча) карый.

Вәкаләтле орган чит ил инвесторын республика һәм Россия базарлары структурасы һәм сыйдырышлылыгы, инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле хезмәт, җитештерү һәм инфраструктура ресурсларының тупланышы турында мәгълүмат белән тәэмин итә.

Вәкаләтле орган, чит ил инвесторын җәлеп итү өчен, инвестиция проекты гамәлгә ашырыла торган территорияләрдә (инвестиция мәйданнарында) инфраструктура һәм кадрлар сәясәте буенча проектларны гамәлгә ашыру инициативасы белән чыга, Татарстан Республикасы икътисадының өстенлекле тармакларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектларын тулысынча тәкъдим итүне гамәлгә ашыра.

2180-XII номерлы Законда шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән чит ил инвестицияләрен кызыксындыруның чит ил инвесторларына карата кулланылырга мөмкин чаралары каралган: салым салу өлкәсендәге чаралар, шул исәптән ташламалы салым ставкалары, кичектереп түләү, өлешләп түләү, инвестицияле салым кредиты рәвешендә салым һәм җыем түләү вакытын үзгәртү, башка чаралар; финанс чаралары, шул исәптән ташламалы заемнар (кредитлар), заем поручительлеге (гарантияләр); бурычларны акцияләргә





өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 28 апрелендәге 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

9) «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 15 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

10) «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 11 декабрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

11) «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 24 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

12) «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

13) «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

14) «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

15) «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында»

2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

16) «Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

17) «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2014 елның 14 маендагы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

Югарыда телгә алынган законнар җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс ягыннан һәм матди яктан тәэмин итү, муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының һәм дәүләт хакимияте органнарының хокукларын һәм бурычларын, җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен башкаруы хакында хисап бирү тәртибен һ.б. ачыклыйлар.

Яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары 131-ФЗ номерлы Федераль законның 85 статьясындагы 10 өлеше нигезендә, әлеге җирле үзидарә органнары күрсәтелгән Федераль законның 84 статьясындагы 5 өлеше нигезләмәләре нигезендә үз вәкаләтләрен үтәүгә керешкән датадан башлап, бу муниципаль берәмлекләр территорияләрендә җирле әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен Россия Федерациясе закон актлары нигезендә гамәлгә ашырган җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының, башка органнарның һәм вазыйфаи затларның хокукый варислары булып тора. Яңа төзелгән муниципаль берәмлекләр җирле үзидарә органнарының хокук дәвамчылыгы нәтиҗәсендә барлыкка килә торган мөлкәт йөкләмәләре Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә расланган тапшыру (бүлү) актлары белән билгеләнә.

Федераль законнарның әлеге таләбен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасында 2006 һәм 2008 еллар дәвамында 2006 елның 1 гыйнварына мөлкәт йөкләмәләре булган яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең (муниципаль районнарның, шәһәр округларының) җирле үзидарә органнарының мөлкәт





ры турында» Федераль законның 7 һәм 46 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 2 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 14-ТРЗ номерлы Закон) кабул ителде.

Әлеге Закон нигезендә, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен артык вазыйфалар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының һәм Татарстан Республикасы бюджетының нигезсез чыгымнары барлыкка килүгә этәрә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлегенә кагылышлы норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм гамәлдәге норматив хокукый актларга экспертиза ясау процедурасы уздырыла.

Законда норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру этаплары, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы законнары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру үзенчәлекләре билгеләнгән.

Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» һәм «Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре турында» законнар белән җайга салына.

«Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – 1872 номерлы Закон) гамәли көче төп капиталга (төп средстволарга) инвестицияләр кертү рәвешендә, шул исәптән яңа төзелешкә яисә гамәлдәге предприятиеләрне торгызуга (реконструкцияләүгә, техник яктан яңадан җиһазландыруга), җайланмалар сатып алуга, проект-тикшеренү эшләренә акча кертү һәм башка чыгымнар рәвешендә гамәлгә ашырылучы инвестиция эшчәнлегенә бәйле мөнәсәбәтләргә кагыла.

1872 номерлы Законда инвестиция эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуның рәвешләре һәм ысуллары билгеләнгән. Законда, шулай ук, инвестиция эшчәнлеге субъектларының хокукларына дәүләт гарантияләре урнаштырыла, бу инвестиция эшчәнлеге субъектларының тотрыклы эшләвен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

ры тарафыннан Россия Федерациясе карамагындагы эшләр буенча аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле дәүләт мөлкәте төрләре билгеләнгән.

«Муниципаль милектәге мөлкәтне бүлешүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү тәртибе турында» 2008 елның 6 августындагы 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 71-ТРЗ номерлы Закон) муниципаль мөлкәтне җирле үзидарә органнары арасында бүлешүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

Әлеге Законда «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль законнар кабул ителү уңаеннан Россия Федерациясе закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуны тану турында» 2004 елның 22 августындагы 122-ФЗ номерлы Федераль законның 154 статьясындагы 11.1 өлеше нигезендә тапшырылырга тиешле муниципаль мөлкәт исемлеген килештерү тәртибе, муниципаль мөлкәтне тапшыру турындагы килештерелгән тәкъдимнәрне җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына җибәрү тәртибе һәм муниципаль мөлкәт бүлешү турында Татарстан Республикасы хокукый актын кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге билгеләнә.

«Хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең идарә һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында» 2000 елның 19 октябрендәге 383 номерлы Татарстан Республикасы Законы акцияләре (өлешләре) Татарстан Республикасы милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең идарә һәм контроль органнарында һәм (яисә) үзләренә карата махсус хокуктан («алтын акциядән») файдалану турында карар кабул ителгән ачык акционер җәмгыятьләрнең идарә һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләренең эшчәнлеген җайга салуга, күрсәтелгән хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре өчен дәүләт вәкилләренең җаваплылыгын арттыруга юнәлдерелгән.

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принципла-





йөкләмәләре буенча тапшыру (бүлү) актын раслаучы 45 закон кабул ителде.

Бу актлар белән кредит шартнамәләре, муниципаль гарантияләр бирү шартнамәләре, муниципаль берәмлекләрнең облигация займнары буенча йөкләмәләрне үз эченә ала торган әлеге муниципаль бурыч китаплары нигезендә мөлкәт йөкләмәләре раслана.

Моннан тыш, тапшыру (бүлү) актларын раслый торган Татарстан Республикасы законнарына кушымта итеп тапшыру (бүлү) актын төзегәнче, йөкләмәләрне инвентаризацияләүнең һәм йөкләмәләр буенча башкарылган исәп-хисаплар чагыштырмасының шушы йөкләмәләр барлыгын, дөреслеген һәм бәясен раслаучы актлары (исемлекләре) бирелә.

## III БҮЛЕК

# ИКЪТИСАДЫЙ ҮСЕШ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЗАКОННАР

### Икътисад тармагында дәүләт идарәсенең гомуми мәсьәләләре

«2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасын раслау турында» 2011 елның 22 апрелендәге 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

Программа икътисадны тотрыклы, динамикалы үстерү һәм уңайлы әйләнә-тирә мохит тудыру нигезендә Татарстан Республикасы халкының тормыш сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк: икътисадның көндәшлеккә сәләтен арттыру; дәүләт идарәсенең һәм муниципаль идарәнең динамикалы системасын формалаштыру; инновацион диверсификацияләнгән икътисад булдыру; икътисадны экологияләштерү; урта сыйныф өлешен арттыру.

Программа икътисад үсешенә институциональ факторларның йогынтысын анализлау нигезендә әлеге Программа нигезендә әзерләнә торган барлык республика, ведомство һәм муниципаль (шул исәптән муниципальара) программаларның һәм проектларның үзара, шулай ук һәркайсының әлеге Программа белән программалар арасындагы функциональ бәйләнешләрнең һичшиксез үтәлешен тәэмин итә торган программалаштыруның яңа моделен кулланып әзерләнде.

Программага үзгәрешләр кертүнең яңа технологиясе Программага, шулай ук аның нигезендә әзерләнгән башка программаларга аларны гамәлгә ашыру барышында да үзгәрешләр кертергә мөмкинлек бирә.

Татарстан икътисадын киләчәктә дә үстерүне дәвам итү максатыннан, «2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 20 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Программага яңа чаралар өстәлде, алар түбәндәгеләрне хәл итүгә юнәлдерелгән:

1) мөлкәт мөнәсәбәтләре белән идарә итү өлкәсендә – мәгълүматны һәм ведомствоара нәтиҗәле хезмәттәшлекне комплекслы анализлау максатыннан республика башкарма хакимиятенең төрле органнары белешмәләрен интеграцияләү системасын киләчәктә дә камилләштерүгә;





2) җитештерү көчләрен урнаштыру өлкәсендә – республикага җәлеп ителә торган инвестицияләр күләмен арттыруга, заманча призводстволар һәм яңа югары җитештерүчән эш урыннары булдыруга, инвесторлар хокукларын яклауга һәм эшкуарларга булышу системасының ачыклыгын арттыруга;

3) кеше капиталын һәм хезмәт базарын үстерү өлкәсендә – өстенлекле тармакларга югары квалификацияле белгечләр җәлеп итү һәм шунда калдыруга;

4) инновацион үсеш өлкәсендә – фән һәм җитештерү интеграциясенә, җитештерү процессына заманча техкрологияләр кертүгә, шулай ук гамәли тикшеренүләрнең коммерциячел булуын арттыруга;

5) бәяләр һәм тариф сәясәте өлкәсендә – торак-коммуналь хуҗалыкта идарә компанияләренең финанс-җитештерү эшчәнлегендә үтәкүренмәлелеккә.

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» 2005 елның 8 апрелендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 65-ТРЗ номерлы Законы) федераль дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте составын билгели. Законның гамәли көче финанс чараларына, җиргә, урманга, суга һәм башка табигый ресурсларга, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт милкендәге хуҗалык җәмгыятьләр акцияләренә (устав капиталындагы өлешләренә) кагылмый.

65-ТРЗ номерлы Законда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан Татарстан Республикасы карамагындагы эшләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле дәүләт мөлкәте төрләре; Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтенең төрләре; Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы эшләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле дәүләт мөлкәте төрләре («Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль Законның 26.2 статьясы нигезендә); Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органна-